


Набережночелнинский институт К(П)ФУ



Набережночелнинское медресе «Ак мечеть» ЦРО-ДУМ Республики Татарстан



Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов



I МЕЖДУНАРОДНАЯ НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКАЯ КОНФЕРЕНЦИЯ

«РОЛЬ ИСЛАМА В СТАБИЛИЗАЦИИ СОЦИАЛЬНЫХ ПРОЦЕССОВ»



«ҖӘМГЫЯТЬ ТОРМЫШЫН ТОТРЫКЛАНДЫРУДА ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ»

I ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Набережные Челны, 2015

НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКИЙ ИНСТИТУТ КАЗАНСКОГО (ПРИВОЛЖСКОГО) ФЕДЕРАЛЬНОГО УНИВЕРСИТЕТА
НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКИЙ ИНСТИТУТ СОЦИАЛЬНО-ПЕДАГОГИЧЕСКИХ ТЕХНОЛОГИЙ И РЕСУРСОВ
НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКОЕ МЕДРЕСЕ «АК МЕЧЕТЬ»

I МЕЖДУНАРОДНАЯ НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКАЯ КОНФЕРЕНЦИЯ

«РОЛЬ ИСЛАМА В СТАБИЛИЗАЦИИ СОЦИАЛЬНЫХ ПРОЦЕССОВ»

***

«ҖӘМГЫЯТЬ ТОРМЫШЫН ТОТРЫКЛАНДЫРУДА ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ»

I ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Набережные Челны, 2015

ББК 86.38 Тат
Р – 68

Печатается по решению Ученого совета (Шуры) Набережночелнинского мусульманского медресе «Ак мечеть» (протокол №8 от 08.05.15)

Роль ислама в стабилизации социальных процессов: сборник статей и тезисов I Международной научно-практической конференции, 14 марта 2015 г. / под ред. Р.И. Хазиева. – Набережные Челны: Ак мечеть, 2015. – 320 с.

Под научной редакцией кандидата филологических наук, доцента Хазиева Ринала Исмагиловича.

В сборник I Международной научно-практической конференции «Роль ислама в стабилизации социальных процессов» вошли тезисы и статьи по проблемам раскрытия роли ислама в стабилизации социальных процессов.

Сборник представляет интерес для студентов, преподавателей духовных и светских учебных заведений.

За содержание тезисов и статей отвечает автор.

ISBN 978-5-9905581-1-3

ПРИВЕТСТВИЕ КАЗЫЯ ПРИКАМСКОГО РЕГИОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН, ИМАМ-ХАТЫЙБА И ДИРЕКТОРА НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКОГО МУСУЛЬМАНСКОГО МЕДРЕСЕ “АК МЕЧЕТЬ” ШАЙХЕВАЛИЕВА РУСТАМА ШАЙХРАЗИЕВИЧА

***

ТАТАРСТАН ҖӨМҺҮРИЯТЕНЕҢ ЧУЛМАН БУЕ ТӨБӘГЕ КАЗЫЕ, ИМАМ-ХАТЫЙБ, ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ “АК МӘЧЕТ” МӨСЕЛМАН МӘДРӘСӘСЕ ДИРЕКТОРЫ ШӘЙХЕВӘЛИЕВ РӨСТӘМ ШӘЙХЕРАЗЫЙ УЛЫНЫҢ СӘЛАМЛӘҮ СҮЗЕ

آعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ. بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ.

الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَلَمِينَ وَ الْعَقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ وَ الصَّلَوةُ وَ السَّلَمُ عَلَى مُحَمَّدٍ وَ عَلَى آلِهِ وَ اَصْحَبِهِ اَجْمَعِينَ.

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, шул галәмнәрне тәрбия кылып һәм үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләндереп торучы Аллаһу Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнәләр, мактау-догаларыбыз, безне хак юлга күндерүче, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түреннән чыккан Салават шәрифәләребез булса иде. Безне олуглап, ихтирам итеп конференциябезгә килүче мөхтәрәм галимнәребез, дин эшлеклеләре, милләттәшләр, газиз дин кардәшләрем! Барчаларыбызга да Аллаһу Сөбханәһү вә Тәгаләнең сәламнәре, рәхмәтләре һәм дә бәрәкәтләре булса иде.

السَّلام عليكم و رحمة الله و بركاته

VII гасыр башында пәйгамбәребез Мөхәммәд салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек вазыйфасы йөкләтелүен һәм шуның белән җир йөзенә Ислам диненең таралуын кешелекнең яңа югарылыкка күтәрелүе итеп кабул итәргә кирәк. Бу вакыйганы тасвирлап Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә: 5.15. “Ий кешеләр! Сезгә мәгърифәт нуры Мөхәммәд галәйһиссәлләм һәм ачык китап килде”, – ди. Кыямәт көненә кадәр, ягъни дөнья беткәнчегә кадәр җир йөзенә башка пәйгамбәр килмәячәк һәм Коръәннән башка китап иңмәячәк. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм алып килгән Ислам дине кешелекне югары әхлакый сыйфатларга өндәве, җир шарындагы һәр халыкның яшәү рәвешен билгели торган шәригате белән аерылып тора. Шуңа күрә Ислам дине Гарәбстан ярымутравында барлыкка килеп, кыска гына вакыт эчендә Атлантик океаннан Кытайга, Тын океанга кадәр тарала. Ул үзенең камиллеге белән бөтен халыкларны гаҗәпләндерә, үзенә җәлеп итә. Ислам дине сәбәпле кешелек үзенең үсешендә яңа этапка күчә һәм бу этап, алда әйтеп кителгәнчә, кыямәт көненә кадәр барырга тиеш.

Кыямәт көненә кадәр барырга тиеш булган динне дөньяви фәннәрсез күз алдына китереп булмый, чөнки дөньяви фәннәр тормышның техник яктан алга китүен тәэмин итүләре нәтиҗәсендә шәргый кануннарга да өстәмәләр кертелүгә сәбәп булалар.

Ислам дине шәригатькә нигезләнеп идарә ителүче яңа дәүләт системасы барлыкка китерә. Шушы чорда бөтен фәннәргә нигез салына, моңа кадәр булганнары бергә җыела, тупланыла. Югары әхлак, Аллаһы Тәгаләгә булган ныклы ышаныч һәм буйсыну, гыйлемгә булган мәхәббәт, омтылыш мөселманнарны моңарчы булмаган биеклеккә күтәрә.

Европада хәтта югары катлам кешеләре дә белемне кирәк дип санамаган бервакытта, Ислам дөньясында мөмкинлекләре булмаган түбән катлам кешеләренең балалары өчен бушлай укытыла торган мәктәпләр эшли. Шунысы мәгълүм: Европадагы монастырьларда да 80 нән артык китап булмый, ә Кордова хәлифе әл-Хакам китапханәсендә 400 000 том китап, ягъни Европаның калган өлешендә булган барлык китаплардан күбрәк була һәм бу әле иң зур китапханә саналмый. Мәсәлән, Каһирә китапханәсендә 1 миллион, Сириянең

Триполи китапханәсендә 3 миллион, ә Багдадның “Хикмәт йорты”нда 4 миллион том китап була һәм бер Кордовада гына ел саен 18000 китап бастырыла. VIII-IX гасырларда хәлифәт дөньяның кәгазь чыгару үзәгенә әверелә.

Мөселманнар үзләре буйсындырган һәрбер шәһәрдә иң элек мәчет салалар, аннары гомуми белем бирүче һәм һөнәри уку йортлары, университет оештыралар. Һәм бу университетларда дини белем беләп беррәттән дөньяви белем дә бирелә. Бөтен Европада җирне яссы һәм шар кебек түгәрәк дип өйрәтү-аңлатулар мөртәтлек булып саналган бервакытта, гарәпләр инде IX гасырда ук балаларын мәктәпләрдә глобустан укыталар.

Ибн Фиркас 800 нче елда очкыч уйлап таба, ясый һәм сынап карый. Моннан соң 500 ел үткәч кенә, Роджер Бекон Ибн Фиркас хезмәтләренә таянып очкыч ясый ала, ә Леонардо да Винчиның уйлап табуы Ибн Фиркастан соң 700 ел үткәч кенә була.

XVII гасырда “оптика” фәненә нигез салучы булып саналган Ньютон яктылык нурының төрле төсләрдән торуын ача. Бу һәм “оптика” фәненә кагылышлы башка ачышлар да XI гасырда әл-Хайтами тарафыннан эшләнгән булалар.

Мөселманнар беренче булып дары һәм дары белән ата торган утлы кораллар ясыйлар.

Бөек галим-энциклопедист Абу-р-Рейхан әл-Бируни математика, астрономия, ботаника, география, гомуми геология, минералогия һәм башка фәннәр буенча фундаменталь хезмәтләр төзегән. Гомумән алганда, мөселман галимнәре алда санап кителгән, шулай ук химия, тригонометрия, алгебра, медицина һәм башка фәннәргә нигез салалар, аларның үсешенә үзләренең зур өлешләрен кертәләр.

Хәлифәтнең “алтын чоры” төгәл фәннәр, тиңдәше булмаган искиткеч гүзәл сарайлар белән генә түгел, бәлки, үзенең дөньякүләм танылган шигырьләре, поэмалары, әсәрләре белән дә, үзенең фәлсәфәсе белән дә бөтен “дөньяның бизәге”нә әверелә. Бу чор шулай ук гасырлар буе онытылмас Фирдәүси, Гомәр Хәйәм, ибн Рушда, Җәләлетдин Румилар, “Шаһнамә”ләр һәм “1001 кичә”ләр чоры да.

Бу чорда Ислам цивилизациясе европалылар уйлый да алмаслык дәрәҗәдә алга китә, шәһәрләр үсә: Кордовада ярты миллион кеше яшәсә, Багдадта яшәүчеләр саны 1 миллионга җитә, ә бу чорда Европаның иң зур шәһәрләреннән саналган Парижда нибары 40 мең кеше яшәгәне билгеле. Европадагы югары даирә түрәләр үзләренең балаларын Кордова, Тунис, Багдад университетларына укырга җибәрәләр. Багдадтан алып Испаниягә кадәр булган университетларда укыган христиан һәм яһүд студентлары башка җирдән алып булмый торган иң яхшы белемнәрне үзләштерәләр. Алай гына да түгел, җирле мөселман хакимияте тарафыннан аларга матди ярдәм дә күрсәтелә.

Шулай итеп, дөнья үзенең бөтен байлыклары белән мөселманнар кулына күчә. Алар дөнья белән идарә итә башлыйлар һәм, кызганычка каршы, үзләренә кадәр булган цивилизацияләр, империяләр язмышына дучар булалар: иман кими, әхлаксызлык арта, хакимият һәм байлык бүлешү башлана. Дөнья байлыкларына ия булган мөселманнар бүгенге көн белән генә яши башлыйлар, аларны инде иртәгәге көн кызыксындырмый. Шул сәбәпле мөселман галимнәренең ачышлары Ислам дөньясын, киләчәк заманның таләпләренә туры килерлек итеп, техник һәм мәдәни үсешкә китерә алмый. Алар фәкать үткәннәрен сагынып, үткәннәре тәэсирендә горурланып-хыялланып яшәүләрен дәвам итәләр.

Әле кайчан гына “дөнья бизәге” булып саналган Кордова хәлифәтенең дә, шигырьләрдә “дөньядагы җәннәт” рәвешендә сурәтләнгән Багдад хәлифәтенең дә “Шаһнамә”дән һәм “1001 кичә”дән башка горурланыр нәрсәләре калмый.

Ә европалыларга килсәк, алар кыргыйлыктан чыгалар һәм киләчәккә зур омтылышлар белән яши башлыйлар. Алар гарәп уку йортларында белем алып, тәре походлары кебек төрле сугышларда гыйбрәтләнеп, кыскасы, бөтен мөмкинлекләрдән файдаланып, мәгърифәттә хәтта Кытайны да узып китәләр.

Европа инде элекке кыргый Европа булудан туктый. Анда көчле галимнәр барлыкка килә, фән үсә. XVII гасыр башыннан башланган географик һәм фәнни ачышлар нәтиҗәсендә, европалылар, мөселманнар белән чагыштырып булмас дәрәҗәдә, алга

китәләр һәм яңа Европа цивилизациясен тудыралар. Ә мөселманнар, киресенчә, гыйбадәт дәрәҗәсендә калып, шул гыйбадәттәге төрлелектә үзара бәхәсләшеп, сугышып дөнья аренасында тоткан урыннарын тәмам югалталар.

Шулай итеп, фән Европага күчә. Ләкин ул барыбер динсез була алмый. Кайберәүләр безгә фән галимнәрен динсез итеп күрсәтергә тырышалар. Европа фәннәренә нигез салучы, бөтен чорларның иң зур галиме булып саналучы Исаак Ньютон: “Көчсез кол кебек без Илаһи затка мохтаҗбыз”, – ди. XX гасырның иң зур галиме Альберт Энштейн әйткән фикер дә игътибарга лаек: “Мин чын галимне ныклы иманга ия булмаган итеп күз алдына да китерә алмыйм. Моны икенче төрле дә әйтергә була: динсез фәнгә ышанырга ярамый”.

Бүгенге көн галимнәре дә Аллаһы Тәгаләнең барлыгын инкарь итмиләр, эволюцион теориянең кешеләрне диннән аерып коллыкта тотар өчен уйлап чыгарылган ялган фән икәнлеген таныйлар. Аллаһы Тәгалә галимнәргә аңлау сәләтен башкаларга караганда күбрәк бирә. Алар материаль тормышны күп өйрәнүләре, төрле фәнни ачышлар нәтиҗәсендә Аллаһы Тәгаләне бу дөньяларның бердәнбер халык кылучысы икәнлеген тануга ирешәләр. Мәсәлән, Исаак Ньютон Аллаһы Тәгаләне түбәндәгечә тасвирлый: “Илаһи зат – мәңгелек һәм абсолют. Ул – бөтен нәрсәгә көче җитүче кодрәт иясе һәм Ул бар нәрсәдән хәбәрдар, бар нәрсәне дә белүче. Аның барлыгы мәңгелек белән бәйләнгән. Ул элек булган, хәзерге вакытта була торган һәм киләчәктә булачак нәрсәләрнең барысын да белә. Ул – чиксез, Аның чиге юк. Ул – мәңге хак. Аның бар булуы мәңге. Ул һәрбер җирдә бар. Аның барлыгы урын һәм вакыт белән бәйле түгел. Ул вакытны һәм шул вакыт араларын барлыкка китерүче”. Бу сүзләрне укыган кеше ничек итеп аның авторын һәм шул автор нигез салган фәннәрне динсез дип әйтә алыр икән.

Фәнгә ия булган Европа бүген дөнья белән идарә итә. Әмма соңгы вакыйгалар бөтен дөньяның Исламлашуын күрсәтә. Чөнки Аллаһы Тәгалә бу дөньяны һәм андагы барлык җанлы һәм җансыз нәрсәләрне Үзенә генә буйсына торган итеп халык кылган. Дин белән фән дөнья арбасының ике тәртәсе кебек: ике тәртә тигез, ныклы булганда гына арба алга барырга мөмкин. Исламнан аерылган Европа цивилизациясе дә әхлаксызлык упкынына тәгәрәп, үзенең һәлакәтенә бара.

Ислам тарихы – үзенең югарыга күтәрелүләре һәм түбәнгә төшүләре белән татар халкының да тарихы. Шуның өчен аның югары күтәрелүен без горурлык итеп кабул итсәк, түбәнчелеккә төшүен кимсетелү буларак кабул итәбез. Тарихны кире язып булмый, ә эшне алга карап алып барырга кирәк.

Без, мәдрәсә коллективы һәм шәһәребезнең фән галимнәре, “Ак мәчет”тә семинарлар, түгәрәк өстәлләр, төрле дәрәҗәдәге конференцияләр оештырабыз. Шул чараларда фәннең – динсез, диннең фәнсез була алмавы турында сүз алып барабыз. Гомумән, бүгенге болгавыр һәм тотрыксыз чорда үзара фетнәләрдән чыгу юлын шушы бердәм эшчәнлектә күрәбез. Без, дөньяда бара торган социаль процессларны тотрыкландыруда Исламның әһәмиятен дөрес аңлаган хәлдә, киләчәктә халкыбызга файдасы булыр дигән зур өмет белән әлеге фикерне әләм итеп күтәреп чыктык һәм шушы халыкара конференция аша башкаларга да җиткерергә ниятләдек. Аллаһы Тәгалә эшебезне хәерле кылсын, конференциядә катнашучыларга зур уңышлар, саулык-сәламәтлек, бәхет, иман байлыгы телим.

СЕКЦИЯ I.
РЕЛИГИЯ И НАУКА. МУСУЛЬМАНСКОЕ ОБРАЗОВАНИЕ: ПРОШЛОЕ, НАСТОЯЩЕЕ, БУДУЩЕЕ

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВАНЫҢ “КЫРЫК СЫРТ” РОМАНЫНДА АСЫЛГӘРӘЙ МУЛЛА ОБРАЗЫ

Габделхакова Г.Я.

Урта гомуми белем бирүче “Риза Фәхретдин исемендәге 1 нче санлы гимназия”, Әлмәт шәһәре, Россия

ОБРАЗ АСЫЛГАРАЙ МУЛЛЫ В ПРОИЗВЕДЕНИИ Ф. БАЙРАМОВОЙ «СОРОК ВЕРШИН»

Гаптулхакова Г.Я.

Муниципальное бюджетное образовательное учереждение «Гимназия №1 имени Ризы Фахретдина», г. Альметьевск, Россия

В статье рассматривается образ Асылгарая в романе Ф. Байрамовой «Сорок вершин».
Ключевые слова: *Фаузия Байрамова, “Сорок вершин”, образ муллы.*

THE CHARACTER OF ASYLGARAY MULLA IN THE NOVEL THE “FORTY PEAKS” BY FAUZIYA BAYRAMOVA

Gaptulkhakova G.Ya.

The Municipal budget educational organization - Riza Fakhretdin Gymnasium №1, Almetyevsk, Russia

This article discusses the image of Asilgaray in the novel “Forty-tops” by F. Bayramova.
Keywords: *Fauzia Bayramova, “Forty-tops”, the image of the mullah.*

Фәүзия Бәйрәмованың “Кырык сырт” романында (2005) үткән гасырның 30 нчы елларында илебездә барган вакыйгалар һәм бу вакыйгаларның конкрет гаилә тормышында нинди чагылыш табуы сурәтләнә.

Романның төп герое – Асылгәрәй хәзрәт. Хәзрәт кимендә кырык буын имам һәм мөдәррисләр, шәех һәм хаҗилар нәселеннән. Аның бөтен бабалары диярлек чит илләрдә дини белем алган, авылда имам булып торган. Нәселләре затлы Морза Мирзаяннар нәселеннән булуын авылда иң борынгы кабер ташлары да раслап килә.

“Зәйтуган зиратында табылган кабер ташын Асылгәрәй хәзрәтнең борынгы бабасы Җанбулат морзаныкы булырга тиеш, диләр” [1, б. 7].

Асылгәрәй хәзрәт бабалары кебек үк чит илләрдә гыйлем туплый.

“Асылгәрәй хәзрәт үзе дә Төркиядә укыганда дүрт тапкыр хаҗ кыла, моннан тыш күп гарәп илләрендә була, белемен Мисырда дәвам итә, гомер буе гыйлем туплый ” [1, б. 7].

Зур гыйлеме бәрабәренә укыган илләрендә төпләнеп калу мөмкинлеге булса да, Асылгәрәй туган авылына кайтып төпләнә. Хатынлыкка да үзе сыман алдынгы карашлы мулла кызы Мәһинурны ала. Аларның тормышлары да авыл тормышыннан шактый үзгә, яңарышлы булса да дингә нигезләнә. Хәзрәт авыл мәчетендә мәдрәсә тота, Мәһинур абыстай үз өйләрендә кызлар укыта. Халыкка динне алар яңача, дөньяви фәннәргә нигезләнеп җиткерергә тырышалар. Хәзрәт ислам динен куркытып укытуга каршы була.

"Шуңа күрә ул мәдрәсәдә шәкертләргә җәграфия, күк фәне, дөнья тарихы кебек дәресләр дә бирә башлады, чөнки ул үзе дә Төркиядә һәм Мисырда шул рәвешле укыган иде" [1, б. 7-8].

Асылгәрәй хәзрәт йортын да төрекләрнеке кебек ике катлы итеп сала. Бакчаларында төрле-төрле, моңарчы авылда булмаган җимеш агачлары утырта. Барган һәрбер җиреннән чәчәк орлыклары алып кайтып, аларны ишек алдына утырта. Абыстай белән хәзрәтнең тугыз баласы шул җәннәткә тиң ихатада үсәләр. Властька советлар килгәч бу матурлыктан бары йорт кына торып кала. Ләкин Асылгәрәй хәзрәт ихатасын ил тормышы белән генә түгел, ә иң беренче чиратта дингә бәйләп карарга кирәктер. Ихатасында кешенең җаны, эчке дөньясы чагылыш таба. Җанында матурлык һәм чисталык йөрткән кеше аны тирә-юненә дә тарата белә. Асылгәрәй хәзрәтләр сөрелгәч, аларның җәннәттәй йортлары юкка чыкмый, ә аларның күңелләрендә кала һәм мөмкинлек туу белән яңадан дөньяга шытып чыга.

"Җаекның текә ярында бер утар бар. Көйгән далада ул яшел утрауны хәтерләтә, чөнки анда агачлар шаулап утыра, гөлләр чәчәк ата, чишмәләр челтерәп агып ята. Бу утарда берничә йорт та бар, алар берсеннән-берсе матур, бай һәм зәвыклы итеп эшләнгән. Капка-тәрәзәләрдә челтәрле бизәкләр, коймалар ялт итеп төрле төскә буялган, һәр бизәктә татар рухы ярылып ята..." [1, б. 182].

Мәһабәт йорт-җирдән тыш Асылгәрәйнең балалары, халыкны кайгыртып, мәчет тә төзиләр. Әмма болар барысы да әле киләчәктә, ә әсәр башында авылда колхозлаштыру башлана. Колхозга кермәгән өчен кешеләрне кыйный-үтерә башлыйлар. Асылгәрәй мондый авыр вакытта үзен чын лидер итеп күрсәтә. Кулак дип бар мөлкәтен талап чыксалар да, ул хаксызга җәберләнгәннәрне яклап чыга. Кыйналган Садыйк мулланы курыкмыйча тоткынлыктан алып чыга һәм үз өенә сыендыра. Шуны да әйтергә кирәк: Асылгәрәй хәзрәт власть дип аталучы кешеләр тарафыннан рәнҗетелсә дә закон буенча эш итәргә омтыла. Ул үзен укымышлы, мәгърифәтле, сәясәтне тирән аңлаучы кеше буларак күрсәтеп, органнарны да телсез калдыра. Ул буш сүз йөртми, кыйналуларга бирешми, сыгылып төшми. Төрмәдә сорау алучылардан да куркып калмый, чөнки аның иманы ныклы: "Асылгәрәй хәзрәт бу вәкил дигәннәренең исерек талаучылар икәнлеген сорау алучының күзенә карап әйтте, бу хакта Мәскәүгә дә язачагын белдерде. "Колхозга көчләп кертү булырга тиеш түгел, бу хакта Сталинның махсус мәкаләсе бар – ул "Уңышлардан баш әйләнү" дип атала", – диде ул" [1, б. 20].

Дин Асылгәрәй хәзрәт тормышында иң мөһим урынны алып тора. Аны төрмә дә, репрессия дә, күргән авырлыклары һәм кичергән югалтулары да диненнән ваз кичерми.

"– Әлмәт төбәгендә бер генә мулла калса да, ул мин булырмын, – диде ул нык инану белән. – Дин тотучы бер мөселман калса да, ул мин булырмын, иншаллаһ. Милләткә хезмәт итүче бер укымышлы татар калса да, ул мин һәм минем нәселем булыр Аллаһы теләсә" [1, б. 23].

Ул хәтта үзен корбан итәргә уйлаган мәҗүсиләргә изге сүзен җиткереп карый:

"– Аллаһы Тәгалә бер генә була, оланнар, – диде Асылгәрәй карт, аларга хакыйкатьне җиткерергә уйлап. – Бу җир-суларның, ут-тауларның үзләрен дә Аллаһ барлыкка китергән бит, шуңа күрә дә гыйбадәт кылу бары тик аңа гына булырга тиеш. Корбан да Аллаһ ризалыгы өчен генә бирелә..." [1, б. 144].

Күп еллардан соң гафу үтенергә килгән Шайтан Шакирга да Аллаһтан гафу сорарга куша:

"– Син Аллаһы Тәгаләдән кичерү сора, аның алдында тәүбәгә кил" [1, б. 185].

Сөргеннән туган ягына кайтканда Асылгәрәйгә нинди генә авырлыклар очраса да, ул аларны Аллаһы ярдәме белән кичеп чыга, һәр туган көнен иртәнге намаз белән башлый һәм ястү белән тәмамлый, үзен Аллаһ ризалыгына тапшыра. Юлында нинди генә кешеләр очравына карамастан, ул аларның һәрберсенә Аллаһ исемен җиткерергә тырыша. Монда пәйгамбәрләр белән тәңгәллек тә күрергә була. Асылгәрәй хәзрәтнең әсәрдәге портреты халык күзаллавындагы Хөзер Ильяска туры килә. Ул да ак сакаллы, мәһабәт гәүдәле, сөргендә дә үзенең мәгърурлыгын югалтмаган ир. Яхшылыгы белән кыргый бүрене дә үзенә ияләштерә (Сөләйман пәйгамбәр белән тәңгәллек). Аның каршында зимагурмы, кеше үтерүче мәҗүсиме, ир йөзе күрми картаючы хатын-кызлармы – ул барысына да Аллаһ коллары итеп карый. Һәм ул чәчкән дин орлыклары киләчәктә шытып чыгалар. Ул үзе генә түгел, аның исән калган балалары да Асылгәрәй хәзрәт эшен дәвам итүчеләр булалар.

Асылгәрәй хәзрәт тә, Маһинур абыстай да, аларның балалары да дөньяга дини күзлектән, мәңгелек тормышка бер адым гына итеп карыйлар. Әлбәттә, һәр ата-ана кебек алар да балаларының исәнлеген кайгырталар. Поезда бар булган ризыкны аларга биреп, үзләре ураза тотып баралар. Исән алып кала алмаган балаларын дини йолалар белән күмәргә тырышалар. Исән калганнарын бердәм һәм Аллаһ юлында булырга өндиләр. Шуңадыр, киләчәктә Асылгәрәй хәзрәт нәселе Магниткада дин тоткасына әйләнә.

Асылгәрәй хәзрәт туган ягына Урал тавының кырык сырты аша кайта. Хатынының бәхиллеген алып, аны соңгы юлга озатырга кайтып җитешә. Икенче көнне кабат сөргенгә җибәрелә. Авылына икенче кайтуына инде ул “министрский” кара “Волга”да, зур урында эшләүче кияве, кызы белән кайта. Тормыш җиле ничек кенә бәргәләсә дә, гаделсезлек һәм авырлыклар аягыннан егарга омтылса да, ул төз булып кала, динен дә, милләтен дә бетерергә юл куймый. Туган ягыннан куылып үз-үзен югалтмый, киресенчә, авылы-иле динен, туры юлын югалта.

Әсәрдә фәлсәфи, лирик, публицистик агым әһәмиятле. Алар Асылгәрәй образын ачарга ярдәм итәләр, язучыга тоталитар җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәтләрен тирәнрәк яктыртырга мөмкинлек бирәләр.

Кырык сырт – ул герой кайткан Урал сыртлары гына түгел, ә татар милләте узган каршылыклы авыр юл буларак аңлашыла. Асылгәрәй образы исә халкыбызның меңләгән шәхесләре язмышын чагылдыручы образ буларак гәүдәләнә. Гомумән, әлеге образ яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

Бәйрәмова Ф.Ә. Кырык сырт. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005.

ӘДӘБИ ТӨШЕНЧӘ БУЛАРАК “УТОПИЯ” АТАМАСЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Галиуллин Р.Р., Сәмигуллина С.Н.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия
Урта гомуми белем бирүче 54 нче санлы гимназия, Яр Чаллы шәһәре, Россия

ОСОБЕННОСТЬ ТЕРМИНА «УТОПИЯ» КАК ЛИТЕРАТУРОВЕДЧЕСКОГО ПОНЯТИЯ

Галиуллин Р.Р., Самигуллина С.Н.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия №54», г. Набережные Челны, Россия

В статье рассматривается такой термин как «утопия». Делается экскурс в историю мировой литературы. Рассматривается особенности возникновения и развития утопических произведений.

Ключевые слова: *фантастическая литература, утопия, жанр, социалистический реализм.*

THE PECULIARITY OF THE TERM «UTOPIA» AS A LITERARY CONCEPTS

Galiullin R.R., Samigullina S.N.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia
Municipal budget educational institution "Gymnasium №54" Naberezhnye Chelny, Russia

The article considers such a term as «utopian». To make an excursion into the history of world literature. The peculiarities of the emergence and development of utopian works.
Keywords: *fiction literature, Utopia, genre, socialist realism.*

Утопия иҗтимагый аңның бер формасы буларак үзендә социаль идеалның барлыгына төшенү, җәмгыятьтә яшәп килгән стройны тәнкыйтьләү, караңгы дөреслектән качу, җәмгыять киләчәген матур итеп күрергә омтылу кебек сыйфатларны барлый.

Бразилия архитекторы О. Нимейер: “Мең, кимендә биш йөз елдан соң нәрсә буласына күз төшерү өчен мин бер нәрсәмне дә кызганмас идем... Ул вакытта кешеләр ничек яшәр икән? Бәхетле булырлармы?...”, – дип баш вата [6, с. 189]. Аның теләген тормышка ашыруның бердәнбер юлы – фантастик әсәрләргә мөрәҗәгать итү.

“500 яки 1000 елдан соң кешеләр бәхетле була алырмы?” дигән сорауга фантастика төрлечә җавап бирә. Ул кешеләрдә гуманистик идеал тәрбияләргә омтыла, бәхетле киләчәк өчен эшли: киләчәкнең нинди буласы кешенең үзеннән тора бит.

Фантастлар әсәрләрендә өзлексез үзләре күрергә теләгән киләчәкне түгел, киресенчә, кешеләрне хәвеф-хәтәрдән саклау, кисәтү өчен, күрергә теләмәгән киләчәкне сурәтлиләр. “Моңа мисал итеп америка язучысы Р. Брэдбериның “451° по Фаренгейту” (1953) дигән роман-кисәтүен алырга мөмкин. Әсәрдә трагик парадокс – җәмгыятьнең дәһшәтле картинасы тасвирлана: янгын сүндерүчеләр китапларны яндыру өчен яши. Шулай да Р. Брэдбериның өмет чаткысы сүнми: шуның белән аның романы киләчәктә берни күрмәүче башка авторларныкыннан аерыла да инде. Мондый “кара фантастика” кешеләрне куркыта, рухи яктан коралсызландыра, аларда көрәш дәртен сүндерә.

Фантастиканың бурычы киләчәк өчен көрәшкә генә барып тоташмый, ул киләчәкне генә дә тасвирламый. Фантастлар бүгенге турында да (мәсәлән, Г. Уэллс “Человек-невидимка”), үткән турында да (әйтик, М. Твенның “Янки при дворе короля Артура”) язалар” [6, с. 189].

Бүгенге көндә фантастик әдәбиятның өч жанр төре билгеләнә: гыйльми фантастика, фэнтези һәм социаль фантастика. Социаль фантастикада төп урынны җәмгыятьтәге кешеләр арасындагы мөнәсәбәт алып тора. Фантастик мотивлар куллану җәмгыятьнең гадәти булмаган, чынбарлыкта беркайчан да була алмаслык шартларда үсүен күрсәтә. Социаль фантастикага утопия һәм антиутопия карый, ягъни “идеальда нәрсә була ала” һәм “идеальда нәрсә була алмый” [1, с. 45] .

“Утопия” термины Англия галиме Томас Морның “Дәүләтнең иң камил төзелеше һәм Утопия исемле яңа утрау хакындагы файдалы да, кызыклы да Алтын китап” хезмәтенә (1516) бәйле рәвештә барлыкка килсә дә, беренче утопия авторы дип Платон исәпләнә.

Аның “Дәүләт”, “Сәясәтче”, “Тимей”, “Критий” диалогларында утопиянең төп кагыйдәләре саклана: әсәрдә иҗтимагый барыш белән идарә итү тасвирлана. Утопия Көнбатыш Европада Яңарыш әдәбиятында калыплаша. Утопия идеяләрен Т. Кампанелла (“Кояш шәһәре”, 1623), Ф. Бэкон (“Яңа Атлантида”, 1627) һ.б. дәвам итә.

Россиядә беренче әдәби утопияләр XVIII гасырда дөнья күрә (А.П. Сумароковның “Төш. Бәхетле җәмгыять” (1759) хикәясе). Инкыйлабтан соң фантастик һәм утопик әдәбият үсеше моңарчы күренмәгән колач ала (С.А. Есенинның “Инония” (1918); А.В. Чаяновның “Минем абыем Алексейның крестьян утопиясе иленә сәяхәте” (1920); Л.М. Леоновның “Океанга юл” (1935) һ.б.).

1516 нчы елда Томас Морның танылган утопиясе басылганнан соң, инде йөзләгән утопияләр дөнья күрде. Тик әлеге жанр бүген дә мәгънәсен югалтмады. Әлбәттә, утопия хәзер үзгәрде, роман формасына якынлаша башлады, психологик проза һәм маҗаралы повестьлар казанышларын үзләштерде, шулай да аның максаты Т. Морныкы шикелле – кешеләргә камил җәмгыять турында сөйләү. Чорның иң танылган утопияләреннән берсе – И.А. Ефремовның “Андромеда томанлыгы” әсәре. Әсәр бердәм кешелекнең, социаль гаделсезлекне җиңеп, нинди биеклекләргә күтәрелә алуы хакында.

Урта гасырлар татар әдәбиятында утопиянең бер сыйфатын чагылдыручы гадел идарәче мотивы киң таралган була. Моннан тыш, шәркый әдәбиятларда әсәрләр идарәче, хан, хөкемдарга багышлап иҗат ителә, аның идарә итү рәвешен, дәүләт системасын мактый.

Татарларның дәүләтчелеген югалтуы, әдәбиятта утопия жанр формасы туугa ихтыяҗны бетерә, күрәсең. “XIX-XX гасырлар чиге прозасында утопик мотив буларак сәяхәтнамәләр кысаларында Европа көнитешен һәм иҗтимагый-мәдәни хәл-халәтен югары бәяләү, татарлар өчен үрнәк итеп кую тоемлана, шулай ук хан заманнарын сагыну сизелә. 1920-1930 нчы елларда, башка әдәбиятлардагы кебек үк, татар әдәбиятында да социалистик җәмгыять төзелешен үрнәк модель итеп күзаллау урнаша. Бу модель Ш. Камалның “Матур туганда” романында, М. Әмирнең “Агыйдел” повестенда аеруча актив. 60-80 нче еллар татар әдәбиятында халыкның изге йола-гадәтләрен саклап килгән татар авылын идеаллаштыру, утопик мотив буларак үткәнне сагыну күзәтелә” [10, б. 198].

“Утопия” билгеләмәсен ике төшенчә берләштерә: зур дөньядан (шәһәр, утрау) читләтелгән киңлек, һәм вакыт, дөресрәге, киләчәк [3, с. 263].

Давыдов Т.Т. һәм Пронин В.А. исә: “Парадоксальность утопии в том, что ее “фантастическое будущее” изначально несбыточно с точки зрения антиутопического мира. Впрочем, утопические проекты вполне реализуемы, воплощаясь в идеологии, которая всегда утопична. “Обычно в утопии преобладает социально-бытовая, нравоописательная проблематика...”, – дип фикерлиләр [4, с. 62].

Утопияне өйрәнүче Америка тикшерүчесе Джозеф Ф. Коатс утопия турында болай дип яза: “Если брать утопию как будущее идеальное государство, то ей нет места в современном мышлении. Условия для утопии не существуют сегодня в западном мире и никогда не существовали в незападной традиции... Когда посмотришь на условия мира в любое время, человек находится в одинаковом состоянии – борьба со злом, столкновение с проблемами и стрессами в каждодневной жизни, предчувствие и планирование – катастроф и неудач... Утопии, таким образом, это обычно видение того, каким мог бы быть мир, если бы угрозы, риски и стрессы были удалены” [2, с. 18].

Француз философы Э.М. Чоран үзенең “Механика утопии” дигән мәкаләсендә утопиянең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтә. Утопик әсәрләрдә психологизм җитешмәвен искәртә: “Ее герои – автоматы, игрушки, символы: они всегда неправдоподобны, всегда послушно исполняют роль куклы, идеи, затерянной в безликом мире…” [9, с. 228].

Һәр әдәби жанрның үзенчәлеге, башкалардан аерып торучы сыйфатлары була. Без утопиягә түбәндәге сыйфатлар хас дип билгеләдек:

1. Сурәтләнгән җәмгыять хәрәкәтсез. Бер генә утопист та дөньяны вакыт аралыгы белән бәйләми.

2. Барлык утопияләр дә тулы фикердәшлек белән сугарылган, аларда кешегә гадиләштерелгән караш яши, характерларны индивидуальләштерү, аларны сурәтләүдә системалылык юк.

3. Утопиядә нинди дә булса эчке конфликт юк. Утопик әсәрнең сюжетын дөньяны, аның кануннарын тасвирлау, кешеләр арасындагы мөнәсәбәт тәшкил итә.

4. Җәмгыятьтәге хәлләр алдан билгеләнгән үрнәк буенча бара.

5. Бу җәмгыятьләр тышкы дөньядан тулаем читтә. Утопиядә пространство чикләнгән.

6. Утопиягә, ниндидер идеалга таянып, чынбарлыктан ерак торучы, үз дөньясын тасвирлау хас.

7. Утопияләрдә сатира юк, чөнки аларда идеалны раслау һәм шул идеалны чынбарлыкка каршы кую бара.

Әдәбият галимнәре һәм фәлсәфәчеләр утопиянең түбәндәге төрләрен билгелиләр:

– технократик, ягъни социаль проблемаларны фәнни-техник прогрессны тизләтү ярдәмендә чишү;

– социаль. Монда кешеләрнең үз җәмгыятьләрен үзгәртү мөмкинлеге ачыла.

Социаль утопияләр үзләре ике төргә бүленә: эгалитар, ягъни шәхеснең гармоник үсешен идеаллаштыручы принциплар (И.А. Ефремов, “Андромеда томанлыгы”), һәм элитар – җәмгыятьне хаклык принцибы буенча төзү (А. Лукьянов, “Кара пешка”).

Утопиянең төп үзенчәлеге шунда: анда реаль дөньяны чикләү юк. Аның төп максаты – камиллеккә юл күрсәтү.

Утопиянең бер тармагы буларак социалистик реализмны карарга мөмкин. Совет чоры татар әдәбиятында ул иң киң таралган алымнардан санала.

Социалистик реализм агымы татар әдәбиятында 1917-1932 нче елларда формалаша. Яңа тормышны социалистик идеяләргә нигезләнеп төзү мәсьәләсен үзәккә куйган әсәрләр шушы процессны күрсәтәләр. Татар әдәбиятында ул коммунизмга чиксез ышаныч, оптимизм белән сугарылган. Кешедәге героизм, корбанчылык сыйфатларын данлап, яңа тормыш хакына үзен корбан итүчеләргә сокланып, мәйданга килсә дә, 1932 нче елдан соң социалистик реализм агымы җәмгыять үсешенең бер юлы булган марксистик-ленинчыл концепцияне бердәнбер хакыйкать итеп исбатлауга кадәр үсә. 1956 нчы елга кадәр бу агымга караган әсәрләрдә шартлылык арта бара.

1960 нчы еллардан башлап әсәрләргә аерым кеше гомере-тормышының кыйммәте хакында уйлану килеп керә. “М. Гафуриның “Кызыл байрак” (1917), М. Җәлилнең “Авыру комсомолец” (1924”) шигырьләре, Һ. Такташның “Гасырлар һәм минутлар” поэмасы (1924), Т. Гыйззәтнең “Ташкыннар” драмасы (1937), М. Әмирнең “Агыйдел” повесте (1935), “Саф күңел” романы (1959), “Миңлекамал” драмасы (1944), Г. Бәшировның “Сиваш” повесте (1937), “Намус” романы (1948), Г. Ибраһимовның “Тирән тамырлар” романы (1928), Ш. Камалның “Матур туганда” романы (1937), К. Тинчуринның “Җилкәнсезләр” драмасы һ.б. әсәрләр моңа мисал булып тора. Соңрак язылган әсәрләрдә социалистик реализмга хас сыйфатлар сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрендә генә сакланып, язучыларның реализм таләпләренә җавап биргән әсәрләрне ниндидер идеяләр белән баету омтылышы сизелә. Мәсәлән, Г. Ахуновның “Чикләвек төше”, “Хәзинә” әсәрләре шуны күрсәтә. 1980-1990 нчы елларда татар әдәбиятында бу агым яшәүдән туктый” [5, б. 77-78].

“Социалистик реализм – яңа социалистик идеаллар белән рухланып, социалистик эпоха эчтәлегеннән үсеп чыккан, шул заманга хас сәнгатьчә ихтыяҗларны чагылдырган һәм, кешелекнең иң алдынгы әдәби казанышларын үзләштереп, туктаусыз үсә, камилләшә барган киң колачлы иҗат методы”, – дигән фикер яңгырый Гали Халитнең “Иҗат методы – тылсым түгел” исемле мәкаләсендә [8, б. 229].

Социалистик реализмның асылын тормыш-чынбарлыкны дөрес, тарихи нигездә һәм революцион үсештә тасвирлау тәшкил итә. Ул дөньяны революцион үзгәртеп коруны максат итеп куйган идеологиягә нигезләнә.

“Социалистик реализмның татар әдәбиятында үзенчәлекләре:

– вакыйга-күренешләрне тарихи нигездә һәм революцион үсештә бирү сәбәпле, аларны бизәп, ал буяларга манып сурәтләү һәм шуның белән заман чынбарлыгыннан читләшү;

– дөньяны социалистик үзгәртеп коруга ышану, шуңа омтылу әсәрләрнең идея эчтәлеген билгеләү;

– кеше характерлары, берьяклы һәм бертөрле генә сурәтләнеп, уңай һәм тискәрегә бүленү, үзара каршы куелу;

– конфликтның схематик характеры: 20-30 нчы елларда сыйнфый көрәш теориясенә нигезләнүе; сугыштан соңгы елларда социалистик идеал белән иске гадәтләр арасындагы каршылыкка таянуы;

– кеше шәхесе иҗтимагый идеалга буйсындырылып, идеалның алгы планга чыгуы һәм чынбарлык буларак тәкъдим ителүе;

– социалистик гуманизм һәм социаль оптимизмның төп пафосны билгеләве, югары өслүбкә нигезләнүе” [5, б. 209].

Соцреализм үзенчәлекләренең утопия сыйфатлары белән тәңгәл килүе, соцреализмны утопия жанрының бер тармагы итеп карарга мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, назәри төшенчә буларак утопия – чынбарлыкта булмаган идеаль җәмгыятьне бар итеп сурәтләүче жанр. Утопиядә социаль идеал булу, җәмгыятьтә яшәп килгән кануннарны тәнкыйтьләү, реаль дөньядан качу, җәмгыять киләчәген матур итеп күрергә теләү кебек сыйфатлар чагылыш таба.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Брандис Е.П. Научная фантастика и художественное познание действительности// Художественное творчество. – М.: Наука, 1983. – С. 37-58.
2. Воробьева А.Н. Русская антиутопия XX – начала XXI веков в контексте мировой антиутопии: Диссертация на соискание ученой степени доктора филологических наук. – Самара, 2009. – 585 с.
3. Галиуллин Р.Р. Жанр утопии/антиутопии в татарской литературе XX века// В мире научных открытий. – 2013. – №11 (47). – С. 261-269.
4. Давыдов Т.Т., Пронин В.А. Теория литературы: Учеб. пос. – М.: Логос, 2003. – 232 с.
5. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш., Йосыпова Н.М. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.
6. Новиков В.И. Энциклопедический словарь юного литературоведа. – М.: Педагогика, 1988. – 416 с.
7. Осипов А. Фантастика от А до Я. Краткий энциклопедический справочник. – М.: Дограф, 1999. – 352 с.
8. Халитов Г.М. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1975. – 328 б.
9. Чоран Э.М. Механика утопии// Иностранная лит. – 1996. – №4. – С. 226-232.
10. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

ЗАҺИД МӘХМҮДИНЕҢ АНТИУТОПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ДИНИ МОТИВЛАР

Галиуллин Р.Р., Тухбатова А.Р.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

РЕЛИГИОЗНЫЕ МОТИВЫ В АНТИУТОПИЧЕСКИХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ ЗАХИДА МАХМУДИ

Галиуллин Р.Р., Тухбатова А.Р.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье рассматривается современная татарская литература. Анализируются фантастическая, антиутопическая проза на примере творчества З. Махмуди.
***Ключевые слова**: Татарская литература, фантастика, антиутопия, З. Махмуди.*

RELIGIOUS CONSIDERATION IN ANTIUTOPIAN CREATIONS OF ZAHID MAKHMUDIY

Galiullin R.R., Tuhbatova A.R.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

The article discusses the modern Tatar literature. Analyzed fantastic, anti-utopian fiction as an example of creativity Z. Mahmudi.
***Keywords:** Tatar literature, fantasy, anti-utopia, Z. Mahmudi.*

Язучы, радиожурналист Заһид Мәхмүди татар әдәбиятына 1991 нче елларда үзенең “Профессор Мияугөл” исемле фантастик җыентыгы белән килеп керә [3, б. 128]. Ул күбрәк фантастика жанрында иҗат итә, шулай ук антиутопик әсәрләр тудыра, дини мотивларга мөрәҗәгать итүче автор да. Фантастика – ул фән тарафыннан барлыгы расланмаган яки шик астына куелган табигать күренешләренә яки законнарына нигезләнгән әсәрләр җыелмасы [7, б. 14]. “Антиутопия (грек. anti – каршы, utopia – утопия) – утопик форма яки идеягә пародия...” [4, б. 22]. Утопистлар иҗтимагый һәм әхлакый проблемаларны хәл итү юлларын эзлиләр, антиутопистлар исә кешелек бәхете өчен көрәшүче гади кешенең тормыш юлындагы каршылыклар турында уйланалар.

“Тәмуг чәчәге” повестенда сүз Хикмәт исемле кеше янына Иблис килүеннән башланып китә. Иблис кешене үзе белән алып китәргә җыена, шуңа күрә ул “... хур кызлары, затлы исерткеч эчемлекләр белән вәсвәвәли башлагач, үзем дә сизмәстән, муенына менеп атландым” [6, б. 4]. Хикмәт Иблис белән бик тиз уртак тел таба һәм аның аркасында үлүенә дә карамастан, тәмугта да аның белән дустанә мөнәсәбәтләрдә кала. Ходай аны үз янына чакырып, гамәл дәфтәрен вәземләп карап чыгу турында, анда язылган баш киткеч гөнаһлы эшләрнең бик күп булуын искәртә, шунлыктан хөкем карарын кичектереп тора, элекке төзелеш тресты директоры буларак, ул җәннәтне яңарту эшләрен җитәкләргә тиеш була. Бәлки ул оҗмахка да эләгә алыр иде, әмма танышлык белән генә алынган дипломы аңа бер файдалы эш эшләргә дә мөмкинлек бирми. Ә менә тәмугта ул үз

урынын таба ала. Ул анда рәхәт, тыныч тормыш кына кичереп калмый, ә яхшы эшкә дә урнашып кала ала, Иблиснең үзе белән әшнәлек итә. “Тәмуг чәчәге” дип исемләнгән сәрхүшләр җәмгыятен оештыра. Иблис тәмугта җыештыручы булып эшләгән гыйфритне тунап, тиресен Хикмәткә кидерә, бүлмәсен аңа тапшыра: “йонлач туганыма охшарга тырышып, аның диварларын якты дөньядагы иң танылган җинаятьчеләрнең, наркоманнарның, фәхишәләрнең фоторәсемнәре белән бизәп чыктым. Әлбәттә, Иблиснең иң сәләтле кешеләре Сталин белән Берия кебек залимнәрнең фоторәсемнәрен дә ябыштырырга онытмадым” [6, б. 57]. Бераздан алар кешеләрне бозарга Казан урамнарына чыгып китәләр. Әмма татарларның баш шәһәрендә алардан башка да гөнаһ чәчәк аткан булып чыгуы, Казандагы мәхшәр оясы Иблиснең үзен дә шаккаттыра.

Әсәрнең антиутопик аспектына килгәндә, ул мистик тармакка караган дисәк дөресрәк булыр. Монда дини тәгълиматлар белән аңлатучы күренешләр дә, дини карашларга каршы килүче күренешләр дә бар. Дин кануннары буенча Хикмәтне теге дөньяга алып китүче Иблис түгел, ә Газраил булырга тиеш. Хикмәтнең үлеменнән соң Алла белән очрашып сөйләшүе дини тәгълимәтләргә туры килеп бетми, чөнки Ислам динендә мондый очрашу Кыямәт көнендә генә мөмкин. Ә Аллаһының эш хисабына Хикмәтнең хөкемен йомшартырга вәгъдә итүе гомумән дингә каршы килә.

Безнең фикеребезчә, автор әлеге әсәрдә җәмгыятьтә чәчәк аткан эчкечелек, фәхишәлек, җиңел генә баерга омтылу, Аллаһны бар дип танымау, кеше алдау кебек проблемаларны ассызыклап үтә. Иблис һәм Хикмәт Казанга начарлык эшләргә дип килгәч, (Иблис үзен Иннокентий буларак таныта) бер җыелышта Сөембикә манарасына ай куйдырту мәсьәләсен биредәге картлар хуплаганда, Иблис мондый сүзләрне әйтә: “Милли аң түбән дәрәҗәдә”. Әлеге репликаны алда санап үткән социаль проблемаларның чишелешенә ишарә буларак та карарга була.

Әүлия исемле шагыйрьнең тишек сүчинкәсеннән башка бернәрсә дә булмый, ләкин ул Иблис тәкъдим иткән “Саламандра” ботинкасыннан баш тарта. Әлеге күренешне, култык астына күн папка тоткан зыялы абзый, шагыйрьнең ботинкасын киптерергә фатиры, Тукай премиясен саклар урыны булмаганга күрә бирмиләр дип аңлата. Бу күренеш шулай ук җәмгыятьтәге тигезсезлекне күрсәтә, Аллаһтан курыкмыйча, кеше әйберсен үзләштерүгә мисал булып тора.

Антиутопия өчен иң мөһим шарт дип, чынбарлыктан канәгать булмауны билгеләп үткән идек. Әлеге үзенчәлек Исбах образында киң яктыртыла: “Ул халыклар төрмәсе Рәсәйне инквизиция чорларына кайтарган хыянәтчел большевиклар фиркасенә мәдхия җырлап, кызыл мәсләк өчен үз атасын саткан һәм милләттәшләрен суйган хаиннәрне герой дәрәҗәсенә күтәреп яшәгән Исбах кулына беркайчан да каләм алмаска ант итте” [6, б. 78]. Ул Ходайны бар дип белмичә, большевикларга баш иде. Журналист буларак, җинаятьчел фиркане, аның кылган гамәлләрен мактап, Исбах үз-үзен генә түгел, Аллаһны, үзенең халкын да алдаган булып чыга. Үзенең эчүгә сабышуы, сөяркәсе Майшикәр белән чуалуы да, хатыны Гөлфирәсе өч елдан артык ирле тол хатын булып яшәвенә дә ул канәгать түгел.

Антиутопиянең тагын бер сыйфаты бу әсәрдә ачык чагыла – Иблис белән Хикмәт күргән кешелек дөньясының киләчәге бәхетле булуы һәм, гомумән, булуы зур сорау. “Псевдокарнавал” дип монда тәмугны атарга була [1, б. 78].

“Эзләмә” хикәясендә дини мотивлар чагылыш таба. Бу бигрәк тә кеше җанының кырык көн җирдә йөрүе турындагы кебек мәгълүматлардан күренә. Хикәядәге Югары Акылны Аллаһы Тәгалә дип карарга була, моны автор тарафыннан китерелгән ассоциатив параллель буларак карарга була. Шулай ук кеше җанының үлемсез булуын да күзәтәбез. Хикәядәге төп герой – Мөхәммәт. Ул Артур белән каршылыкка керә, ягъни Югары Акыл булуына ышанмый. Бу конфликтның чишелешен Артурның үлеменә бәйләп карау дөрес булыр. Икенче каршылык – Мөхәммәт һәм Югары Гакыл каршылыгы, бу шулай ук төп геройның Югары Акылга, ягъни Аллаһы Тәгаләгә ышанмавы, аны бар дип танырга теләмәвенә бәйле. Ахырда Мөхәммәт Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышана башлый һәм бу каршылык Мөхәммәтнең Югары Акылга ышана башлавы белән чишелә. Югары Акыл шулай ук метафорик образ буларак чагылыш таба. Кешеләрнең Аллаһы Тәгалә

кануннарына каршы чыгулары, булганыннан артыгын таләп итүләре (җанны кырык көннән артык җирдә яшәтү, лабораторияләрдә саклап калу) – антиутопик әсәрнең дини мотивын тәшкил итә. Мондый халыкның киләчәге әлбәттә инде юк, әсәрдә бирелгәнчә, имансыз кеше Аллаһы Тәгаләнең үзен күргәч кенә, аның барлыгына ышана башлый. Хикәядә сурәтләнгән җәмгыять математиканы башка әйберләрдән өстенрәк күрә. Билгеле булганча, математика белән генә саналган җәмгыятьнең якты киләчәккә ия булуы зур шик астында, дөресрәге юклык дәрәҗәсендә. Һәрнәрсәне сан белән генә исәпләп булмый, саннардан кала кешенең аң, үзаң, Аллаһка ышану кебек төшенчәләр дә булырга тиеш.

"Җен тыкрыгы" повестенда шулай ук дини мотивларга басым ясала. Төп герой – Кафил, элек үзе советлар иле өчен кеше үтереп йөргән, ә бүген аның үзеннән сорау алалар һәм ахырда үлем җәзасына хөкем итәләр. Аның бернинди дә үкенеч хисләре кичермәве, әлбәттә, бик аяныч. Теге дөньяга күчкәч тә, аны кире җиргә җибәрәләр. Икенче тормышында Кафил дөньяга укытучы булып туа. Яңадан тууның максаты: күңелдә мәрхәмәтлелек, миһербанлык хисләре уяту, чөнки укытучы һөнәре – изге һәм җаваплы һөнәр.

Кафилнең яңа тормышы Җен тыкрыгы дигән җирдән башлана. Нәкъ менә шушы урыннарда без "Җен тыкрыгы" повестенда фантастиканың "фэнтэзи" жанрына хас күренешләр күзәтә алабыз [2, б. 6]. Әсәрдә башка галәм булып, Өмет планетасы карала. Планетаның исеменнән үк нәрсәгә дә булса өметләнү бар икәнен күрәбез. Ул галәмдә барсы да башкача, ләкин сәяси яктан безнең тормыш белән аваздаш. Өмет планетасында Советлар Союзы урынына Сәвитләр Берлеге, Татарстан урынына Бөек Болгар дәүләте параллельләре уздырырга була. Бөек Болгар дәүләте чәчәк атучы, алга киткән дәүләт буларак сурәтләнә. Автор әсәрнең төп идеясе итеп бәхетле һәм бай дәүләтне тасвирлауны максат итеп алмый – антиутопия үзенчәлеге. Бу планетада Кафил кабат Илаһи зат белән очраша (әлеге күренешне дини фантастика буларак билгелибез) һәм үзе бер гаепсезгә үтергән кыз баланың исән калган очракта туа алган балаларын күрә. Нәкъ шушы вакытта аның исенә Советлар иленең тугъры колы булып, сукырларча советлар сәясәтенә бирелеп китеп, Аллаһны бар дип белмичә үткән хезмәтче яшәеше исенә төшә. Ниһаять, Кафил вөҗдан газаплары кичерә башлый.

Г. Гыйльманов фикеренчә: "З. Мәхмүдинең әсәрләре, әдәби тәнкыйтьнең гомум фикеренчә, үзенчәлекле стиль-манерада һәм эзлекле милли рухта язылуы белән аерылып тора" [5, б. 5].

Шулай итеп, "Тәмуг чәчәге"н – дини-сатирик фантастика яисә иҗтимагый фантастика буларак карап булса, "Җен тыкрыгы" повесте дини мотивлары булган иҗтимагый фантастикага ачык мисал, "Эзләмә" хикәясе – дини мотивларны үз эченә алган гыйльми фантастика. Һәр әсәрдә диярлек эчкечелек, фәхишәлек, җиңел генә баерга омтылу, кеше алдау, Аллаһны бар дип танымыйча ясалган хаталар, дингә ышанмау кебек дини-иҗтимагый проблемалар күтәрелә; милләтнең киләчәктәге язмышына ишарә ясала, үсеш-үзгәреш яки юкка чыгу юллары күрсәтелә.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Воробьева А.Н. Русская антиутопия в контексте мировой антиутопии: Дис... док. филол. наук. – Самара, 2009. – 585 с.

2. Галиуллин Р.Р. Татар әдәбиятында детективның эволюциясе. – Казан: РИЦ "Школа", 2007. – 160 б.

3. Даутов Р.Н. һәм Рахмани Р.Ф. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б.

4. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

5. Мәхмүди З. Ак болыт: маҗаралы кыйссалар, хикәяләр / кереш сүз авт. Г. Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 239 б.

6. Мәхмүди З. Тәмуг чәчәге. Маҗаралы повесть һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 255 б.

7. Черняк М.А. Современная Русская литература: Учеб. пособие. – СПб., М.: Сага, Форум, 2004. – 336 с.

РОЛЬ РЕЛИГИИ В ВЫБОРЕ ТИПА ПИСЬМЕННОСТИ

Закиров Р.А., Большакова Л.В.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье на примере из истории тюркских народов VIII - XIII вв. доказывается, что выбор того или иного вида письма был обусловлен вероисповеданием. Письмо многим народам пришло вместе с религией. Народы, не исповедовавшие мировые религии, приобрели письменность только в XX веке.

***Ключевые слова**: буддизм, ислам, манихеизм, тенгрианство, христианство.*

THE ROLE OF RELIGION IN CHOICE OF A TYPE OF THE WRITTEN LANGUAGE

Zakirov R.A., Bolshakova L.V.

Naberezhnochelninsky Institute of socio-pedagogical technolologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

The article deals with the problem of a choice of a type of the written language, which was conditioned by denomination. This point of view is based on the examples taken from the history of the Turkic people at the turn of the VIII-XIII centuries. People who did not draw out world religions acquired the written language only in the XIX century.

***Keywords**: buddhism, islam, manichaeism, tengrianity, christianity.*

Великое изобретение человечества – письмо сделало возможным общение людей в широких пределах времени и пространства. При помощи письма люди передавали накопленный опыт из поколения в поколение; без письма невозможно представить развитие общества, цивилизацию. Письмо возникло в эпоху образования союзов племен, государств… Большую роль в создании или заимствовании письменности играла религия. Многим народам письмо пришло именно вместе с религией как средство приобщения к данной религии.

Например, письменность, которой мы сейчас пользуемся, была создана в IX веке с целью распространения христианства (православия) среди славянских народов. Греческий император Михаил III в 863 году поручил православным проповедникам Константину Философу (Кириллу) и Мефодию миссию христианизации южных славян. Свою работу они начали с создания письменности на базе греческого алфавита, чтобы перевести на славянский язык христианские богослужебные книги. Эта письменность позже была названа кириллицей в честь Кирилла.

После принятия христианства в конце X века предки русских начали пользоваться этим письмом. Подвергнутая нескольким реформам кириллица лежит на основе современного русского, украинского, белорусского, сербского и македонского алфавитов [4, с. 20], а также алфавитов большинства народов бывшего СССР. Татары также с 1939 года пользуются этой письменностью, до нее они 10-12 лет пользовались латиницей (яналиф), а с принятием ислама в Волжской Булгарии (начало X века) до 1927 года – письменностью на основе арабской графики.

Предки татар – тюркские народы до арабского алфавита пользовались и другими типами письма, причем выбор вида письменности, как правило, всегда был обусловлен вероисповеданием. Например, самое древнее из дошедших до нас древнетюркское руническое письмо, относящееся к VII - XI вв., памятники которого обнаружены на территории Монголии, Сибири, Восточного Туркестана, Европы, в том числе и в регионе Волго-Камья, в первую очередь обслуживало потребности тюрков-тенгрианцев. Об этом говорят и сами тексты: «*Тенгритег тенгриде болмыш тюрк Билге каган…*» (Небоподобный, неборожденный мудрый тюркский каган – «Памятник в честь Кюль-Тегина»), «*Тенгри анча темиш*» (Тенгри сказал так… – «Памятник в честь Тоньюкука») «*Тенгриде болмыш ил етмиш Билге каган*» (Неборожденный, создавший государство Билге каган – «Памятник Бильге кагану») и др. [5, с. 19, 56, 11].

Проживающие в IX - XIII вв. на территориях уйгурских государств в Восточном Туркестане тюркские народы исповедовали «все тогдашние мировые религии – главным образом буддизм, но у них были исповедники и христианства, и манихейства» [5, с. 139] и других религий. В зависимости от вероисповедования они пользовались разными типами письма: манихейским, согдийским, уйгурским, брахми, эстрангело и др.

Манихейское письмо, заимствованное у местных согдийцев, использовали тюрки, исповедующие манихейство, которое в 762 году стало официальной религией Уйгурского каганата [6, с. 63]. Наиболее крупные, дошедшие до нас памятники этого письма: «Покаянная молитва манихийев», религиозные гимны, назидательные рассказы… Однако манихейство не стало ведущей религией среди тюркских народов Восточного Туркестана и постепенно было вытеснено буддизмом, который с X века стал господствующей религией и существовал в течение пяти веков [2, с. 489; 6, с. 63]. Тюрками-буддистами создана богатая литература религиозного и светского содержания на нескольких типах письма: брахми, согдийском, уйгурском. Тюркских текстов, написанных на древнеиндийской письменности брахми, до наших дней дошло немного. Они, очевидно, переведены с санскрита. Гораздо больше тюркско-буддийских текстов написано на согдийском алфавите. Причем тюрки адаптировали согдийскую азбуку потребностям тюркских языков, в результате появился новый самостоятельный вид письменности, называемый в науке уйгурским письмом. Эта письменность имела статус государственной в Золотой Орде, была заимствована монголами и до перехода в 1941 году на русский алфавит, под названием «монгольское письмо», использовалась в Монголии (в автономном районе Внутренняя Монголия КНР бытует и ныне). На уйгурской письменности создано огромное количество литературы религиозного, медицинского, юридического и др. содержания, стихи. На этой графике написаны даже некоторые манихейские, христианские и мусульманские тексты.

Среди тюркских народов Турфанского княжества были и исповедующие христианскую религию несторианского толка. Они пользовались письмом эстрангело.

1877 году Гаспринский был избран мэром Бахчисарая. Он поставил перед собой поистине исполинскую задачу развития научной основы для успешного развития тюркского национального движения. Как признанный специалист по просвещению, языкам, истории и литературе, Гаспринский был готов взять на себя такую сложную задачу. Особенно широкой, оригинальной и разносторонней для молодого мусульманина

была его политическая подготовка. Во время путешествий Гаспринский испытывал на себе влияние многих зарубежных идеологов, включая русский популизм в славянофильской форме, французский либерализм и умеренный социализм, младотурецкий пантюркизм и немецкий романтизм. Но душа этого «пышущего сада идей» всегда была и будет исламской. По мнению Гаспринского, ни одна значительная политическая доктрина или культурная программа не сможет быть российским мусульманином прямо заимствована из зарубежных идеологий. Ислам должен служить посредником или катализатором, если вообще какой-либо из этих идей суждено быть приемлемой для российских мусульман [2]. Его мысли и предложения по поиску сотрудничества между последователями различных религий и культур имели международный резонанс.

Предложенная им реформа просвещения нашла сторонников и продолжателей не только в самой Российской империи, но и за ее пределами, особенно в Турции, Персии, даже в Индии. В результате реформ Гаспринского образовательный и культурный уровни мусульманской элиты Империи значительно возросли. Ряд мусульманских городов: Казань, Бахчисарай, Оренбург, Баку, Уфа, Троицк – стали достойными соперниками других интеллектуальных и культурных центров – Стамбула, Каира, Бейрута.

Гаспринского занимали три главные проблемы: модернизация мусульманской общины через реформы просвещения; духовное и политическое единение мусульманских тюрков Российской империи; и формы взаимодействия русских мусульман с Западом, представленным в основном Россией [2].

Европеизация татарского общества была просто необходима татарским буржуа для того, чтобы выстоять в конкурентной борьбе с более опытной и сильной русской буржуазией, пользовавшейся к тому же всяческими привилегиями со стороны правительства и его аппарата на местах. Свое отражение получило в общественном течении, известном под названием джадидизм. Организатором этого движения, выступила прогрессивно настроенная интеллигенция, протестующая против затхлой атмосферы социальной действительности той поры. Это движение носило просветительский характер. Гаспринский же на протяжении более 30 лет популяризировал идеи джадидизма среди татарских народов Российской империи [4].

Таким образом, фактически он был творцом – идеологом, и практическим организатором – целого движения в области просветительства среди мусульманских народов России – джадидизма. Именно за эту, просветительскую деятельность он еще при жизни был признан Улуг устазом – Великим учителем. Так величали его культурные представители не только крымских и казанских татар, но и азербайджанцев, узбеков, туркмен, кумыков, уйгур, ногайцев и т.д. Именно за эти заслуги за Гаспринским закрепился почетный титул – Отец нации. Велико было значение и газеты «Терджиман» для бурного развития после революции 1905 года многочисленной периодической печати – газет и журналов на различных тюркских языках. И в этой области Гаспринский был общепризнанным лидером, получившим почетный титул: Аксакал – почетный старейшина [2].

Список использованной литературы

1. Байрамов, Э.З. Великий просветитель российских мусульман Исмаил Гаспринскийи. – 2001 – Режим доступа URL:http://www.mtss.ru/?page=bairamov3

2. Гаспринский, И. Русское мусульманство. Мысли, заметки и наблюдения мусульманина. – Симферополь: Типография Спиро, 1881. Переиздание: Гаспринский Исмаил бей. Русское мусульманство. – Оксфорд, 1985.

3. Керимов, И. На стыке веков. – 1995 – Режим доступа URL:http://www.kitaphane.crimea.ua/ru/node/149

4. Мухаметшин, А.Г. История развития педагогической мысли, просвещения и образования татарского народа в XVI – начала XX вв.: Учебное пособие / А.Г. Мухаметшин. – Набережные Челны: ФГБОУ ВПО «НИСПТР», 2012. – 254 с.

5. Сеймеметова, С. Секреты древнего города. Исмаил Гаспринский (1851-1914) – Режим доступа URL:http://bikz.org/novosti/sekrety-drevnego-goroda-ismail-gasprinskij-1851-1914/

6. Хасанов, М.Х. Муса Бигиев (к 130-летию со дня рождения) / М.Х. Хасанов // Научный Татарстан. Теоретический научно-популярный и информационный журнал. – 2005. – №3 (4) – С. 3-11.

РЕЛИГИЯ В ВОЛЖСКОЙ БУЛГАРИИ КАК ПРЕДПОСЫЛКА СТАНОВЛЕНИЯ И РАЗВИТИЯ ПЕДАГОГИЧЕСКОЙ МЫСЛИ БУЛГАР

Мухаметшин А.Г.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье рассматриваются язычество и ислам как предпосылки становления и развития педагогической мысли в Волжской Булгарии. Духовно-нравственные ценности, заложенные в религиях которые становятся доминирующим мотивом обучения и воспитания подрастающего поколения в Волжской Булгарии. Рассмотрено содержание народной педагогики, народные традиции, особенности национальной культуры. Представлено на рассмотрение актуальные проблемы воспитания подрастающего поколения.

Ключевые слова: *языческая религия, культ предков, ислам, духовно-нравственное воспитание, народные традиции, проблемы воспитания.*

THE RELIGION IN A VOLGA BULGARIA AS A PREREQUISITE FOR THE FORMATION AND DEVELOPMENT OF PEDAGOGICAL THOUGHT OF THE BULGARS

Mukhametshin A.G.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

This article regards Islam and paganism as backgrounds for foundation and development of pedagogical thought in Volga Bulgaria. Spiritual and moral values inherent in religions which are becoming the dominant motive to educate and bring up the raising generation of Volga Bulgaria. Contents of folk pedagogy, national traditions, national culture are under consideration in the article. Actual problems of the raising generation's upbringing are proposed for consideration.

Keywords: *pagan religion, cult of ancestors, Islam, spiritual and moral education, folk traditions, problems of education.*

Несмотря на ранее проникновение в Поволжье (IX в.) мусульманской религии, у булгар сохранились многочисленные пережитки политеума. Древние булгары, как и другие народы, одухотворяли окружающий мир, природу.

Можно предположить, что у древних булгар была вера в 17 божеств, связанных с «деревом жизни» и главным божеством, венчавшим языческий пантеон, как почти у всех древнетюркских народов, был бог неба Тенгре. Его имя встречается в булгарских эпитафиях XIII – XIV в. и в «Кыйссаи Йосыф» Кол Гали. Тенгре представлялся

невидимым антроморфизированным мужским божеством, имеющим атрибуты: неба, солнце, коня, орла, функции: военную, созидательно-хозяйственную, юридическую (справедливость, владение судьбой людей, покровительственная, внушающая страх, карающая, награждающая).

Они были уверены, что Тенгре слышит и видит их деяния, что несправедливое отношение к природе, к старшим, к окружающим вызывает его гнев. Булгары были уверены, что Тенгре обладает всеми человеческими качествами: справедлив, гуманен и милосерден. Они старались выработать такие качества у себя и у своих детей. Образ идола для булгар был не только религиозным реквизитом, но являлся для них своего рода эталоном нравственности, гуманизма, этики.

Тенгре в зависимости от обстоятельств поклонялись, приносили жертвы. Сама суть поклонения Тенгре и проведения магических праздников заключалась не только в воспитании в подрастающем поколении религиозности, но и способствовала воспитанию в подростках уважительного отношения к тем традициям, которые были накоплены народом в процессе жизнедеятельности. Именно через традиции и обряды дети приучались к коллективизму, необходимости дружно жить в семье, с соседями, с односельчанами, в них воспитывались уважительные отношения к старшим.

У булгар с культом Тенгре связывались также ритуальные празднества. В ритуальные условия входили различные формы единоборства: битва на мечах, рукопашная борьба, скачки на конях, различные игры, пляски. Сопровождалось всё это звуками барабанов. Эти праздники не только были ритуалом, но и своего рода экзаменом на зрелость в физическом плане, умения мыслить, находить неординарные решения. В соревнованиях участвовали в основном юноши и девушки. Они держали экзамен перед всем родом. Глядя на них, учились и равнялись и младшие представители молодого поколения. Здесь происходил обмен опытом между поколениями и осуществлялся воспитательный процесс.

Примечателен то факт, что уже в древнейший период на первый план выдвигается всепобеждающая сила добра, подчёркивается бессилие зла. Во всех легендах и преданиях мы видим презренное отношение к злу и насилию.

Булгары поклонялись также родникам, верили в их исцеляющую силу. Такое почитание, в частности, родников - святилищ (в Биляре, Булгаре и др.) можно было наблюдать и у казанских татар. Это явление мы видим в Мадаре – древнем языческом святилище дунайских болгар.

Обожествление рек, озёр, ручьёв, родников имело и воспитательную роль, так как способствовало воспитанию бережного отношения к окружающей среде, или, говоря современным языком, имело место экологическое воспитание подрастающего поколения. Обожествлялись не только реки, ручейки, озёра, но и существовало почитание огня, солнца, дерева. Священным деревом у булгар считался дуб, в котором они видели могущество, мудрость и т.д.

Культ предков способствовал формированию у подрастающего поколения уважительного отношения к старцам, к человеческой жизни, учил гуманным отношениям между соплеменниками.

Культ предков обязывал потомков знать своих предков до седьмого колена. В определённой мере это способствовало сохранению и укреплению родственных отношений между семьями, сохранению рода, истории рода, которое передавалась по наследству.

В булгарском обществе наблюдается особое положение стариков, дедов. Ибн Фадлан пишет: «Если у сына (какого-либо) человека родится ребёнок, то его берёт (к себе) его дед прежде его отца и говорит: «Я имею больше права, чем его отец, на его воспитание, пока он не сделается (взрослым) мужем» [1, с. 137].

Этот древний обычай был распространен у многих народов. Мальчик находился до совершеннолетия у деда и приобретал навыки, мудрость жизни. Например: Царь Алмуш с

уважением относится к словам деда, предков, когда объясняет Ибн Фадлану явления, происходящие на небе [1, с. 134].

Роль языческой религии в воспитании подрастающего поколения в булгарском обществе была огромной. Прежде всего, она способствовала воспитанию любви к окружающей человека природе. Религия давала понять, что человек – дитя природы, он должен покориться ей, соблюдать её законы. Язычество было распространено именно во время формирования государственного строя булгар, когда ещё только-только проявились первые попытки разделения труда. Это время, когда человек полностью был зависим от природы. Природа кормила и одевала человека, она и воспитывала его. А человек в знак благодарности приносил ей жертвы, чтил её законы.

Языческая религия булгар, как и религия ислам, имела свою нравственную систему. Именно в языческой религии были заложены те основополагающие права человека, которые должны выполняться при любых обстоятельствах.

Эта религия, как бы устанавливает для человека систему жизни, основанную на добре и свободную от всего злого.

Языческая религия расширяла кругозор и воспитывала человека в гармонии с природой. Она учила его брать из даров природы все то, что ему необходимо и ничего лишнего, она воспитывала человека как существо нравственное, живущее в тесном контакте с природой, любящее окружающую его среду.

Таким образом, языческая религия булгар способствовала созданию высочайшего уровня нравственности, которая в дальнейшем нашла продолжение в религии ислам. Ислам является новым витком в жизни булгар. Она отличается своей особой организованностью и оригинальностью в области воспитания. Надо заметить, что любая религия вообще предназначена воспитывать человека. Религия ислам представляет собой образец постоянства и стабильности нравственных стандартов, что создаёт возможность для подлинного регулирования и адаптации поведения человека в социальном мире.

Исламизация булгарского общества шла по восходящей линии. Относительно быстрое распространение ислама объясняется тем, что феодализирующееся в социально-экономическом, политическом и культурном отношении булгарское общество было готово для принятия новой монотеистической религии в виде ислама. В конце IX – начале X в. в процессе образования раннефеодальной государственности у булгар наблюдается коренной перелом во всех сферах, общественно-политической и культурной жизни. Завершается переход населения к полной осёдлости, основываются новые города и сёла и т.д. Формирующееся феодальное государство нуждалось в идеологии, соответствующей новой общественно-экономической формации, отвечающей интересам поднимающейся булгарской аристократии во главе с царём, стремящимся к созданию мощного государства путём объединения разрозненных племён и племенных союзов. Этой цели могла служить новая идеология в виде одной из мировых монотеистических религий. Такой идеологией был ислам, т.е. мусульманство, пришедшее на смену к тенгрианству.

Когда мы говорим о распространении ислама, то имеем ввиду главным образом степень исламизации булгарского общества в целом и проникающие параллельно ей явления. Это – педагогическая мысль, социально-экономический строй, тесные торгово-экономические, политические, культурные связи с мусульманскими центрами, архитектура, одежда, нравы, обычаи, система просвещения, наука, художественная литература, метрология и система счёта, календарь и т.д. Ислам стал идеологической основой сближения культуры булгар с культурой народов Востока.

Принятие ислама Волжской Булгарией означало новую эпоху в жизни страны и в развитии педагогической мысли народа. Булгары были приобщены к передовой культуре арабского Востока. Появляется единая письменность, через которую булгары знакомились с наукой и культурой мусульманского мира. В это время арабский халифат переживал период культурного расцвета, здесь находился центр мировой культуры. С принятием ислама в городах Булгарии возводятся мечети, строятся мектебы, медресе и библиотеки. Здесь изучают произведения античных авторов, труды мусульманских учёных. В это время

появляются первые учебные пособия, свои учёные, писатели, поэты. Наступает период расцвета государства.

Булгары воспринимали священное откровение как источник основных знаний, обеспечивало стабильность и постоянство нравственных стандартов и способствовало регулированию поведения. Священное откровение одобряет духовное начало в человеке, любовь и страх к Аллаху, повиновение человека моральным законам без давления извне. Вера в Аллаха и Судный день становится той силой, которая приводит к тому, что человек легко и искренне выбирает нравственное поведение со всей преданностью души и сердца. При этом ложное чувство оригинальности и новшества не обеспечивает никаких моральных добродетелей и не стремится приуменьшить важность общеизвестных нравственных норм, и не преувеличивает важность одних, и не игнорирует других без причины. Оно принимает общеизвестные нравственные добродетели, и с чувством нравственности и соразмерности означает подходящее место и действие каждому из них в общей схеме жизни.

Оно расширяет кругозор человека, его семейные отношения, поведение как гражданина, деятельность в социально-экономических, политических, юридических и общеобразовательных областях. Коран охватывает все стороны жизни семьи и общества, от колыбели до могилы. Нравственные принципы ислама охватывают все сферы жизнедеятельности человека и определяют нравственность как главенствующий. Это гарантирует регулирование жизненных дел нормами морали, а не эгоистическими интересами. Священное откровение формирует у человека систему жизни, основанную лишь на всем хорошем и свободную от всего злого. Жить добродетельно и искоренять порок, стремиться к добру и запрещать зло есть стремление достойное уважения.

Булгарское общество руководствовалось этими идеями. И надо отметить, что нравственные ценности здесь были превыше всего, ибо оно опиралось на Коран. Гильом де Рубурук писал: «Эти Булгаре – самые злейшие соррадины, крепче держащие закон Магометова, чем кто-нибудь другой» [4].

Коран изучался булгарами с малолетства в медресе. И булгары старались придерживаться всех писаний священной книги. Воспитывающая роль ислама подтверждается основными его положениями:

- вера должна быть правдивой и искренней;
- быть готовыми проявить веру в благотворительных поступках по отношению к собратьям;
- быть хорошими гражданами, поддерживающими социальные организации и душа должна быть твёрдой и непоколебимой в любых обстоятельствах [2].

Эти три направления, утверждённые Кораном, твёрдо соблюдались в булгарском обществе. Они были своеобразным образцом, по которому судили о поведении человека и с помощью которого определяли, хорошее общество или плохое. Пример такого суждения создавал ядро, где концентрируются поступки людей, обеспечивая бесконечные возможности для нравственного развития человека.

Ислам является мощным средством воспитания нравственности, гуманности, обращая при этом большое внимание на проблему отцов и сыновей. Ислам, на наш взгляд, близок к решению этой многовековой педагогической задачи. Мы неоднократно встречаем в разных источниках сцены, в которых проявляется особое уважение к старшему поколению, их нередко называет мудрейшими, аксакалами. Старшее поколение являлось и теперь является как бы своего рода аккумулятором опыта сложившейся многими годами практической деятельности.

Уважение и внимание к родителям является важной частью выражения мусульманской веры и особо подчёркивается в исламском учении. В Коране есть такие строки: «И решил Господь, чтобы вы не поклонялись никому, кроме него и к родителям – благодеяние. Если достигнет у тебя старость один из них или оба, то не говори им тьфу! И не кричи на них, а говори им слово благородное. И приклоняй пред ними обоими крыло

смирения из милосердия и говори: «Господи! Господи! Помилуй их, как они воспитатели меня маленьким» [2].

Согласно Корану и Суннам, моральная ответственность распространяется как по отношению к родственникам или другим людям, но и ко всему человечеству, живому и неживому миру, не разрешается все то, что является развлечением.

Принятие ислама булгарами привело к коренным изменениям во всех сферах их жизнедеятельности. Прежде всего, изменения произошли во взаимоотношениях между людьми, которые раньше строились на основе обычаев предков. Такие обычаи назывались гэдэт (по-арабски – адат). На смену отношений, регулируемых законами предков, пришли отношения предопределенные Аллахом. В соответствии с законом ислама булгарин платил ежегодный налог в пользу бедных. Этот налог назывался закят. Собранный закят булгары-мусульмане распределяли между бедными. В этом проявлялось милосердие народа к неимущим.

Ислам выстраивал высокую систему морали опираясь на нравственные качества личности, помогая человеку реализовать свой потенциал, остерегая его от распутства, тирании и непослушания. Святое писание направлено на формирование богобоязненных и преданных своим идеалам людей, обладающих чувством моральной ответственности и способностью к самоконтролю.

Мы можем с уверенностью сказать, что в воспитании подрастающего поколения и в дальнейшем развитии педагогической мысли народа ислам сыграл одну из основных ролей в булгарском обществе:

1. Культура поведения мусульманина, его нравственная культура строго регламентированы законами религиозной этики. Любая заповедь должна восприниматься как необходимое условие нравственного поведения. «Аллах Великий видит каждого, всегда и везде. Человек может скрыть свой поступок от мира, но от Аллаха – никогда. Люди могут не разоблачить, но Аллах разоблачит всегда».

2. Основные требования к нравственному поведению мусульман содержатся в сурах Корана, Сунне и сборниках хадисов.

3. Мусульманин должен хорошо знать, что ему дозволено, и, что запрещается делать, как себя вести в семье, в общественных местах, на работе, в круге друзей и родственников. Ислам строит свои отношения в обществе между его членами на двух принципах: на основе братства и уважения прав личности. Любое высказывание или действие, оскорбляющее эти принципы, ислам считает харамом, т.е. запретным.

4. Основные заповеди ислама:

- не судить никого, будучи в ярости или в радостном состоянии;
- выбирать средний путь между богатством и бедностью;
- восстановить дружбу с тем, кто ее прервал;
- заниматься мыслительной деятельностью в момент молчания;
- раздавать блага и тому, кто не подает руку;
- всегда сохранять во взгляде наставление и внушение;
- быть справедливым.

Эти заповеди в мусульманской среде считаются обязательными. Важным компонентом исламской морали является формирование у мусульманина здорового образа жизни. Мусульманин должен быть здоровым и духовно, и физически. Соблюдение санитарно-гигиенических правил; бережное отношение к воде, пище; чистота внутренняя и внешняя; очищение организма во время поста (уразы); исключение употребления алкоголя и других стимуляторов дает возможность мусульманам вести здоровый образ жизни. Этическая система ислама входила в течение многих веков в сознание мусульман, внося свой вклад в развитие мировой цивилизации, пополняя сокровищницу человеческой мудрости.

Ислам представляет ряд политических прав и охраняет их при любых обстоятельствах. Главным является неприкосновенность человеческой жизни. Ислам утверждает, что жизнь человека священна. Ни при каких обстоятельствах ислам не

разрешает нападать на человека, на женщин, детей, стариков, больных и раненых. Голодный имеет право на еду, раздетый на одежду, раненый на лечение, больной на уход.

Таким образом, на основе анализа и сопоставления двух религий удалось выявить прогрессивные воспитательные стороны языческой религии и ислама. Примечателен тот факт, что эти две религии не стали антагонистически настроенными друг против друга, а, наоборот, взаимно дополнялись, обогащались, что является редким явлением в истории мировых религий и сыграли значительную роль в воспитании подрастающего поколения.

Список использованной литературы

1. Ковалевский А.П. Книга Ахмеда Ибна Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 г.г. [Текст] / А.П. Ковалевский. – Харьков, 1966. – 220 с.

2. Коран / Перевод и комментарии Крачковского И.Ю. – М., 1963. – 177 с.

3. Мухаметшин А.Г. Педагогическая мысль булгар-татар в Казанском крае: VIII – начало XX в. [Текст] / А.Г. Мухаметшин. – М.: НИИ школьных технологий, 2006. – 232 с.

4. Беркутов В.М. Народный календарь и метрология булгар-татар / В.М. Беркутов. – Казань: Татарское кн. изд-во, 1987. – 95 с.

ҮЗГӘРТЕП КОРУ ЕЛЛАРЫННАН СОҢ АКТИВЛАШКАН ГАРӘП - ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫНЫҢ МӘГЪНӘ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Мөхиярова Р.Х.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

СЕМАНТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ АРАБСКО-ПЕРСИДСКИХ ЗАИМСТВОВАНИЙ В ТАТАРСКОМ ЛИТЕРАТУРНОМ ЯЗЫКЕ ПОСТПЕРЕСТРОЕЧНОГО ПЕРИОДА

Мухиярова Р.Х.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье анализируются семантические особенности арабско-персидских заимствований, которые переживают процесс активизации в татарском литературном языке конца XX - начала XXI вв. Часть таких заимствований приобрела в современном татарском языке новые значения или оттенки значений, отсутствующие в языке – источнике, часть употребляется в новых значениях для обозначения новых реалий или замены русско-интернациональных терминов. Многозначные иноязычные слова обычно употребляются только в одном актуальном для современности значении.

Ключевые слова: *активизация, арабско-персидсие заимствования, лексическое значение, семантика, язык-источник.*

SEMANTICAL FEATURES OF THE ARABIC-PERSIAN BORROWINGS IN THE TATAR LITERARY LANGUAGE OF THE POST PERESTROIKA PERIOD

Mukhiarova R.Kh.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

Some semantic features of Arabic-Persian borrowings are analysed in this article, which are in current process of intensification in the Tatar literary language of the late 20[th] and early 21[st] centuries. Some of these eastern borrowings are acquired new meanings or some features of meanings in contemporary Tatar language, which do not exist in the source language; some of them are used in new meanings for determination of new realities or for changing some international terms of the Russian language. Polysemantic foreign words usually have only one meaning, which is actual in the present.

Keywords: *intensification, Arabic-Persian borrowings, lexical meaning, semantics, source language.*

Гарәп-фарсы алынмаларының яңадан активлашуы XX гасыр ахыры –XXI гасыр башы татар әдәби теле лексикасының иң характерлы үзенчәлеге дияргә була. Телебезгә ун гасыр (X-XIX) дәвамында дин, әдәбият аша, сәүдә, фәнни һәм мәдәни багланышлар нәтиҗәсендә өзлексез кереп торган гарәп һәм фарсы алынмаларының күбесе совет власте чорында интернациональ, рус һәм яңа ясалган татар сүзләре белән алмаштырылган иде. Илдә демократик үзгәрешләр башлангач, халыкның милли үзаңы уянуга бәйле рәвештә бу процесс капма-каршы юнәлеш алды: интернационализмнар һәм рус алынмалары урынына яңадан гарәп-фарсы сүзләрен куллану белән мавыгу көчәйде.

Гарәп-фарсы алынмаларының шактые яңа чорда үзләренең элекке мәгънәләрендә генә активлашмады, ә бәлки төрле үзгәрешләр кичерде. Аерым алганда, күп кенә сүзләр яңа иҗтимагый-сәяси һәм икътисадый вәзгыятькә бәйле рәвештә яңа мәгънә төсмере белән баедылар, кайберләре аерым конкрет мәгънәләрендә генә активлашты.

Гарәп-фарсы сүзләренең күбесе үзләренең рус һәм Көнбатыш телләреннән кергән эквивалентларын алыштыру максатында кире кайтарылды. Бу исә аларның кайберләрендә яңа мәгънә төсмерләре туура китерде. Түбәндә шундый сүзләрнең аеруча еш кулланылганнарын карап үтәбез.

Вакыф – соңгы елларда аеруча актив кулланылышка кергән сүзләрнең берсе. Аңлатмалы сүзлекләрдә дә ул “искергән, китап теле сүзе” билгесе белән “Ислам динендә: уку-укыту өчен яки, гомумән, байлар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан ярлыларга <...> матди ярдәм рәвешендә бирелә торган бүләк” мәгънәсендә теркәлгән (ТТАС, 247). Гарәп һәм фарсы теле сүзлекләрендә аның ике мәгънәсе күрсәтелә: “1) дингә бәйле эшләр яисә хәйрия максатларында тоту өчен бирелгән, васыять ителгән мал, милек; 2) тартып алынмый һәм налог салынмый торган милек” (АРС, 907; ПРС, II, 706). Хәзерге татар телендә бу сүз, нигездә, **фонд** алынмасы урынына “матди ярдәм күрсәтү оешмасы” дигән мәгънәдә кулланыла. Күрәсең, вакыф сүзенең телебездә нәкъ шушы мәгънәдә активлашуы төрек теле йогынтысы белән бәйле: төрек телендә дә ул шул ук төшенчәне аңлата (ТТС, 461): *Аларны төрле җәмәгать оешмалары һәм **вакыфлар** (фондлар) оештыра* (З.-Т.). *Бу **вакыф** үсеп килүче илләрдәге иҗтимагый оешмаларның ниятләгән эш проектына акча бирә* (В.Т.).

Гыйбарә алынмасы ТТАСтә “тексттан өзек, өземтә” мәгънәсендә генә теркәлгән (I, 280). ГТРАС һәм гарәп теле сүзлегендә “язылган сүз; әйтем, фраза, сүз тезмәсе” мәгънәләре дә күрсәтелә. Соңгы елларда бу сүз аңлатмалы сүзлектәгедән бигрәк шушы чыганак телдәге мәгънәләрдә кулланыла, шулай ук аны формулировка сүзе урынына файдалану да очрый: *Әйе, “О темперо, о море” дигән латин **гыйбарәсе** юкка тумаган* (М-т). *Преамбула өлешендә Ислам, буддизм һәм яһүд диннәрен дә искә алуны яклап чыктылар һәм шундый **гыйбарә** (формулировка) тәкъдим иттеләр* (М.ж.).

Казый – (*тар*. Шәригать законнары буенча хөкем итүче рухани – ТТАС, II, 22) сүзе соңгы еллар татар әдәби телендә арбитр, рефери сүзләре урынына, ягъни “спорт уеннары судьясы” мәгънәсендә дә кулланыла башлады: *Ярышлар бик яхшы оештырылган иде, секторлар, стадиондагы юллар искитмәле. Югары дәрәҗәдәге **казыйлар*** (Ш.Ч.). Чыганак гарәп телендә бу сүз дини мәгънәдән тыш гомумән судья, хөкем итүче мәгънәләренә ия

булса да, конкрет арбитр, рефери мәгънәсендә башка – хаким, мухаккам сүзләре кулланыла (АРС, 644, 187, 188).

Кануннамә (законнар җыентыгы – ГТРАС, 202) сүзе төрле типтагы закон кулланмаларын атау белән бергә, конституция сүзенең синонимы буларак та файдаланыла: *Китапны татар, башкорт һәм урыс милләтенең һәркайсын милләт һәм дәүләт буларак саклау өчен **кануннамә** (катехизис) дип тә кабул итәргә мөмкин* (М.җ.). *Ә Шартнамә безнең **Кануннамәне**, РФ Конституциясе белән бергә, төп чыганак дип игълан итә* (И-л).

Мәкам – (1) дәрәҗә, тоткан урын; 2) көйле тавыш, көйле тон – II, 418) сүзе элек татар телендә тулысынча диярлек икенче мәгънәсендә генә очраса, хәзер ул беренчел мәгънәсенә яңа төсмер өстәп "хокукый хәл" мәгънәсендә статус сүзе урынына кулланыла: *Украина, мәсәлән, элеккеге Советлар Союзының иярчене Болгария **мәкаменә** (статусына) тиклем төшерелсә, инде башны авырттырмас иде* (И-л). *... Русия эчендә кайбер автономияләр дә үз **мәкамнәрен** күтәрүгә ирештеләр* (И-л).

Мәхәллә (1) шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше; 2) квартал – II, 423) сүзе төп мәгънәләрендә активлашу белән беррәттән, яңа төсмерләр белән баеп, "дини-этник принципта төзелгән оешма", "төп территориясеннән читтә яшәүче халык төркеме" (диаспора) мәгънәләрендә кулланыла: *Анда гаилә кодексы икенче укылышта, милли мәгариф системасын булдыру һәм **мәхәллә** төзү концепцияләре беренче укылышта тикшерелде* (М.җ.). *Татарстанда яшәүче урыс **мәхәлләсе** үзенең милли-демократик парламент партиясен оештыра алса да, Татарстан өчен файдалы булыр иде* (А-к).

Мөнбәр (1) мәчет эчендә мулла, имам хөтбә укый торган баскычлы биек урын; 2) трибуна, кафедра – II, 379) сүзен "трибуна" мәгънәсендә еш куллану анда күчерелмә "дәрәҗәле урын, нинди дә булса иҗтимагый эшчәнлекне башкару чарасы" мәгънәләре пәйда булуга китерде: *Айга ашкан көне булды бу яңа мөхәррирлек **мөнбәрен** яулаган кеше өчен* (А-к). *Әмма матбугат ярдәмендә дан **мөнбәренә** күтәрелгәннәр күпчелек иде* (В.Т.).

Һөнәри сыйфаты фарсы телендә "нәфис, художестволы" мәгънәсенә генә ия (ПРС, II, 731). Ясагыч нигез һөнәр исеме үзе дә, чыганак телендә "сәнгать, осталык, сәнгаткә бәйле шөгыль" мәгънәсен аңлатып та (ПРС, II, 730), татар теленә "эш, кәсеп, профессия" мәгънәсендә алынган кебек, һөнәри дә сыйфат буларак "профессиональ" билгесен белдерә: *Татарстан **һөнәри** уку йортлары 1 миллион 254,5 мең квалификацияле эшче әзерләде* (М-т). Бу сыйфатны исемләштереп, профессиональ сүзе урынына да кулланалар: *Татар телендә иртәгесе көн **һөнәриләрен** (профессионалларын) әзерләү мөмкинме?* (М-ф). Шул ук төшенчәләрне бирү өчен тамырдаш **һөнәрмәнд** (1) һөнәрче; 2) һөнәрле, оста, махсус белемле – III, 827; фарсы телендәге мәгънәсе – художник, сәнгать әһеле – ПРС, II, 1010) сүзе дә файдаланыла: *Хәзер Татарстан рәссамнары берлеге татар хатын-кызлары арасында иң беренче **һөнәрмәнд** рәссам Гайшә Рахманкулова музеен булдыру артыннан йөри* (И-л). *Милиция **һөнәрмәндләре** белән бергә бу көнне... барлык хезмәт коллективлары да билгеләп үтәләр* (Ш.Ч.).

Югарыда каралган сүзләрдә чыганак телдә дә, арадаш телләрдә дә булмаган яңа мәгънә төсмерләре барлыкка килү күзәтелә. Кайбер яңадан активлашкан сүзләр элек татар телендә кулланылмаган, аңлатмалы сүзлектә теркәлмәгән, әмма чыганак яисә арадаш телдә булган мәгънәләрендә дә кулланыла башладылар. Әйтик, мәдәни алынмасы аңлатмалы сүзлектә "культуралы, алдынгы", ә мәдәният "культура" мәгънәсендә генә теркәлгән (II, 417); гарәп, фарсы теле сүзлекләрендә аларның "цивилизацияле", "цивилизация" мәгънәләре аерым күрсәтелә (АРС, 746; РПС, 1013). Цивилизация сүзенең төп "теге яки бу иҗтимагый-экономик формация ирешкән иҗтимагый үсеш һәм материаль культура дәрәҗәсе" мәгънәсеннән тыш, икенче "дөньядагы алдынгы илләрнең хәзерге культурасы, мәдәнияте" (ТТАС, III, 392) мәгънәсенә ия булуын да искә алсаң, мәдәният сүзен цивилизациянең синонимы буларак куллану үзен аклый: *Сез тормыш шартларын яхшыртыгыз, тормышка **мәдәни** мәгънә бирегез!* (А-к). ***Мәдәният** (цивилизация) дигәндә нәрсә күз алдында тотыла соң?* (И-л).

Мәҗмуга сүзе аңлатмалы сүзлектә "җыентык, сайланма әсәрләр" мәгънәсендә теркәлгән (II, 425). Гарәп һәм фарсы телләрендә дә ул шул ук һәм "коллекция"

мәгънәләрендә кулланыла (АРС, 139; РПС, 334, 816). Ә төрек телендә бу сүз "журнал" мәгънәсенә ия (Тур.РС, 256). 90 нчы еллар татар матбугатында да мәҗмуга журнал сүзен алыштыру өчен шактый еш кулланыла, ягъни төрек теле тәэсирендә мәҗмуга сүзе яңа мәгънә алды дип расларга нигез бар: *...“Химия и жизнь” **мәҗмугасында** ... кызыклы бер язма укырга туры килде* (Ш.К.).

Татарча үз атамасы булмаган, моңарчы рус-европа сүзләре белән белдерелгән төшенчәләрне атау өчен, аерым авторлар гарәп-фарсы алынмаларына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Мондый – сүзнең төп мәгънәләре белән бәйләнешле – яңа мәгънәләр өстәүне, шартлы рәвештә, окказиональ кулланыштагы мәгънә киңәю дип атарга була. Телдә ныгып калу мөмкинлеге бар дип исәпләнгән берничә мисал китерәбез: *Бөтенләйгә ташлау – ваз кичү түгел, төп шәхесне, ничектер төплерәк, гыйльми **этрафта** киңрәк дәлилләп яктырту теләге белән* (С-ә) – этраф – *иск.* тирә-як, әйләнә-тирә – ТТАС, III, 687; тарафның күплек формасы булган (АРС, 472) бу сүз "әйләнә-тирә" мәгънәсен "тирәлек, мохит" дәрәҗәсенә кадәр киңәйтеп, среда сүзе урынына кулланылган. *...“Эдельвейс” ширкәте башлыгы Вилсур Садыйков Караваево **вилаятенең** администрациясеннән чакыру ала* (К.у.) – вилаять – өлкә, губерна, провинция, штат (АРС, 913; ГТРАС, 53) сүзе биредә һәм башка кайбер авторларда "район, микрорайон" сүзләрен алыштыра.

Чыганак һәм арадаш телләрдә туры һәм күчерелмә мәгънәдә табышмак төшенчәсен аңлаткан **могаммә** сүзен (РПС, 235; Тур.РС, 264; ГТРАС, 356) "Идел" журналы проблема сүзе урынына куллана: *Ләкин тирәндәрәк яткан зур **могаммәләргә** (проблема) бу ачкыч ярамый иде* (И-л). ***Могаммәнең** субъект ягы да бик мөһим* (И-л).

Өммәт (1) нинди дә булса бер дин тарафдары, бер пәйгамбәр өндәгән диндә булган кеше // бер динне тоткан халык, бер диндәге халык; 2) милләт – ТТАС, III, 703) сүзен этнос төшенчәсен бирү өчен куллану да нигезсез түгел, чөнки чыганак телдә аның беренчел мәгънәсе – гомумән халык (АРС, 42): *Рәсәй чыннан да төрле **өммәтләр** (этнослар) өчен уртак йорт булды* (М-т).

Сәрмая (берәр нәрсәне башлап-корып җибәрү өчен билгеләнгән акча, төп капитал // гомумән, акча, байлык (ТТАС, II, 711) – инвестиция урынына кулланыла: *Белград Косово өлкәсенә шактый гына **сәрмая** кертте* (З.-Т.).

Телебездә соңгы чорда гына ныклап кереп бара торган кайбер алынмаларның, чыганак тел белән чагыштырганда, татар телендә мәгънәләрен тарайтулары, конкретлаштырулары дә күзәтелә. Аңлатмалы сүзлектә теркәлмәгән берәмлекләрдән мондыйларга гамәлият, зиһният, көллият сүзләрен кертергә була.

Гамәлият (гамалия) сүзе гарәп телендә "1) җитештерү, производство; 2) операция (төрле мәгънәләрдә); 3) эш-хәрәкәт, процесс" мәгънәләренә ия (АРС, 542). Соңгы еллар татар әдәби телендә аны, күрәсең, төрек йогынтысында (кара: Тур.РС, 31), нигездә, икенче, "операция" мәгънәсендә кулланалар: *..., хөкүмәт хисабына **йөрәгенә гамалият** ясаткач, Батулла да тынып калды, өстәгеләрне тәнкыйтьләми* (М.җ.). *Америкалы Винона Мелик яман шеш авыруыннан 4 тапкыр **гамалият** ясаткан...*(М.җ.). Сирәк булса да аны беренче мәгънәсендә производство сүзе урынына файдалану очрый: *... **гәмалият** (производство) мөнәсәбәтләренә кагылышлы җөмләләр төзергә маташуым аркасында бөтенләй кыен хәлдә калдым* (А-к).

Зиһният сүзенә гарәп-рус сүзлегендә татарчага төгәл тәрҗемәләү авыр булган "1) склад ума; образ мыслей; 2) умственный уровень, умственное развитие, интеллект" аңлатмасы бирелгән (АРС, 272). Хәзерге татар телендә исә ул конкрет "интеллект" мәгънәсендә кулланышка кереп бара: *Дөресен әйткәндә, бүгенге горур төрек милләтенең **зиһниятен** барлыкка китерүдә безнең бабаларыбыз да олугъ өлеш керткән* (Т.я.). *Беренче чор тәҗрибә туплау, осталык яулау, акыл, **зиһният** уяту вакыты* (К.у.).

Көллият сүзе гарәп телендә "тулылык, бөтенлек; колледж, факультет, югары хәрби уку йорты, университет" мәгънәләренә ия (АРС, 695). XX йөзнең 90 нчы елларында җөмһүриятебездә Көнбатыш илләре үрнәгендә яңа типтагы тулы булмаган югары белем бирүче уку йортлары – колледжлар ачылгач, аларның "татарча" атамасы итеп нәкъ менә шушы сүз алынды: *Югары уку йортлары галимнәре, **көллият** һәм педучилище*

укытучылары төрле курслар буенча укыту программалары эшләделәр (М-ф). ***Көллияттәге** мондый үсеш-үзгәреш уку-укыту эшчәнлегенә уңай тәэсир итте, белем бирүнең сыйфаты яхшырды* (М-ф).

Татар телендә күптән кулланылган **хаким** (1) судья, хөкем итүче, казый // арбитраж; 2) өстенлек итүче...; 3) хуҗа, түрә, башлык... – ТТАС, III, 360) сүзе дә шул чорда конкрет “шәһәр администрациясе башлыгы” мәгънәсендә мэр сүзе урынына кулланышка керде: *Кичә Илдар Халиковның Чаллы шәһәре **хакиме** итеп билгеләнүенә 4 ел тулды* (Ш.Ч.). *Юбилярны гомер бәйрәме белән шәһәр **хакиме** Васил Шәйхразиев тәбрикләде* (Ш.Ч.). Аны башка элекке мәгънәләрендә куллану очраклары юк диярлек.

Димәк, телнең үз сүзләре кебек үк, гарәп-фарсы алынмалары да активлашу процессында мәгънәви үзгәрешләргә дучар ителә икән. XX гасыр азагы – XXI йөз башында күп кенә алынма сүзләр чыганак телдә булмаган яңа мәгънәләр белән баедылар, кайберләре исә чыганак яки арадаш телдә булып та, татар телендә элек кулланылмаган мәгънәләрен үзләштерделәр; аерым авторлар тарафыннан татарча эквиваленты булмаган рус-европа сүзләрен алыштыру өчен көнчыгыш алынмаларын яңа мәгънә төсмере өстәп файдалану да еш очрый. Шул ук вакытта кайбер күпмәгънәле алынмалар чор өчен актуаль конкрет мәгънәләрендә генә активлашалар. Гарәп-фарсы алынмаларының шактые яңа иҗтимагый-сәяси, икътисадый вәзгыятькә бәйле рәвештә яңа мәгънә төсмере белән баеды, кайберләре исә аерым конкрет мәгънәләрендә генә активлашты.

Әдәбият - шартлы кыскартмалар

1. Сүзлекләр

АРС – Баранов Х.К. Арабско-русский словарь. Изд. 5-е, переработанное и дополненное. – М.: Русский язык, 1977. – 944 с.

ПРС, II – Персидско-русский словарь, II том / Отв. ред. Ю.А. Рубинчик. – М.: Советская энциклопедия, 1970. – 848 с.

РПС – Русско-персидский словарь / Под ред. Али Асадуллаева, Л.С. Пейсикова. – М.: Советская энциклопедия, 1965. – 1092 с.

ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

ТТС – Ганиев Ф., Әхмәтьянов Р., Ачыкгөз Х. Татарча-төрекчә сүзлек. – Казан-Мәскәү: Инсан, 1997. – 496 б.

2. Газета-журналлар

А-к – Аргамак
В.Т. – Ватаным Татарстан
З.-Т. – Заман-Татарстан
И-л – Идел
К.у. – Казан утлары
М-ф – Мәгариф
М-т – Мәгърифәт
М.ж. – Мәдәни җомга
С-ә – Сөембикә
Т.я. – Татарстан яшьләре
Ш.К. – Шәһри Казан
Ш.Ч. – Шәһри Чаллы

КЛАРА БУЛАТОВА ШИГЪРИЯТЕНДӘ ДИН ҺӘМ ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ

Мөхиярова Р.Х., Хамматуллина И.И.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

ВОПРОСЫ РЕЛИГИОЗНОГО И НРАВСТВЕННОГО ВОСПИТАНИЯ В ПОЭЗИИ КЛАРЫ БУЛАТОВОЙ

Мухиярова Р.Х., Хамматуллина И.И.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье анализируются вопросы религиозного и нравственного воспитания в творчестве известного татарского поэта К. Булатовой, которая большую часть своей жизни посвятила учительскому труду. Подчеркивается роль современных мультимедийных материалов, составленных с учетом возрастных особенностей детей, в религиозном воспитании подрастающего поколения.

Ключевые слова: *нравственность, поэзия, религия, воспитание.*

QUESTIONS OF RELIGIOUS AND MORAL EDUCATION ARE IN POETRY OF CLARA BULATOVA

Mukhiarova R.Kh., Khammatullina I.I.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

In this article the author analyses religious and moral education problems in the pieces of work of the well-known tatar poet K. Bulatova by name, who devoted the most part of her life to teaching proffession. The author of the article underlines the importance of the modern multimedia materials worked out taking into account the age-related peculiarities of children in the religious education of younger generation.

Keywords: *morality, poetry, religion, education.*

Һәр иҗтимагый чорда шигъриятнең асыл кыйммәте ил тормышына, халык язмышына якынлык, кеше кичерешләрен яңача сурәтли белү һәм сәнгатьчә нәфислек белән бәяләнә. Шул сыйфатларга ия булган шигъри әсәрләр генә, еллар, гасырлар сынавын үтеп, безгә килеп җиткән, һәм һаман да матурлыгын югалтмаган әнә шушы әдәби мирасыбыз киләчәк буын укучысын да уйландырыр һәм рухландырыр.

Безнең көннәр шагыйре дә дәвернең фәлсәфи һәм әхлакый эчтәлегенә тирән үтеп керергә, алдынгы идеалларны аларга бәрабәр форма, калып аша укучысына җиткерергә омтыла. Бүгенгенең һәм киләчәкнең культура байлыгына һәр сүз остасы үз өлешен кертә.

Клара Булатова шигърияткә илленче елларның азагы – алтмышынчы еллар башында үз заманының ашкынулы уй-кичерешләрен, оптимистик күтәренке рухын чагылдырган Яшьлек, Мәхәббәт җырчысы буларак килеп керде [6, б. 65].

“Минем тормыш һәм иҗат юлым бергә башлангандыр, дип беләм: шигырьләрне үзем белә башлаганнан бирле “чыгарам”, ә “язам” түгел”, [2, б. 28] – ди Клара апа “Үзем турында үзем” мәкаләсендә.

Клара Булатова – дистәдән артык шигъри китап авторы. Аның нигездә традицион татар шигыре калыбында иҗат ителгән лирикасында тормышта кайгы-хәсрәтен дә, сөенеч-шатлыкларын да күп күргән хатын-кыз шәхесенең хис-тойгылары, мәхәббәт кичерешләре, гомер турында, туган җир, заман, кеше язмышы, мәңгелек турында фәлсәфи уйланулары, сагыш-әрнүләре сурәтле чагылыш таба. Аның шигъри теле халыкчан гыйбарәләргә, отышлы чагыштыру-метафораларга бай булуы, фикер-хисләренең ихласлыгы белән үзенә тарта.

Тәрбия өлкәсенә зур өлеш кертүче мөгаллимә буларак шагыйрә иҗатында тәрбияви, әхлак тәрбиясе мәсьәләләре күтәрелүе табигый.

Әхлак (әхлякъ) – әхлак, кешелеклелек сыйфатлары, мораль [5, б. 750] дигәнне аңлатса, тәрбия сүзе “карау, карап үстерү” [5, б. 587] мәгънәсенә ия.

Дин һәм әхлак тәрбиясе гаиләдә башлангыч ала. Тәрбия чыганагы булып, беренче чиратта, нәкъ менә ата-ана, гаилә тора. Тик хәзерге бозык заманда тәрбияле, әхлаклы кеше булуы, кешелеклелек, тыйнаклык, сабырлык, вөҗдан кебек сыйфатларга тугры калуы бик авыр.

Бүгенге көн баласында әдәплелек, әхлаклылык, тәрбиялелек кебек сыйфатлар, кызганычка каршы, кими бара. Балалар ата-ана, гаилә, тәрбия кебек кыйммәтләрнең кадерен белми башлады. Бу проблемалар язучы-шагыйрьләр иҗатында да чагылыш тапмый калмый. Шагыйрә Клара Булатова – үзе тәрбия өлкәсендә бик күп көч куйган шәхес. Укытучылар нәселеннән булган әдибә балалар язмышы, аларның тәрбияви, әхлакый башлангычы өчен җан өрә, борчыла.

“Клара Булатова иҗатын шартлы рәвештә ике чорга бүлеп карасак, соңгысында лирик шәхеснең илдә барган үзгәрешләргә, укытучы горурлыгын таптаган сәясәткә, кичәге укучыларның бүгенге әхлаксызлыгына карата җан әрнүен күрәсең”, [4, б. 73] – дип яза филология фәннәре кандидаты Ләйсән Кәшфиева үзенең мәкаләсендә.

Атлас Гафиятов та, шагыйрәнең яшь буынга игътибарын ассызыклый: “Күп кенә шигырьләрендә К. Булатова Ана булып та, бала булып та уйлый. Шуның белән ул буыннар бәйләнешен ныгыта, үткәнне бүгенге белән бәйләп киләчәккә тоташтыра” [3, б. 171].

Яшь буынның киләчәге турында борчылу, уйлану, кайвакыт хафалану шәхеснең рухын телеп үтә. Клара Булатова шигырьләрендә укытучы үз шәкертләренең юлбашчысы, аларны гаделлеккә, намуслылыкка, әхлакый камиллекә әйдәүче, үз көченә ышанган, карашы белән алга омтылган, заман җилләренә каршы күкрәген киереп баскан фидакарь зат булып та, төн йокысыннан бүленеп, һәр баланың өлгереше өчен борчылып, куанып яшәгән аналарча ягымлы, мөлаем зат буларак та күз алдына баса. Ягымлылык, һәр укучыны үз баласыдай якын күрү һәм нечкә шагыйранә юллар белән шушы тойгыны укучы күңеленә җиткерү – Клара Булатованың иҗат үзенчәлеге, шигъри почеркы.

Шагыйрәнең “Яшьләр колагына” дигән шигыре – киләчәк буынга мөрәҗәгать. Әдибәнең әлеге шигыре XIX йөз әдәбияты шагыйре Мифтахетдин Акмулланың “Иң әүвәл кирәк нәрсә иман дигән...” шигыре белән аваздаш дип әйтергә мөмкин. Акмулла кешелеклелекнең 6 кыйммәтен ача: иман, күңел, гакыл, шөкер, әдәп, сабырлык.

Бишенче кыйммәт нәрсә – әдәб дигән,
Әдәб дигән – мәхәббәткә сәбәб дигән;
Көферлек әдәбледә тормагандай,
Әдәбсездә иман тору гаҗәб дигән [7, б. 298].

Клара Булатова да яшьләрне игътибарлы, сабыр булырга, башкаларны хөрмәт итә, аларга юл куя белергә чакыра.

Үзең хаксыз чакта гафу үтен,
Гаебеңне таны тиз арада.
Бер хатасыз тик бер Алла гына,
Тик син Тәңре түгел, шуны аңла! [1, б. 84], – дип шагыйрә Аллаһының барлыгын, берлеген төшендерергә тели. Бүген балаларга дини тәрбия өчен яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән китаплар, аудио-видео язмалар, мультимеда материалларының да күренә башлавы күңелләрне сөендерә, әлбәттә.

Кешеләрдә сабырлык тәрбияләүгә дә зур игътибар бирә әдибә. “Әшәкелек көндә баштан ашты...” исемле шигырендә ул сабырсызлык сыйфатының никадәр тамыр җәюенә сызлана:

Әшәкелек көндә баштан ашты,
Югалта бит йөзен безнең җир!..
Сабырлыкны саклау авырлашты,
И Ходаем, үзең түзем бир [1, б. 99].

Бу шигъри юлларда автор Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, түземлек, сабырлык сорый.

“Хак Тәгалә: “Гафу итәм”, – ди бит” шигырендә дә К. Булатова Хак Тәгалә, дин, догаларга мөрәҗәгать итә.

Гафу итми. Бусы – иң зур гөнаһ,
Табындыра тик бер Ходаем.
“Лә иләһә иллә Аллаһу”, – дип
Кабатлыйбыз шуңа һәрдаим.

Хәзерге чор яшьләренә карата дини тәрбия көчәйсә, җәмгыятебез торышы да яхшы якка үзгәрер иде. Моның өчен баланы кечкенәдән Аллаһы Тәгаләнең бөеклегенә төшендереп үстерү кирәктер. Бар күңеле белән Аллаһыга ышанган бала берәүне дә рәнҗетми, авыр сүз әйтми, начар гамәлләр кылмый, чөнки ул аның барлык кылган эшләре өчен җавап тотачагын белә һәм дөрес юлдан читкә тайпылмыйча атларга тырыша.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, әхлак – кешеләрнең бер-берсенә карата мөнәсәбәтләр нормасы һәм принциплар җыелмасы. Кешене әхлакый яктан тәрбияләүдә Коръән, хәдисләр, әдәбият – чын мәгънәсендә остазлар. Гомеренең күп өлешен балалар тәрбияләүгә багышлаган шагыйрә Клара Булатова үз иҗатында дин, әхлак, тәрбия мәсьәләләрен тирән яктырта. Иманлы, шәфкатьле, мәрхәмәтле, итәгатьле, намуслы шәхес булырга чакыра, шигырьләренең күбесендә Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә, ул кушканча яшәргә кирәклеген ассызыклый. Клара Булатованың шигъри әсәрләре кешелек туплаган рухи байлыкны, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, нәрсә ул яхшы, нәрсә ул яман төшенчәләрен укучыга үтемле итеп җиткерә.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Булатова К.Г. Каурый канат – Җил Атым: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: ТКН, 2006. – 286 б.

2. Булатова К. Үзем турында үзем// Мәйдан. – 2006. – №3. – Б. 28-30.

3. Гафиятов А. Сөйләр сүзләр әле никадәр// Казан утлары. – 2002. – №11. – Б. 170-172.

4. Кәшфиева Л. Шигырьләрдә укытучы шәхесе// Мәйдан. – 2006. – №3. – Б. 71-74.

5. Мәхмүтов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. II том – Казан: Иман, 1993. – 853 б.

6. Рахмани Р. Шигъри кышлар алда әле// Мәйдан. – 2006. – №3. – Б. 65-71.

7. Татар әдәбиятыннан хрестоматия: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. һәм гимназияләренең 9 нчы с-фы өчен/ төз. Х.Й. Миңнегулов, Ш.А. Садретдинов. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 383 б.

ОНОМАСТИКОН ПРОЗЫ ТАТАРСКОГО ПИСАТЕЛЯ ВАХИТА ИМАМОВА

Салахутдинова З.Ф.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Выявлена ономастическая лексика, использованная в художественном мире известного татарского прозаика Вахита Имамова. Исследованы антропонимы, топонимы и этнонимы прозы В. Имамова, освещены особенности функционирования этих средств как идиостилевых черт и установлена целостная ономастическая система писателя. Все это подтверждается текстовым материалом. Определена их идейно-эстетическая и стилистическая роль в создании исторического колорита произведения.

Ключевые слова: *ономастическая лексика, антропонимы и топонимы, этнонимы, стилистическая роль.*

THE ONOMASTIC VOCABULARY IN THE PROSE OF THE TATAR

WRITER VAHIT IMAMOV

Salakhutdinova Z.F.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

The article singles out the onomastic vocabulary, used in the fictional world of a well-known tatar prosaic Vahit Imamov. The article investigates the anthroponemes, toponemes and ethnonemes in the prose of V. Imamov, reveals the peculiarities of functioning of these linguistic means as idiostylistic aspects, defines the whole onomastic system of the writer. The main points are supported by the examples from the text. The authors of the article determine the moral, aesthetic and stylistic value of the mentioned linguistic means in creating a historical colouring in the piece of fiction.

Keywords: *onomastic vocabulary, anthroponemes, toponemes, ethnonemes, stylictic value.*

В области ономастики татарского языкознания особого внимания заслуживают труды Г.Ф. Саттарова, М.З. Закиева, Ф.Г. Гариповой, Л.Ш. Арсланова и др. Как известно, для определения имен собственных в художественных произведениях употребляется термин «поэтическая ономастика» [3, с. 96]. Поэтическая ономастика произведений татарских писателей и поэтов – сравнительно малоизученная область в татарской лингвистике, исследованию которой посвящены отдельные работы Г.Ф. Саттарова, Ф.Г. Гариповой, Д.А. Салимовой, Р.Х. Гарраповой, А.Р. Биктимеровой, С.С. Арслановой, Г.Х. Зиннатуллиной, Л.М. Хамитовой и др.

Как показал лексический анализ, в художественном мире известного татарского прозаика Вахита Имамова ономастическая лексика выступает как заметное, стилистически и семантически маркированное выразительное средство, как яркая примета идиостиля. Однако, несмотря на это, ее функционирование в художественном пространстве писателя до настоящего времени не становилось предметом специального научного исследования.

Цель нашей работы заключается в комплексном исследовании ономастикона прозы В. Имамова, освещении особенностей функционирования этих средств как идиостилевых черт и установлении целостной ономастической системы писателя.

При исследовании антропонимов нами была предпринята попытка выявить генетические пласты ономастикона исследуемых произведений В. Имамова. Ее результатом стало выделение следующих групп антропонимов:

1) имена тюрко-татарского происхождения: *Айсылу* (*ай* ‘луна’ + *сылу* ‘прекрасная’) и др.;

2) имена монгольского происхождения: *Чыңгыз* ‘великий и могучий’ и др.;

3) имена арабского происхождения: *Әкбәр* ‘величайший’ и др.;

4) имена персидского происхождения: *Маһитап* ‘лунный свет’ и др.;

5) имена арабо-персидского происхождения: *Ахияр/Әхияр* ‘последний возлюбленный’ и др.;

6) производные имена с тюркским и арабским компонентами: *Тимер-Мөэмин* (*тимер* ‘железо’ + *мөэмин* ‘мусульманин’) и др.;

7) производные имена с тюркским и персидским компонентами: *Гөлйөзем* ‘красивая, как цветок’ и др.;

8) имена еврейско-арабского происхождения: *Гайса* ‘божья милость’ и др.;

9) имена древнееврейского происхождения: *Иосиф* ‘бог прибавит’ и др.;

10) имена греческого происхождения: *Алексей* ‘защитник’ и др.;

11) имена латинского происхождения: *Устин* ‘справедливый’ и др.;

12) имена древнегерманского происхождения: *Глеб* ‘предоставленный богу’ и др.;

13) имена древнескандинавского происхождения: *Ольга* ‘святая’ и др.;

14) имена древнеславянского происхождения: *Ярослав* ‘ярко + слава’ и др.

Исследование показало наибольшую распространенность в исторических произведениях автора личных имен арабского (48%), древнегреческого (11%) и тюрко-татарского (9%) происхождения, что, несомненно, объясняется хронотопом событий, нашедшим отражение в произведениях писателя, а также мировоззрением общества того периода.

Следует отметить, что в прозе В. Имамова, за исключением исторических произведений, частотность мужских и женских личных имен приблизительно одинакова; в исторических же текстах преобладают мужские имена, с помощью которых автор создает неповторимые образы воинов, защитников Отечества.

Вошедшие в исторические произведения из реального ономастикона женские имена отражают высокие чувства автора к женщине, ее красоте, величию и мудрости (*Зөлфия, Айзирәк, Саҗидә и др.*).

Активно используются как древние, устаревшие в современном литературном языке, имена (*Илбуга, Осланбикә и др.*), так и не устаревшие имена (*Булат, Ләйлә и др.*). Также употребляются антропонимы из легенд (*Алтын* – хан; *Бигеш* – герой легенды, основатель деревень возле Камы *и др.*), встречаются и вымышленные онимы (*Борак и др.*).

Заметный пласт в художественном пространстве писателя занимают имена, фамилии и псевдонимы выдающихся исторических личностей, что в общем-то характерно для всех исторических произведений: *Чыңгызхан*, *Кол Гали*, *Петр I*, *Екатерина II*, *Николай II*, *Ленин*, *Сталин*, *Троцкий*, *Колчак* и др.

Широко представлены в произведених В. Имамова имена богов как традиционных религий, так и языческих, имена пророков, святых: *Аллаһ*, *Тәңре*, *Мөхәммәт*, *Иисус Христос*, *Хозыр Ильяс*, *Изге Мария*, *Перун* и др.

Качественно своеобразную группу антропонимов в пространстве литературного текста автора представляют прозвища людей. Прозвища входят в число «говорящих» имен. Они употребляются с личными именами в постпозиции и препозиции (*Бакыр Зыя* ‘Медный Зыя’, *Сәүбән Мәргән* ‘Саубан Меткий Стрелок’ *и др.*). Нами выделены следующие виды прозвищ:

1) прозвища, выражающие положительные черты характера героя (*Бөркет Саруч* ‘Орёл Саруч’ – храбрый воин, *Аккош Ульяна* ‘Ульяна-Лебедь’ – самая красивая девушка в поселке *и др.*);

2) прозвища, выражающие отрицательные черты характера героя (*Каты кабык Харис* ‘Жестокий Харис’ *и др.*);

3) прозвища, выражающие физические недостатки героя (*Бөкре Карун* ‘Горбатый Карун’ *и др.*);

4) прозвища, связанные с профессией, родом занятий героя (*Адай оста* ‘Адай мастер’, *Озынколак* ‘Лазутчик’ *и др.*).

Если в практичной антропонимике прозвища выполняют вспомогательную функцию в общении, то в рассматриваемых произведениях они являются выразительным средством характеристики действующих лиц, обогащают образы эмоционально-экспрессивными оттенками. Их выбор стилистически обусловлен, автор обращает внимание и на их формальные элементы, и на звуковой облик, и на значение основ.

В ходе анализа словообразовательной структуры антропонимов нами были отмечены:

1) личные имена синтетической структуры, представляющие, в основном, корневые слова (*Гата и др.*);

2) личные имена аналитической структуры, представленные собственно сложными (*Хәсәншәех и др.*), парными (*Нух-Мансур и др.*) и составными словами (*Талиб Шәмси и др.*).

Итак, совокупность различных моделей имен в произведениях В. Имамова создает богатую и целостную антропонимическую систему.

Изучение топонимов показало, что они, как и антропонимы, принимают непосредственное участие в формировании лингвистической структуры художественных текстов. Топонимика писателя включает в себя реальные географические названия, основной функцией которых является создание пространственности, достоверного фона для изображаемых событий. В работе проводится историко-лингвистический анализ 3 групп топонимов: гидронимов, ойконимов и оронимов.

Самую многочисленную группу составляют гидронимы: *Нургали чишмәсе* ‘родник Нургали’, *Мыштым инеш* ‘Тихая речка’, *Әтил* ‘Итиль’, *Идел* ‘Волга’, *Агыйдел* ‘Белая’, *Сөн* ‘Сюн’ и др.; вторую по численности группу – ойконимы: *Болгар* ‘Булгар’, *Биләр* ‘Биляр’, *Суар* ‘Сувар’, *Шайтан шәһәрчеге* ‘Чёртово городище’, *Казан* ‘Казань’, *Мәскәү* ‘Москва’, *Боголюбово* и др.; наконец, третью группу – оронимы: *Елантау* ‘Зилантова гора’, *Җигүле тау* ‘Жигулёвские горы’, *Йомрытау* ‘Круглая гора’, *Таш-билбау* ‘Уральские горы’, *Көбә үзән* ‘Кубань’, *Ямансаз* ‘Страшное болото’ и др.

Поскольку география событий, описываемых В. Имамовым, очень обширна, в его книгах часто встречаются названия крупных географических объектов: *Кавказ*, *Рәсәй* ‘Россия’, *Япония*, *Корея*, *Кара диңгез* ‘Чёрное море’, *Бәхре Хәзәр* ‘Каспийское море’, *Тын океан* ‘Тихий океан’ и др.

Следует отметить, что, в отличие от реальных топонимов, поэтические топонимы выполняют описательную функцию, они не только называют предмет, но и придают ему стилистическую окраску. Топонимы в прозе писателя отражают географию, быт, традиции народа, а также любовь и уважение к родному краю. Топонимические единицы, сохраненные в исторических произведениях, передают современному читателю древние народные названия объектов, исторические изменения, происходившие в названиях. Изученный топонимический материал позволяет выявить отражение социально-экономических, общественно-политических перемен и природных изменений в топонимии региона.

История народов, изображенная в произведениях писателя, является важной составной частью истории человечества. Исторические предки народов, населяющих Поволжье и Приуралье, создали цивилизацию, которая оказала влияние на ход исторических процессов на обширных просторах Евразии. Исследование этнонимов исторических произведений писателя может способствовать прояснению некоторых вопросов этнической истории татарского народа, дать сведения о степени участия тех или иных народов в формировании татар.

Хотя этнические корни татарского народа связаны с его языконесущими компонентами – тюркскими племенами, в произведениях В. Имамова обнаруживаются названия десятков не только тюркских (*алан*, *суар*, *бортас*, *болгар*, *татар*, *башкорт*, *казах*, *чуаш* и др.), но и нетюркских племен и народов (*касога* ‘черкес’, *яс* ‘осетин’, *монгол*, *калмык*, *чин* ‘китаец’, *швед, япон* и др).

Изучение этнических и культурных связей между народами имеет важное значение для восстановления картины этнических контактов в прошлом. Этнонимы исторически обусловлены и представляют ценность, прежде всего как исторические свидетельства.

Итак, ономастическая лексика в художественном мире Вахита Имамова представляет собой самостоятельную сложную систему, несущую в себе отдельные черты истории развития татарского народа и татарского языка с древнейших времен до наших дней. Как и любые другие изобразительные средства, ономастика в прозе писателя выполняет важные идейно-эстетические и стилистические функции.

Список использованной литературы

1. Калинкин В.М. Поэтика собственных имен в произведениях романтического направления. – Одесса, 1989.

2. Карпенко М.В. Русская антропонимика. Конспект лекций спецкурса. – Одесса, 1970. – 42 с.

3. Подольская Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. – М.: Наука, 1988. – С. 96.

4. Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. – 278 б.
5. Саттар-Мулилле Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? – Казан: Раннур, 1998. – 488 б.
6. Хигир Б.Ю. Энциклопедия имен. – М.: ООО изд-во "Яуза", изд-во "ЭКСМО", 2002. – 512 с.

МЕХАНИКА ТРЕЩИН И РАСПАД ИМПЕРИЙ

Сибгатуллин Э.С.

Набережночелнинский институт (филиал) К(П)ФУ, г. Набережные Челны, Россия

В работе проводятся некоторые аналогии между явлениями, законами, имеющими место в естествознании и обществознании.
Ключевые слова: *кристаллические твёрдые тела, трещины, государства, внутренние и внешние деструктивные явления.*

MECHANICS CRACKS AND COLLAPSE OF THE EMPIRE

Sibgatullin E.S.

Naberezhnochelninsky Institute (branch) K(P)FU, Naberezhnye Chelny, Russia

The work carried out some analogies between the phenomena and laws that take place in natural science and social science.
Keywords: *crystalline solids, cracks, state, internal and external destructive phenomena.*

Империя (лат. *imperium* – власть, государство) – государство, имеющее колониальные владения [1]. В данной работе под термином «империя» подразумеваем конгломерации людей, где один народ (или одно государство) господствует над другими народами (государствами) в той или иной форме (колониальной, блоковой, финансовой и тому подобное). Например, в настоящее время можно говорить о существовании мировой финансовой империи США. Главное – есть народ-сеньор (государство) и народы-вассалы (государства) в широком смысле этих слов.

Существует мнение, что в общественных науках нет таких четко сформулированных объективных законов, которые имеют место в естествознании. Наша позиция в этом вопросе заключается в следующем:

- на наш взгляд законы, установленные Аллахом, имеют всеобщий характер;
- процесс познания человечеством сущности этих законов бесконечен;
- в процессе этого познания полезно искать аналогии между законами естествознания и обществознания.

В данной работе проводятся некоторые аналогии между процессами разрушения твердых тел и людских конгломераций (начиная от семьи и заканчивая империями).

Идеальное кристаллическое тело имеет строго упорядоченное расположение атомов, образующих кристаллическую решётку (рис. 1а). Оно имеет так называемую «теоретическую» прочность, которая может быть в сотни раз больше так называемой «технической» прочности, определённой экспериментально. Учёные выяснили, что причиной такого расхождения является наличие дефектов в структуре материала. Внедрения (рис. 1б) и вакансии (рис. 1в) являются нарушениями регулярности строения кристаллической решётки. В «нормальных» условиях такого рода точечные дефекты постоянно зарождаются и исчезают в силу теплового движения (флуктуации). При наличии определенных внешних воздействий процесс идёт в сторону накопления нарушений в структуре материала: дислокации (которые имеют линейные размеры

порядка 10^{-6} м), накопление дислокаций (10^{-5} м), полосы скольжения (10^{-4} м), пустоты (10^{-3} м), большие пластические деформации (10^{-2} м), образование видимых трещин (1÷10 см и более) [2].




Рис. 1.

Рис. 2.

Появление видимой трещины ещё не означает, что тело обязательно разрушится с разделением на отдельные части. На рис. 2 изображена пластина с центральной трещиной длиной $AB=2l$. Дальнейшее распространение трещины существенно зависит от: относительных размеров пластины и трещины; ориентации трещины (от угла α); значения внешней нагрузки p; способности материала пластины сопротивляться трещинообразованию. Например, чем длиннее трещина при других одинаковых условиях, тем меньше значение p_0 критической силы, после достижения которого трещина будет дальше расти [3]. Отметим несколько интересных фактов, имеющих место в процессе роста трещины и разрушения пластины. По мере увеличения значения силы p у кончиков трещины (точки A и B на рис. 2) образуются сравнительно малые области интенсивного разрушения материала, которые на рис. 2 схематически изображены заштрихованными кругами. За счёт этого острия трещины затупляются, большая концентрация напряжений,

имеющая место в точках A и B, уменьшается, условия работы пластины улучшаются. Но эти области интенсивного разрушения материала у кончиков трещины имеют свои условные предельные размеры, после достижения которых трещина получает возможность дальнейшего роста и пластина может разрушиться с разделением на части. При этом образуются новые поверхности вдоль линий AC и BD (рис. 2), на них возникают дополнительные напряжения и потенциальная энергия, связанные с поверхностным натяжением. Линии разрушения AC и BD имеют такие направления и длины, чтобы при разрушении пластины внешние силы совершали как можно меньше работы, а внутренние силы сопротивления материала пластины действовали максимально эффективно, с наименьшей тратой имеющихся ресурсов; при этом образуются как можно меньше новых поверхностей, связанных с разрушением.

Существуют различные способы борьбы с ростом трещин. Например, сверление отверстий у кончиков A и B трещин, устройство «заплаток» 1 (рис. 2).

Как видно из вышеизложенного, даже в поведении «неживой» материи можно обнаружить некоторые признаки рациональности (поведение материи «выгодно» для неё самой). Поэтому, осуждая эгоцентризм людей, необходимо соблюдать определённую осторожность. Возможно, эгоисты подчиняются некоему всеобщему закону, установленному Аллахом.

Относительно мелкие «дефекты» в человеческих отношениях, которые нарушают прочность связей между людьми, в «нормальных» условиях также постоянно зарождаются и исчезают, в силу динамичности нашей жизни. В качестве аналога внедрения (рис. 1б) в семейные отношения можно брать, например, появление любовницы у мужа. В государстве – появление «агентов влияния», шпионов. В качестве аналога вакансии (рис. 1в) можно брать уход мужа из семьи. В государстве – «утечка мозгов» за пределы государства.

Проведём некоторые параллели между разрушением пластины с трещиной (рис. 2) и распадом людских конгломераций. Здесь заметные трещины между частями общества могут появиться в силу различных причин. Перечислим некоторые из них: громадная пропасть между очень богатыми и очень бедными слоями общества; неравенство разных групп людей перед законом; неравное положение разных народов и конфессий в государстве; постоянный обман народа правящими кругами; неразумные реформы; расцвет коррупции и воровства общественной собственности; ослабление экономических связей между различными частями конгломерации людей; наличие «пятой колонны»; чрезмерные амбициозность и властолюбие местных «князей», их подверженность влиянию иностранных государств и продажность; вообще продажность власть имущих (вольно цитируя Филиппа Македонского, можно сказать «нет таких крепостных стен, которых не смог бы перешагнуть ишак, гружёный золотом»); кумовство, «блат»; отсутствие рационального способа передачи власти, когда довольны и приходящий, и уходящий от власти; монополия на власть (в процессе развала СССР партия власти КПСС подверглась мощнейшей атаке как со стороны внутренних, так и со стороны внешних деструктивных сил) и т. д. Иногда, чтобы отвлечь внимание народных масс от своих ошибок, правящие круги искусственно создают напряжение в обществе («маленькая победоносная война», натравливание одних народов на других, амнистии, в результате которых общество «разбавляется» уголовниками и т. п.), не всегда понимая, что они играют с огнём. Как говорится, из искры может возгореться пламя. Весьма отрицательное влияние на внутреннюю прочность государства оказывает деградация института семьи. То, что творится в настоящее время во многих так называемых цивилизованных странах, раньше характеризовалось одним ёмким словом «блуд». Периодические кризисы, имеющие внешние или внутренние причины и делающие богатых мгновенно в два раза богаче (как минимум), а бедных – в два раза беднее, ведут также к росту напряженности в обществе, к потере веры в справедливость. В итоге может создаться ситуация, когда «низы не хотят, а верхи не могут». Большую опасность для крепости государства представляет образование специфической прослойки людей между властью и народом. Эта прослойка поёт

дифирамбы власти, истинное положение вещей до власти не допускает, имеет большое влияние на власть и большую выгоду от своего положения. В результате власть может «бронзоветь». В случае серьёзного политического кризиса упомянутая прослойка может предать власть, оставить её один на один с разозлённым народом. Особо следует отметить деструктивное влияние внутриконфессиональных распри и падения авторитета религиозных институтов в обществе.

Внешние силы, как правило, работают на распад государств-конкурентов (империи, какую бы форму они не имели, – колониальную, блоковую, финансовую или другую, всегда конкурируют между собой за «мировое господство»). Виды внешних воздействий подробно перечислять не будем, назовём только наиболее существенный из них – внешняя военная агрессия (например, нападение нацистской Германии на СССР). Влияние внутренних и внешних деструктивных явлений и сил может совпасть как по времени, так и по интенсивности их действия. Тогда может возникнуть «эффект резонанса».

Как может противостоять государство на рост трещин в его теле и на распад путем разделения на части? Первое – убрать вышеперечисленные деструктивные явления. Это аналогично упрочнению материала пластины (рис. 2). Можно и «просверлить» наиболее конфликтные зоны общества (аналоги точек A и B на рис. 2), вплоть до проведения «контртеррористических операций». Можно поставить упрочняющие заплатки (аналог заплаток 1 на рис. 2) в виде, например, финансовых вливаний сторонникам единства государства в зоне конфликта. Можно ослабить отрицательное влияние внешних сил путём умелой дипломатической деятельности, или аналогичными внешним угрозам контрдействиями, разумно оценивая при этом общую ситуацию и свои потенциальные возможности (важно не переборщить, следуя поговорке «не буди лихо, пока оно тихо»).

Если деструктивные силы берут верх, то людская конгломерация распадается на отдельные, «независимые» друг от друга, части. При этом, в отличие от «неживой» материи, разделение не всегда происходит с наименьшими потерями для отдельных частей. Некоторые супруги разводятся очень конфликтно, а некоторые – довольно спокойно. Некоторые народы объединяются и расходятся довольно спокойно (например, Норвегия и Швеция, Чехия и Словакия), а некоторые – очень тяжело (например, народы бывшей Социалистической Федеративной Республики Югославии). Можно предположить, что большие конфликты, возникающие при распаде империй, противоречат неким общим законам, установленным Аллахом. Если вместе жить невозможно, расходиться нужно спокойно.

Следует отметить, что не все внедрения имеют отрицательное влияние. Например, на рис. 1г показана кристаллическая решётка, содержащая в своём составе упорядоченную систему атомов двух разных веществ («нанокомпозит»). У таких материалов могут появиться новые свойства, отличные от свойств составляющих веществ (они могут быть прочнее, с лучшей электропроводностью и так далее). Аналог в обществе – появление нужных для страны иностранных специалистов, спортсменов-легионеров, «гастарбайтеров» и т. п. Общество состоит из примерно одинакового числа представителей мужского и женского полов.

Обратимся к законам Ньютона. Первый закон (закон инерции) действует как в природе, так и в обществе. Чем больше масса тела, или размер страны, тем больше у них инерция. Например, движущийся прямо грузовик нельзя резко повернуть направо, или налево, – грузовик может упасть на бок. Аналог – попытка резко перестроить общество в СССР, в результате которой он развалился. Согласно второму закону Ньютона, ускорение тела прямо пропорционально силе и обратно пропорционально массе тела. У команды М.С. Горбачёва не хватило сил, чтобы дать ускорение такому массиву, как СССР. Согласно третьему закону Ньютона противодействие равно действию. Нацистская Германия, попробовав действовать против СССР силой, получила в итоге такое противодействие, в результате которого потерпела сокрушительное поражение.

В заключение ещё раз подчеркнём, что, на наш взгляд, существуют всеобщие законы, которые частным образом проявляются в природе и в обществе. Вернее сказать,

человек, в силу ограниченности своих возможностей, не может охватить эти законы целиком, а видит их отдельные, часто искажённые разумом человека, стороны. Большему познанию этих законов может способствовать, на наш взгляд, признание абсолютной воли на всё Аллаха, обуздание чувства гордыни в себе, постоянные любознательность и трудолюбие.

Список использованной литературы

1. Словарь современных иностранных слов: Справочное издание. Ред. – Комарова Л.Н. – М.: Рус. яз., 1992. – 740 с.

2. Партон В.З. Механика разрушения: От теории к практике. – М.: Наука, 1990. – 240 с.

3. Сибгатуллин Э.С. Трактат о критериях разрушения в механике трещин // Проектирование и исследование технических систем: Межвузовский научный сборник. Вып. 5 (19). – 2012. – С. 5-19.

РИЗА ФӘХРЕДДИН ИҖАТЫНЫҢ ТӘРБИВИ ӘҺӘМИЯТЕ

Сөләйманова Х.Х.

“79 нчы лицей-интернат”, Яр Чаллы шәһәре, Россия

ВОСПИТАТЕЛЬНОЕ ЗНАЧЕНИЕ ТВОРЧЕСТВА РИЗЫ ФАХРЕДДИНА

Сулайманова Х.Х.

“Лицей-интернат №79” г. Набережные Челны, Россия

Современная образовательная система ставит целью воспитать образованного, компетентного человека. Автор статьи представляет произведения Р. Фахреддина как актуальные для достижения данных целей, предлагая пример из личного опыта работы на уроках и внеурочной деятельности.

***Ключевые слова**: произведения Р. Фахреддина, духовно-нравственное воспитание, татарская литература, нравственность, воспитание личностных качеств, совершенная личность.*

EDUCATIONAL VALUE OF RIZA FAKHREDDIN WORKS

Sulaymanova H.H.

“Litsey-internat №79”, Naberezhnye Chelny, Russia

Modern educational system aims to raise educated, competent person. The author presents works of R. Fakhreddin as relevant to achieve these goals these days by offering an example from personal experience at lessons and extracurricular activities.

***Keywords**: R. Fakhreddin works, spiritual and moral education, Tatar literature, morality, education of personal qualities, perfect personality.*

Кешелекнең киләчәге, Ватан язмышы, гаилә бәхете киләчәктә гражданин булачак баланың менә бүген нинди тәрбия һәм белем алуына бәйле. Бүгенге балаларыбыз тагын берничә елдан соң нинди кеше булыр, ата-бабаларының лаеклы дәвамчысы була алырмы?

Заман мәктәпләр алдына түбәндәге бурычларны куя: катлаулы, һаман үзгәреп торучы шартларда яшәргә, эшләргә, социаль кыйммәтләр системасында үз урынын табарга сәләтле шәхес тәрбияләү. Мәктәп, андагы укыту-тәрбия процессын Риза Фәхреддиннең бүгенге милли мәгариф өчен дә әһәмиятен югалтмаган педагогик хезмәтләреннән башка күз алдына китерү һич тә дөрес булмас иде. Чөнки галимнең өйрәтүләре бүгенге заман таләпләренә дә аваздаш.

Риза Фәхреддин – укытучылык һөнәренә гомере буе тугрылыклы булып калган шәхес. Ул педагогиканың нечкәлекләрен шулкадәр тирән белеп, искиткеч күп мәгълүматлар туплап, үзенең актуальлеге белән бүген дә тиңе булмаган һәм һәр укытучының өстәл китабы булырлык бик күп хезмәтләр язган. Р.Фәхреддин күтәргән проблемалар бүгенге көндә дә актуаль яңгырый. Аның хезмәтләре һаман үз кыйммәтләрен керсез саклап, төпле акыл, бәһасез фикерләр белән баетып торалар.

Р. Фәхреддин эшчәнлегенең асылы – камил шәхес тәрбияләү. “Кеше булу өчен, гыйлем белән күркәм холык кирәктер, һәм боларны бер-берләреннән аеру дөрес булмас”, – ди ул. Аның тәрбия-әхлак мәсьәләләренә багышланган китаплары – “Тәрбияле ана”, “Тәрбияле ата”, “Тәрбияле бала”, “Гаилә”, “Нәсыйхәт” бүген дә зур әһәмияткә ия. Чын шәхес тәрбияләү – кешелекнең мәңгелек проблемасы. Балаларда милли үзаң тәрбияләү, татар теленә мәхәббәт уяту, рухи дөньясы бай, физик яктан камил шәхес тәрбияләү хәзерге көндә дә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала [1, б. 38].

Мин – Яр Чаллы шәһәренең 79 нчы лицей-интернатында татар теле һәм әдәбияты укытучысы, сыйныф җитәкчесе. Безнең лицейда бары тик ир егетләр генә белем ала. Коллективыбыз да күбрәк ир егетләрдән тора. Аларның һәрберсе начар гадәтләрдән азат булган, һәрвакыт үзенең белемен күтәрү өстендә эшләүче һәм яхшы тәрбия алган шәхесләр. Коллективыбыздагы җылы, үзара ихтирамга корылган мөнәсәбәт укытучы һәм укучы хезмәттәшлеге өчен дә иң әһәмиятле шарт булып тора, минемчә. Без балаларны халык педагогикасы нигезендә тәрбияләүгә зур урын бирәбез. Халык педагогикасының асыл нигезе Р. Фәхреддин мирасында чагыла. Шунлыктан галимнең мирасын өйрәнү һәм аны укыту-тәрбия эшчәнлегендә куллану системага салынган. Методик берләшмә утырышларында галимнең бай мирасын яшь буынга җиткерү, әлеге темага укучылар белән төрле фәнни-эзләнү эшләре алып бару тәҗрибәсе өйрәнелә. Укытучыларыбыз барысы да дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш чараларда галимнең бай мирасын белем һәм тәрбия бирү чарасы буларак кулланалар. Сыйныфтан тыш уку дәресләре исәбенә Р. Фәхреддиннең иҗат мирасы тагы да тирәнрәк өйрәнелә. 6-7 нче сыйныфларда “Тәрбияле бала нинди була?” дигән темаларга сыйныф сәгатьләре, 8-9 нчы сыйныфларда галимнең “Шәкертлек әдәбе” китабы буенча дәрес-диспут, ә 10-11 нче сыйныфларда Р. Фәхреддиннең тормыш юлы, педагогик карашлары турында дәрес-лекцияләр уздырыла. Ул дәресләрдә киләчәктә эти кеше булачак егетләребез өчен галимнең тәрбия өлкәсендә киң кулланылыш табарга тиешле тәгълиматлары әңгәмәләрнең төп нигезе булып тора. Мәсәлән, “Булдыра алсаң, галим бул, бу эш насыйп булмаса, шәкерт вә гыйлем эстәүче бул, бу да булмаса, гыйлемне дус күр”, “Сәламәтлек – байлык, әдәплелек – камиллек, тәүбә итү – бәхет, күркәм холык – яхшы иптәш”, “Кеше өчен иң бәхетле вакыт – башкалар өчен яхшылык кылу сәгатьләредер”, “Ялкаулык рәхәтлек китерми, өстәвенә гомерне кыскарта” һ.б. Мондый дәресләр уздырганда укучылар фикер йөртергә, әхлакый нормалар турында уйланырга, сыйныфташларының, яшьтәшләренең теге яки бу сыйфаты турында уйланырга, анализ ясарга өйрәнәләр, тел байлыклары арта, әхлак сыйфатлары үсә. Укучыларның күңеленә “кешенең матурлыгы – аның тәрбиясендә, эшчән, намуслы булуында, олыларны олы итеп, кечеләрне кече итеп яши белүендә” икәнлеге һәр дәрестә сеңдерелә [2, б. 109].

“Бала – өстенә һәртөрле бизәк төшерү мөмкин булган бәһале җәүһәр, яки һәрнәрсәне язарга яхшы булган ак кәгазьдер ... әгәр файдасыз бизәк белән мәгънәсез язу язылса, әлбәттә бизәкче белән язучы гаепле булыр”, – дип язган Р. Фәхреддин. Лицеебызда балаларның иҗади сәләтләрен үстерүгә дә зур игътибар бирелә. Укучыларның иҗади активлыгын, сәләтләрен үстерү юнәлешләренең берсе – аларны бәйгеләргә тарту, фәнни эзләнү-тикшеренү эшләре алып барырга өйрәтү. Укучыларны 7 нче сыйныфтан ук фәнни-

эзләнү эшенә тарту да системага салынган. Укучыларыбыз ел саен үз иҗади эшләре белән шәһәребездә уза торган “Фән җилкәннәре”, “Ломоносов укулары”, “Без тарихта эзлебез”, “Болгар илем – гүзәл җирем” республикакүләм фестиваль, конфереңияләрдә уңышлы чыгыш ясыйлар, төрле дәрәҗәдәге дипломнарга лаек булалар. Гомумән, укучыларыбыз гыйлемнең әһәмиятен аңлап, тырышып укыйлар. Ә бу үз чиратында мөгаллим эшенең күркәм нәтиҗәсе дә булып тора.

Һәркемгә мәгълүмдер, тәрбия эшен мәктәп һәм гаилә кулга кул тотынып алып барса гына ул нәтиҗәле була. Ата-аналар җыелышларында “Гаиләдә әхлак һәм хезмәт тәрбиясе”, “Тәрбиядә ата кешенең роле”, “Тәрбиядә гаиләнең роле”, “Гаиләдә хатын-кыз” дигән темаларга сыйныф җитәкчеләре чыгышлар ясыйлар. Мәшһүр галимебезнең: “Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас”, – дигән сүзләре белән ата-аналар җыелышларын башлап җибәрү гадәткә керде. “Ата-ана әхлаклы булса, бала бәхетле була”, – дип, борынгылар бик тә дөрес әйткәннәр. “...Балаларны изге итү юлы ничек? Изге балалар күктән төшмиләр, бәлки гаиләләр эчләрендә җитешәләр. Аның юлы исә – яшь вакытларыннан башлап яхшы тәрбия бирүдер. Бу эш – ата-ана өстендәге иң олуг бурычтыр...” – дип язган Р. Фәхреддин үзенең “Җәвамигуль-кәлим шәрхе” дигән хезмәтендә. Галимнең язып калдырган киңәшләре белән һәрбер сыйныф җитәкчесе ата-аналарны таныштырырга тиеш дип саныйм. Без даими рәвештә укчыларның өйләрендә булабыз, аларның гаилә хәлләрен, тормыш шартларын күзәтеп торабыз. Шулай ук лицеебызда ата-аналар катнашында үткәрелә торган чараларның да әһәмияте бик зур. Ул эти-әниләрнең туган көннәрен үткәрү, 7-8 нче сыйныф укучыларының ата-аналары белән үткәрелә торган “Танышу. Дуслык” кичәләре, төрле ел вакытларында үткәрелгән спорт чаралары, табигатьтә бергәләп ял итү, Корбан ашлары, Әниләр көне, Әтиләр көне һ.б. Аларда милли традицияләргә, гореф-гадәтләргә, Р. Фәхреддин нәсыйхәтләренә зур игътибар бирелә.

Шул ук вакытта укытучыларыбыз камил шәхес тәрбияләүдә мәктәпнең роле, укытучының абруе зур икәнлеген тоеп эшлиләр. Р. Фәхреддин дә бит яшь буынны тәрбияләүче укытучыларга зур таләпләр куя. “Бер мөгаллим – никадәр галим вә никадәр зирәк булса да булсын, гүзәл холык иясе булмаса һәм дә гүзәл холкын вәгазьләренә яраклаштырып һәм фигыле белән күрсәтмәсә аның укытуыннан файда күрелмәс. Файдасы торып торсын, бәлки зарар күрелер!” – дип язган галим үзенең “Әдәбе тәгълим” дигән хезмәтендә. Галимнең әлеге хезмәте укытучыларыбызның өстәл китабы булып тора дисәм дә ялгыш булмастыр. Димәк, без укытучылар үзебез тәрбияле, акыллы, тирән белемле, ихлас, җитди әзерлекле, чиста күңелле кешеләр булырга тиешбез. Шул вакытта гына без үзебезнең куйган максатыбызга ирешербез, яшь буынга дөрес тәрбия бирербез.

“Укытуның нигезе – тәрбия... Тәрбия булмаган җирдә ... гүзәл кеше дә җитешмәс”, – ди Р. Фәхреддин. Ул җәмгыятькә лаеклы алмаш, лаеклы шәхес тәрбияләү мәсьәләсендә гомере буена уйлана, бу бик мөһим мәсьәләгә бер яклы гына карамыйча, аның кешене бөтен яктан да камил итеп күрәсе килә. Галимнең тәрбия өлкәсенә караган хезмәтләре бүген дә педагогика фәнен үстерергә, камилләштерергә, төрле уку йортларында укытуның сыйфатын яхшыртырга, яшь буынны тәрбияләргә, өлкән яшьтәгеләрнең, ата-аналарның педагогик осталыкларын арттырырга булышлык итә. Ул дәвамлы булсын, илкүләм югарылыкка күтәрелсен.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин тәгълиматы: эзләнүләр һәм тәҗрибә. – Яр Чаллы: ӨПББИ, 2006. – 88 б.

2. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. V кисәк. – Казан: РИЦ “Школа”, 2009. –168 б.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДАГЫ ГАРӘП-ФАРСЫ ЧЫГЫШЛЫ АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ

Хаҗиев Р.И.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

НАЗВАНИЯ ДЕРЕВЕНЬ АРАБО-ПЕРСИДСКОГО ПРОИСХОЖДЕНИЯ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

Хазиев Р.И.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье исследуются названия деревень арабо-персидского происхождения в Республике Татарстан. Автор дает развернутую классификацию ойконимов по генетическому признаку. Делается вывод об особенностях ойконимических групп.

Ключевые слова: *Республика Татарстан, топонимика, топоним, ойконимика, ойконим, арабо-персидские названия.*

THE NAMES OF VILLAGES OF ARAB-PERSIAN ORIGIN IN REPUBLIC OF TATARSTAN

Khaziev R.I.

Naberezhnye Chelny Institute of social-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

In the article are investigated the names of villages of arab-persian origin in Republic of Tatarstan. The author gives the deployed classification of oykonyms on a genetic sign. The author gives the conclusion about the features of oykonymyc groups.

Keywords: *Republic of Tatarstan, toponymyc, toponym, oykonymyc, oykonym, arab-persian names.*

Топонимика фәненең үтә дә кызыклы, үтә дә мавыктыргыч бер өлкәсе бар. Ул – ойконимика.

Ойконимика – телебездәге барлык төр торак пункт атамаларын (авыл, шәһәр, поселок, хутор, станция һ.б. исемнәрен), аларның килеп чыгышы мәсьәләсен өйрәнә. Һәрбер торак пунктның үз исем-атамасы бар. Аны ***ойконим*** дип атыйлар. Ойконимнар төрле юллар белән ясалалар: я кеше исеменә, я берәр тарихи вакыйгага нигезләнәләр, я шушы төбәкнең географик үзенчәлекләрен чагылдыралар һ.б.

Татарстан республикасында яшәүче халыкның урнашу тәртибенә килсәк, моның бертөрле генә булмавын күребез. Әйтик, 2003 нче елгы мәгълүматларга күз салсак, 2790600 (74,2 %) кеше шәһәрләрдә, 970300 (25,8 %) кеше авылларда гомер кичергән. 2004 нче ел башына республикада 3120 торак пункт булган. Шуларның 20се республика буйсынуындагы шәһәр, 21е шәһәр тибындагы поселок һәм 3079ы авыл [1, б. 91].

2005 нче елда нәшер ителгән “Татарстанның Көньяк-көнчыгыш Кама арьягы ойконимиясенә этнолингвистик анализ” (Казан) хезмәтендә телгә алынган төбәктәге авыл-

шәһәр исемнәрен этнолингвистик яссылыкта берникадәр өйрәнгән дә идек [4]. Әлеге мәкалә шушы эшнең дәвамы булып тора.

Биредә безнең максат – гарәп-фарсы чыгышлы яки алар катнашында ясалган ойконимнарны өйрәнү-барлау.

Хәзер исә кайбер торак пункт атамаларын карап үтәрбез.

1. Гарәп чыгышлы ойконимнар:

Ир-ат исемнәре белән:

Абдул Сәлман – Әлки районындагы татар авылы. Сәлман елгасының югары агымында утыра.

Атама ике гарәп чыгышлы исемгә нигезләнеп ясалган:

1) *Абдул ~ Абдулла ~ Габдулла* – "Аллаһ колы";

2) *Сәлман* – "сәламәт".

Әбсәләм – Ютазы районындагы татар авылы. Ык елгасы буенда урнашкан.

Гарәп генезислы *Әбессәлам* антропонимы "тынычлык атасы" мәгънәсенә ия.

Әҗмәкәй – Тукай районындагы татар авылы. Чулман елгасының сул кушылдыгы Шилнә суы ярында утыра.

Әҗмәкәй антропонимын гарәп чыгышлы *Әҗмемөхәммәт* исеменең кыскартылма формасы буларак карый алабыз:

1) *Әҗме* – "матур";

2) *Мөхәммәт* – "мактаулы".

Әлеге ояга Апас районындагы *Әҗем*, Актаныш районындагы *Әҗмәт* авыллары атамаларын да кертеп карарга мөмкин.

Әлмәт шәһәре һәм Сарман районындагы *Әлмәт* исемен йөртүче татар авылы атамасы да *Әлмөхәммәт* антропонимының кыскаруы нәтиҗәсендә ясалган.

Әмир – Чирмешән районындагы татар авылы. Олы Сөлчә елгасының югары агымында урнашкан.

Шунысы кызыклы: гарәп чыгышлы *Әмир* ("боеручы, әмер бирүче") сүзен сословие термины һәм антропоним буларак та карарга мөмкин.

Әхмәт – Минзәлә районындагы татар авылы. Брустанка елгасы буенда утыра.

Әхмәт исеме гарәп телендә "иң мактаулы" дигән мәгънәгә ия.

Базаровка – Бөгелмә районындагы разъезд.

Атама фарсы *базар* ("базар көне, бәйрәм көн") ойконимик терминына нигезләнеп ясалган.

Бәкер – Бөгелмә һәм Лениногорск районнарындагы татар авыллары.

Гарәп генезислы *Бәкер* исеме "яшь, саф" мәгънәсен белдерә.

Төбәктә шушы исемне йөртүче атаклы "Бәкер" ял йорты урнашкан. Бу – халыкның яратып ял итү урыны. Бирегә Татарстан республикасыннан гына түгел, ә Россиянең башка төбәкләреннән дә киләләр.

Вәли – Лениногорск районындагы татар авылы.

Вәли исеме "изге, хакимлек итүче" мәгънәсен аңлата.

Габдрахман – Әлмәт районындагы татар авылы. Дала Зәе елгасы янында урнашкан.

Габдрахман антропонимын ике мөстәкыйль компонентка тарката алабыз: *Габде* ("кол") + *Рахман* ("Аллаһынын бер исеме"), ягъни "Аллаһының колы".

Гали – Әгерҗе районындагы татар авылы.

Гарәп исеме *Гали* "бөек" дигән мәгънәгә ия. Аллаһының бер эпитеты буларак та мәгълүм.

Камай – Менделеев районындагы татар авылы.

Камай – гарәп *Камалетдин* ("диннең камиллеге") исеменең кыскартылма формасы.

Тарихтан безгә *Камай шәһәрчеге* булуы да билгеле. Ул хәзерге Биектау районындагы *Камай* авылы янында урнашкан булган. Биредә археологик эзләнүләр дә оештырылган.

Минзәлә – Минзәлә елгасының Чулманга койган урынында урнашкан.

Җырларда җырланган *Минзәлә* атамасы үзендә нинди серләр саклый соң?

Профессор Г.Ф. Саттаров фикеренчә, кайчандыр бу урында Болгарга сәүдә белән килүче гарәпләрнең тукталыш пункты – *минзәлә* була. Бу хакта бер риваятьтә дә сөйләнелә. Риваятьтәге мәгълүматларның чынбарлыкка туры килүе бик тә ихтимал. Идел буе болгарлары ераклыкны көнлек юл һәм айлык юл берәмлекләре белән үлчәгәннәр. Гарәпләр ара ераклыгын махсус үлчәү берәмлеге – *мәнзел, мәнзил* белән исәпләгәннәр [2, б. 77-78]. Бер мәнзел 87 чакрымга тиң булган.

Мөслим – шул исемдәге район үзәге атамасы.

Гарәп теленнән үтеп кергән *Мөслим* исеме “мөселман” мәгънәсен аңлата. Ислам динендәге хатын-кызга *мөслимә* диләр. Татарларда *Мөслимә* дигән хатын-кыз исеме дә кулланыла.

Салих – Баулы районындагы татар авылы. Оренбург өлкәсе – Татарстан республикасы чигендә урнашкан.

Салих (гарәп) – “яхшы, изге”.

Хәсән – Кукмара районындагы татар авылы.

Хәсән (гарәп) – “игелекле, матур”.

Хәсәншәех – Арча районындагы татар авылы.

Гарәп чыгышлы *Хәсәншәех* исеме ике компоненттан тора: *Хәсән* “игелекле, матур” + *Шәех* “аксакал, дин башлыгы”.

Хатын-кыз исеме белән:

Әйшә – Яшел Үзән районындагы рус-татар авылы. Казан – Түбән Новгород юлында урнашкан.

Гарәп генезислы *Гайшә* исеме “тере” мәгънәсенә ия.

Өйрәнүләр барышында гарәп генезислы фамилияләргә нигезләнеп ясалган авыл исемнәре дә очрады. Мәсәлән:

Вахитов – Кукмара районындагы татар авылы.

Антропоойконимны түбәндәгечә таркатабыз: *Вахит* (гарәп) – “бердәнбер; беренче бала” + *-ов* – фамилия ясагыч кушымча.

Мостафин – Сарман районындагы татар авылы. Зәй-Сарман юлында урнашкан.

Мостафа (гарәп) – “сайлап алынган; иң яхшы” + *-ин* – фамилия ясагыч кушымча.

2. Фарсы чыгышлы ойконим:

Ир-ат исеме белән:

Азат – Аксубай районындагы татар авылы. Кече Сөлчә елгасы бассейнында урнашкан.

Фарсы чыгышлы *Азат* ир-ат исеме “ирек, ирекле, азат” мәгънәсенә ия.

Татарларда *Азат* антропонимы белән янәшә *Ирек* дигән ир-ат исеме дә кулланылышта йөри.

3. Төрки-гарәп чыгышлы ойконимнар:

Акбулат – Чистай районындагы татар авылы. Багана елгасы ярында урнашкан.

Атаманы *ак* һәм *булат* компонентлары кушылмасы буларак карыйбыз. *Ак* “белый” мәгънәсендә кулланылса, гарәп чыгышлы *булат* сүзе “яхшы, чыдамлы корыч” дигән мәгънәне белдерә, ягъни “ак корыч”.

Аллабирде – Тәтеш районындагы татар авылы.

Ойконим нигезендә гарәп-төрки-татар *Аллабирде* (“Аллаһ бирде”) исеме ята.

Төбәктәге күп кенә ойконимнар составындагы антропонимнар янәшәсендә төрки чыгышлы *иске, түбән* кебек топокомпонентлар очрый. Алар торак пунктның нигезләнеш вакыты, урнашу урыны хакында өстәмә мәгълүмат биреп киләләр.

Иске Абдул – Тукай районындагы татар авылы. Игәнә елгасы бассейнында урнашкан.

Ойконим төрки *иске* һәм гарәп *Габдулла* (“Аллаһ колы”) топонигезләреннән гыйбарәт. *Иске* компоненты авылның нигезләнеш вакыты турында хәбәр итә.

Әлеге компонент башка ойконимнар составында да очрый:

Иске Әлмәт – Мөслим районындагы татар авылы.

Иске Әхмәт – Сарман районындагы татар авылы. Минзәлә елгасы ярында утыра.

Әлмәт ~ Әлмөхәммәт, Әхмәт исемнәренең этимологиясен югарыда карап үттек инде.

Иске Сәет, Яңа Сәет – Мөслим районындагы татар авыллары. Төбәк халкы сөйләвенә караганда, Яңа Сәет авылын Иске Сәет авылыннан күчеп килүчеләр нигезләгәннәр.

Яңа Сәет – танылган татар шагыйре, Г. Тукай премиясе лауреаты *Дөлфәт (Зөлфәт) Маликовның* туган авылы.

Сәет (гарәп) – “башлык, әфәнде”. Ул титул һәм антропоним буларак та кулланыла.

Иске Солтангол – Актаныш районындагы татар авылы.

Солтангол: Солтан (гарәп) – “дәүләт җитәкчесе” + *гол* (төрки-татар) –“кол”: “солтан колы”.

Иске Шөгер, Яңа Шөгер – Лениногорск районындагы татар авыллары.

Шөгер (гарәп) – “акыл, аң; сәләт”.

Түбән компоненты да торак пунктның түбәнлектә яки елганың түбәнге агымында урнашуы хакында хәбәр итеп килә. Мәсәлән:

Түбән Сәлман – Әлки районындагы татар авылы. Сәлман елгасының түбәнге агымында урнашкан.

Гарәп чыгышлы *Сәлман* антропонимы “сәламәт” мәгънәсен белдерә дигән идек.

4. Төрки-фарсы чыгышлы ойконимнар:

Ак Чишмә – Арча, Әлмәт, Ютазы районнарындагы татар авыллары.

Ойконимның беренче компонентын төсне белдерүче төрки-татар *ак* (“чиста, үтә күренмәле”) компоненты тәшкил итә. *Чишмә* гидронимик термины исә фарсы телендәге *чәшмә* “күз” сүзенә мөнәсәбәтле.

Түбән Гәрәй – Актаныш районындагы татар авылы. Шәбез елгасының түбәнге агымында урнашкан.

Гәрәй (фарсы яки төрки-татар) – “теләк; кодрәтле”.

5. Төрки-яһүд-гарәп чыгышлы ойконим:

Иске Ибрай – Аксубай районындагы татар авылы. Кече Сөлчә елгасында урнашкан.

Иске – төрки компонент + *Ибраһим ~ Авраам* (яһүд-гарәп) – “халыклар атасы”.

6. Гарәп-монгол-төрки-татар чыгышлы ойконим:

Тукай районының Оргыды елгасы бассейнында *Салих-Тукай* исемен йөртүче бик тә матур бер авыл урнашкан. Аның атамасы түбәндәгечә аңлатыла ала: *Салих* (гарәп) – “сәламәт” + *Тукай* (төрки-татар-монгол) – “ризыклы-нигъмәтле бул; туганкай; тугай; монголча *тукай* – “җәя”, “салават күпере”.

Гомумән алганда, безнең тарафтан 46 авыл атамасының килеп чыгышы өйрәнелде. Тикшеренү нәтиҗәләрен түбәндәге таблица ярдәмендә тәкъдим итәбез:

№	Авыл исемнәренең килеп чыгышы төре	Саны	Процентларда
1	Гарәп чыгышлы ойконимнар	28	61 %
2	Фарсы чыгышлы ойконим	1	2 %
3	Төрки-гарәп чыгышлы ойконимнар	11	24 %
4	Төрки-фарсы чыгышлы ойконимнар	4	9 %
5	Төрки-яһүд-гарәп чыгышлы ойконим	1	2 %
6	Гарәп-монгол-төрки-татар чыгышлы ойконим	1	2 %
	Барысы:	46	100 %

Өйрәнелгән торак пункт атамаларының шактый зур өлеше (41 атама) антропонимик чыгышлы булуы ачыкланды (89 %). 1 атама ойконимик (2 %), 4 атама гидрографик (9 %) терминга нигезләнеп ясалганнар.

Татарлардагы кеше исемнәренең генезисын тикшерү белән ономаст Г.Ф. Саттаров шөгыльләнә. Аның “Татар исемнәре ни сөйли?” (Казан, 1998) дигән татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге безгә гарәп-фарсы чыгышлы исемнәрнең мәгънәләрен ачыклау барышында да ярдәм итте [3].

Авыл атамалары – шул төбәктә яшәгән халыкның, аның теленең тарихы ул. Без аларны барларга, өйрәнергә һәм сакларга тиеш!

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Иванова Е.Е., Галимов Ш.Ш., Гайсин И.Т., Мустафин М.Р., Хусаинов З.А. Экономическая и социальная география Республики Татарстан: Учебное пособие / Под. ред. И.Т. Гайсина. – Казань: Изд-во КГПУ, 2005. – 250 с.
2. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы. – Казан, 1984.
3. Саттар-Мулилле Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: Раннур, 1998. – 488 б.
4. Хаҗиев Р.И. Татарстанның Көньяк-көнчыгыш Кама аръягы ойконимиясенә этнолингвистик анализ: Уку кулланмасы. – Казан: РИЦ «Школа», 2005. – 168 б.

ИСЕМ – КЕШЕ ХОЛКЫНЫҢ КӨЗГЕСЕ

Хаҗиев Р.И., Фәтхетдинова Л.Ф.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

ИМЯ – ЗЕРКАЛО ЧЕЛОВЕЧЕСКОГО ХАРАКТЕРА

Хазиев Р.И., Фатхутдинова Л.Ф.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Данная статья представляет собой анализ поэтических антропонимов арабо-персидского происхождения в романе-трилогии Ф. Садриева “Счастье несчастных”. Делается вывод об особенностях функционирования антропонимов в составе художественного произведения.

Ключевые слова: *антропонимы арабо-персидского происхождения, Ф. Садриев, роман-трилогия “Счастье несчастных”.*

NAME – MIRROR OF HUMAN NATURE

Khaziev R.I., Fatkhutdinova L.F.

Naberezhnye Chelny Institute of social-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

This article is an analysis of poetic anthroponyms Arab-Persian origin in the novel-trilogy of F. Sadriev "Happiness accidents". The conclusion about the features anthroponyms functioning as part of a work of art.

Keywords: *anthroponyms of the Arab-Persian origin, F. Sadriev, the novel-trilogy "Happiness accidents".*

Телебездәге барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнү белән *ономастика* тармагы шөгыльләнә. Ономастика үзе *антропонимика*, *топонимика*, *космонимика*, *зоонимика*, *теонимика*, *поэтик ономастика* һәм башка шундый бүлекләргә аерымлана.

Безне биредә поэтик ономастика бүлеге кызыксындыра. Әлеге чагыштырмача яшь юнәлешнең өйрәнү объекты нәрсәдән гыйбарәт соң? Бу сорауга төрлечә җавап бирү бар.

Профессор Г.Ф. Саттаров “Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики” хезмәтендә хәл ителергә тиешле максат-бурычларның берсе буларак матур әдәбият әсәрләрендә урын алган ялгызлык исемнәрнең (антропоним һәм топонимнарның) поэтик-стилистик үзенчәлекләрен өйрәнүне күрсәтә [2, с. 86-87]. Ул поэтик ономастика төшенчәсен матур әдәбият әсәрләренә һәм әдәби каһарманнарга исем бирү сәнгате дип билгели [3, б. 180].

Татар поэтик ономастикасы тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән әле. Аерым язучыларның поэтик ономастикасын өйрәнү бездә шактый соң башланды. Шушы өлкәдә хезмәт куйган галимнәрдән Г.Ф. Саттаров, Д.Ә. Сәлимова, Р.Х. Гаррапова, А.Р. Биктимерова, Р.И. Хаҗиев һәм башкаларның исемнәрен атарга мөмкин.

Эшебезнең тикшерену **объекты** булып, Фоат Садриевның “Бәхетсезләр бәхете” роман-трилогиясе [1] тора, ә өйрәнү **предметы** – шушы әсәрдә кулланылган поэтик антропонимнарның үзенчәлекләре.

Мәгълүм булганча, язучылар әдәби образларга исем сайлаганда очраклы исемнәр кушмыйлар, ә аларның характер сыйфатын ача торганын (образга туры килгәнен) куярга тырышалар. Ф. Садриев та шундый (“төптән уйлап эш итә торган”) язучыларга керә.

Гомумән, әдәби образның исеменнән чыгып, аның характерына хас сыйфатларны табарга була. Мәкаләбезнең темасы да шушы өлкәгә карый. Бу мәсьәлә хәзер дә **актуальлеген** югалтмый, чөнки Фоат Садриев бүгенге көндә яшәп иҗат итүче язучы. Ул замана белән бергә атлый. Аның әсәрләрен укып, бәлки, бүгенге чор кешесе балаларына шул исемнәрне бирәдер. Замана үзгәргән саен, исемнәр дә үзгәрә бит. Ф. Садриев та геройларына исемнәрне замана таләпләренә туры китереп сайлый.

Хәзер әсәрдәге кайбер исемнәрнең генезисын карап китәрбез. Әйтик, исемнәр арасында гарәп-фарсы чыгышлылары күп табылды. Мәсәлән:

Әнвәр (гарәп) – “бик нурлы, бик якты”.

Давыт (гарәп-яһүд) – “сөекле, үзенә җәлеп итүче”.

Зирәк (фарсы) – “үткен акыллы; зирәк”.

Илһам (гарәп) – “дәрт, иҗади дәрт, рухлану, илһам”.

Мөнир (гарәп) – “яктыртучы; яктылык чәчүче; нур өләшүче”.

Рашат (гарәп) – “1. Акыллылык. 2. Дөрес фикердә тору. 3. Акылның өстенлек итүе. 4. Дөрес юл”.

Рәҗәп (гарәп) – “Һиҗри елның җиденче аеның (сугышу тыелган айлардан берсе) исеме. Шул айда туган ир балага кушылган”.

Төрки-татарларда кулланыла торган исемнәрнең зур бер өлеше Ислам диненә мөнәсәбәтле. Бу 922 нче елда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителү белән бәйле.

Ислам – өч бөтендөнья диннәренең берсе (*буддизм* һәм *христиан* дине белән бергә). Ул VII гасырда Гарәбстан ярымутравында барлыкка килгән.

Ф. Садриев иҗатында да Ислам дине белән бәйле исемнәр күп очрый. Мәсәлән:

Мөхәммәд ~ Мөхәммәт (гарәп) – “1. Макталган, мактаулы, данлыклы. 2. Ислам диненә нигез салучы Мөхәммәт пәйгамбәр исеме”.

Димәк, Мөхәммәт исеме үзенең генезисы белән *Мөхәммәт (Әхмәт ибн Габдулла)* пәйгамбәр (570-632) исеменә барып тоташа.

Мөхәммәт – Аллаһының пәйгамбәре һәм 631 нче елда Гарәбстанда беренче мөселман дәүләтенә нигез салучы.

Харис (гарәп) – “1. Игенче, сабанчы, сукачы. 2. Сакчы, саклаучы, яклаучы”.

Шакир (гарәп) – “шөкер итүче, рәхмәт әйтүче; бар булганына риза кеше; рәхмәтле, кеше кадерен белүчән”.

Романда кушма төзелешле исемнәр дә шактый. Мәсәлән:

Сәфәргали исеме ике компоненттан гыйбарәт: *Сәфәр + Гали*.

1. ***Сәфәр*** (гарәп) – “1. Юл йөрү; сәфәр. 2. Һиҗри елның икенче ае исеме. Сәфәр аенда туган балаларга кушылган исем”.

2. **Гали** (гарәп) – “1. Бөек, олы, югары дәрәҗәле; кыйммәтле; куәтле, көчле, кодрәтле. 2. Һәрнәрсәдән өстен һәм бөек, Аллаһының эпитеты”.

Айсылу (болгар-төрки) – “ай кебек сылу, чибәр, күркәм; ай сылуы, чибәре”.

Составында гарәп чыгышлы ***дин*** (“инану, ышану”) сүзе булган шактый гына кеше исемнәренең асылында да Ислам динен зурлау, аңа табыну, буйсыну мәгънәсе ята. Мәсәлән, әсәрдәге ***Сираҗетдин*** (“дин яктысы, дин чырагы”) исеме – шундый антропонимнарның берсе.

Ислам диненә мөнәсәбәтле гарәп исемнәренең байтагы ***-алла/-улла*** (“бар вә бер”, “тәңре, хода, хак”) сүзе катнашып ясалган. Мәсәлән:

Галимулла (гарәп) – “барысын да белүче Аллаһ”.

Нурулла (гарәп) – “Аллаһ нуры, яктысы”.

Хәлиулла (гарәп) – “Аллаһ биргән бизәк, асылташ”.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: Ф. Садриев үз әсәрендә Ислам дине белән бәйле исемнәрне актив һәм уңышлы куллана. Ләкин бу гади бер куллану гына түгел, ә язучы шул исемнәр аша безне дөрес фикерләргә, күренешләргә бәя бирергә, тормышны һәм сәнгатьне аңларга ярдәм итә, зәвыгыбызны тәрбияли. Биредә танылган педагог Ә.Н. Хуҗиәхмәтовның акыл тәрбиясе хакындагы фикере кызыклы: “Акыл тәрбиясе тәрбия эшенең иң әһәмиятлеләреннән санала. Акыл тәрбиясе әхлак тәрбиясе белән тыгыз бәйләнештә тора, чөнки әхлаклылык кешенең дөньяга карашы һәм идея инанганлыгы нигезендә барлыкка килә” [5, б. 285].

Мәкаләбез ахырында Гомәр ага Саттаровның канатлы сүзләре урынлы булыр: “Кеше исемнәре ... үзләрендә телебезнең борынгы сүзләрен, грамматик күренешләрен мул саклаганнар. Боларда халыкның борынгы теле, тарихы, тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, материаль һәм рухи культурасы эзлекле чагыла. Димәк, ономастик берәмлекләр тел чаралары белән, сүз белән бәян ителгән тарихны, исем-атамаларда саклану һәм гәүдәләнү тапкан тарихны тәшкил итәләр” [4, б. 10].

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Чыганак

1. Садриев Ф.М. Бәхетсезләр бәхете. Роман-трилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 903 б.

2. Фәнни-теоретик әдәбият

2. Саттаров Г.Ф. Этапы развития и очередные задачи татарской ономастики. – Казань, 1970. – С. 86-87.

3. Саттаров Г.Ф. Г. Ибраһимов әсәрләрендә исем-атамалар // Казан утлары. – 1993. – № 6.

4. Саттар-Мулилле Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: Раннур, 1998. – 488 б.

5. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2004. – 543 б.

ГЫЙЛЕМНӘН ЗУР ХӘЗИНӘ ЮК

Хаҗиев Р.И., Хаҗиева Р.Р.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

Муниципаль бюджет белем бирү йорты “25 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”, Яр Чаллы шәһәре, Россия

САМОЕ БОЛЬШОЕ БОГАТСТВО – ЗНАНИЕ

Хазиев Р.И., Хазиева Р.Р.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия
Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа №25», г. Набережные Челны, Россия

В данной статье нами рассматривается роль знаний в жизни человека. Основная цель – выявить теснейшую связь между светскими и религиозными знаниями. Автор анализирует некоторые важные особенности данной проблематики.
Ключевые слова: *религие, Ислам, Коран, Мухаммед, знание, народное творчество.*

THE GREATEST WEALTH – KNOWLEDGE

Khaziev R.I., Khazieva R.R.

Naberezhnye Chelny Institute of social-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia
Municipal budget educational institution "Secondary school №25", Naberezhnye Chelny, Russia

In this article we investigate the role of knowledge in life of man. Primary goal is to educe the closest connection between society and religious knowledge. The author analyses some important features of this range of problems.
Keywords: *religion, Islam, Koran, Muhammad, knowledge, folk creation.*

Халкыбыз белем алуны элек-электән үк хуплаган, аң-белемле кешенең җәмгыятьтә кадере зур булган. Бу халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, *мәкальләрдә:* “Белемдә бәхет, белемсезгә дөнья ләхет”, “Белемдә көч”, “Белем – нур, белмәү – хур”, “Дөньяда иң зур байлык – белем”, “Гыйлем алу – инә белән кое казу”, “Гыйлем өйрәнү – бишектән ләхеткә чаклы”, “Белем беләккә көч бирә”, “Белеме ничек – сүзе шундый”, “Белемле кеше югалмас”, “Белмим дип әйтмә, теләмим дип әйт” һ.б. [1, б. 24-26].

Бишек җырларында:
“Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу...” [1, б. 118].

Тизәйткечләрдә:
“Остасын сез остадыр да,
Теләсәгез остарырга,
“Без оста!” – дип очынмагыз,
Коры куык очырмагыз.
Останың да остасы бар,
Останың да остазы бар” [1, б. 77-78].

Табышмакларда:
“Үлчәүләрдә үлчәнми,
Базарларда сатылмый”. *(Акыл)*

“Аршынлы түгел, потлы түгел,
Һәркемдә бар”. *(Акыл)*

“Акыллы чәчә барыр,
Акылсыз җыя барыр”. *(Белем)* [6, б. 3-4].

Мәзәкләрдә:

Хәтта үзе дә аңлаган.

Укытучы балаларга дәрестә яңа тема аңлата икән. Бер тапкыр аңлаткан да сораган:

– Аңладыгызмы, балалар?

Балалар:

– Аңламадык, – дигәннәр. Тагын аңлаткан. Балалар тагын аңламый калганнар. Укытучы өченче тапкыр аңлаткан да әйткән:

– Әһә, инде менә үзем дә аңлап җиттем [1, б. 70].

Дини һәм дөньяви гыйлемнәрнең әһәмияте хакында галимнәребез (Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддинев, Г. Гобәйдуллин һ.б.) элек-электән үк төрле хезмәтләр язганнар. Мәсәлән, Ш. Мәрҗани "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" (Казан, 1989) китабында гыйлемнең әһәмиятен түбәндәгечә искәртә: "Гыйлем һәм мәгърифәт белән шөгыльләнү, акыл белемен һәм камиллекне өйрәнү – һәр сәламәт акыл, аек аң каршында һичшиксез кирәкле сыйфат, ә бу өлкәдә тырышлык һәм бер-береңә киң ярдәм күрсәтү – берсүзсез күркәм эш. Зирәк шәхесләр һәм акыл ияләре карашынча, хаклыгы ачык гыйлем – ул иң кадерле сыйфатларның берсе, камиллекнең иң мактаулысы, ә гыйлем өйрәнү – рәхәтлекнең һәм бәхетнең иң югары дәрәҗәсе икәнлеге ачык. Пакъ ислам шәригате гыйлемнәр өйрәнү һәм мәгарифне камилләштерүгә төрлечә өндәп һәм кызыктырып килде... Гомумән, гыйлем турында "Белгәннәр белән белмәгәннәр бертигез булырмы?..", "...Берәү хикмәтле берәр сүз әйтсә, күп изгелек кылган булыр", "Акыл ияләре генә телгә алыныр" дигән аятьләр бар" [5, б. 41].

Р. Фәхреддинев "Болгар вә Казан төрекләре" (Казан, 1993) хезмәтендә болгарларның ислам динен чын күңелдән инанып кабул итүләре хакында яза: "Һәрхәлдә, болгар төрекләрендә ислам дине ныклы рәвештә урнашты, хәлифәлек үзәгеннән һәм ислам бишегеннән ерак булуларына карамастан, Аллаһе тәгаләнең өстенлеге һәм мәрхәмәте белән дини гадәтләр үтәлеп торды. Бу эш – болгар төрекләренең ислам кабул итүләре дөньяви бер киңлек өчен генә булмыйча, бәлки хаклыкны тирән аңлаулары аркасында динне күңелдән тануларына дәлил. Юкса, җилдән килгән мәхәббәт, төш һәм кәрамәт юнәлешендәге эшләр сәбәбеннән генә хасил булган ихласның шул эшнең киресе булган икенче төрле җил һәм икенче төрле кәрамәт сәбәбеннән югалуы һәм, һәрхәлдә, ныклы булмавы, гомумиләшмәве мәгълүм" [7, б. 48].

Г. Гобәйдуллин Алтын Урда чоры хакында: "Ислам дине Бәркә хан заманасында кабул ителгән булса да, тәмамән җәелеп җитмәгән иде. Ислам дине иң куәтле рәвештә Үзбәк хан заманасында җәелде (1313-1342). Аның заманасында ислам йортларыннан голямалар бик килеп йөрделәр. Мәшаих фәкиһлар, башка голямалар күбәйгән иде. Ханнар тирәсендә пәйгамбәр нәселеннән булган сәидләр була. Алтын Урда дәүләтенә мәсҗедләр салынган, мәдрәсәләр дә зоһур итеп, аларда укучы шәкертләр хөкүмәт каршында бик кадер-хөрмәттә иде", – дип яза [3, б. 106].

Әлбәттә, белем алу кешедән зур тырышлык, тәвәкәллек сорый. Изге "Коръән" китабында бу хакта болай диелә: "Хактыр ки, кыенлык белән рәттән җиңеллек тә бар" ["Инширах": 6]; "Шулай булгач, бер эшне тәмам итүгә үк, икенчесен башларга тырыш" ["Инширах": 7]; "Һәр эшне бары тик Аллаһының тарафына йөз тотып башкар" ["Инширах": 8].

Мөхәммәд (570-632) пәйгамбәребез үзе дә белемгә омтылучы изге зат булган. Ул халыкның аң-белемен күтәрү, Аллаһ юлына күндерү буенча зур эшләр башкарган. Дөньякүләм билгеле галим, "100 великих людей" (М., 2000) хезмәте авторы Майкл Х. Харт аны кешелек үсешенә зур йогынты ясаган иң бөек шәхесләрнең берсе дип күрсәтә.Ул бу хакта түбәндәгеләрне яза: "Последствия арабских завоеваний VII века продолжают оказывать существенное влияние на жизнь человечества и сегодня. Вот это соединение огромного религиозного и светского влияний и заставило меня выделить Магомета как уникальное историческое лицо" [8, с. 30].

"Коръән" – һәртөрле белемнәр чыганагы. Ул безне кызыксындырган күп сорауларга җавап бирә. Мәсәлән:

Күкләрне һәм Җирне барлыкка китерүче кем?

"Күкләрне, Җирне яралтуы да, Күктәге, Җирдәге бөтен җан иясен барлыкка китерү дә Аның *(барлыгына, кодрәтенә)* дәлил булып тора. Аллаһ үзе теләгән вакытта *(Кыяматтә)* боларның барысын да бер урынга туплarга да кодрәтле" ["Шура": 29]; "Аллаһ бөтен нәрсәне юктан бар итеп, тәртипләде" ["Әгълә": 2].

Кеше ни рәвешле яралтылган?

"Хәзер инде кеше үзенең ничек яралтылганы турында уйлансын һәм гыйбрәт алсын" ["Тарикъ": 5]. "Ул атылган су тамчысы кебек сыеклыктан, *(ир кешенең)* арка кимегеннән һәм *(хатынның)* күкрәк кимегеннән чыккан сыеклыктан хасил зат" ["Тарикъ": 6-7].

Кеше өчен кирәк булган сый-нигъмәтләрне кем яралткан?

"Җир йөзендә ни булса, Ул барысын да сезнең өчен яралтты. Соңра күккә юнәлде, аны җиде кат итеп корды. Ул барысын да белүче" ["Бәкара": 29]; "Хактыр ки, Без *(Аллаһ)* мул-мул яңгырлар яудырдык ["Габәсә": 25]; "Аннан соң Без туфракны яхшылап ярдык *(сөрдек)*" ["Габәсә": 26]; "Шулай итеп, без анда орлык үстердек" ["Габәсә": 27]; "Йөземнәр, ашый торган төрле үләннәр, зәйтүн агачлары, хөрмә бакчалары, куп-куе булып үскән җимеш бакчалары, җиләк-җимеш һәм печән үстердек" ["Габәсә": 28-31]; "*(Боларның һәммәсен дә Без)* сезгә һәм мал-туарларыгызга файда булсын, дип бар иттек" ["Габәсә": 32].

Аң-белемле, укымышлы кеше яхшы белән начарны аера белергә тиеш: "Кеше игелек кыла икән, үз файдасына булыр. Кеше яманлык кыла икән, үзенә зарар булыр. Раббың колларына гаделсез түгел *(гөнаһ кылмаганны җәзаламас)*" ["Фуссиләт": 46].

Тәрбияле һәм укымышлы кеше гөнаһлар кылудан да саклансын: "Әй, инсаннар! Сезне һәм сездән элек яшәгәннәрне яралткан Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз. *(Шулай итсәгез)* бәлки сез *(гөнаһтан, начарлыктан, Аллаһның җәзасыннан)* котылырсыз, тәкъвалыкка ирешерсез" ["Бәкара": 21]; "Алар *(мөселманнар)* иң зур гөнаһлардан берсе – оятсызлыктан ерак йөри. Ачулары чыккан чагында да, кызмаслар, кешене гафу итәрләр" ["Шура": 37].

Алар яманлык өчен җәза зур булачагын истә тотарга тиешләр: "Яманлык өчен җәза шул кылынган яманлык кадәр булырга тиеш. Кем гафу итсә, тынычлык сакласа, *(бозылышканнарны татуландырса)* аңа бүләк Аллаһ тарафыннан булыр. Дөресе шул, Аллаһ залимнәрне сөйми" ["Шура": 40]; "Рәнҗетелгән кеше соңыннан хакын кайтарса, аңа җәза булмас" ["Шура": 41]; "Яманлык кылганнарга вә Җир йөзендә хаксызга кеше рәнҗеткәннәргә җәза бар. Аларга – әче газап" ["Шура": 42]; "Кем дә кем *(үч алмыйча)* сабыр итсә һәм *(рәнҗетүчене)* кичерсә, һичшиксез, бу кеше мәртәбәле, нык рухлы икәнен исбатлар" ["Шура": 43].

Иманы нык кеше бернәрсәдән дә куркырга тиеш түгел:

"– Раббыбыз – Аллаһ! – дип, соңыннан да шуңа тугры булганнар өчен *(Кыяматтә)* бернинди дә курку юк. Аларга кайгы килмәс" ["Әхкаф": 13]; "Алар җәннәт әһеле булыр. Кылган игелекләренә күрә, әҗер буларак, анда *(җәннәттә)* мәңгегә калачаклар" ["Әхкаф": 14].

Кеше исән вакытта игелек эшләргә ашыгырга тиеш. Нәрсә соң ул игелек? "Игелек ул – гөнаһ кылудан саклану", – дип җавап бирә "Коръәни-Кәрим" ["Бәкара": 189].

Изге китапта юмарт һәм миһербанлы булу да мактала: "Ятим очратсаң, аң бул, син чыраеңны сытма, аңа ярдәм ит" ["Духа": 9]; "Мохтаҗларны әрләмә, яныңнан кума, аларга ярдәм ит" ["Духа": 10]; "Шуңа күрә, син *(Мөхәммәд)* һичтуктаусыз Аллаһының чиксез юмартлыгы, төкәнмәс кодрәте турында *(кешеләргә)* бәян ит!" ["Духа": 11].

Кешедән җәннәтнең барлыгына инану сорала: "Һәр җан иясе үлемне татыячак. Кыямәт көнендә *(дөньяда)* кылганнарыгызга таман итеп әҗер биреләчәк. Кемдер җәһәннәмнән еракка җибәрелеп җәннәткә барып урнашса, ул чынлап та морадына ирешкән булыр. Бу дөньядагы тормыш исә алдавыч кына" ["Гыймран": 185].

"Коръән"дә кешелек тарихында булып узган күп кенә фактлар да телгә алына. Әйтик, Мисыр фиргавеннәре (патшалары) турында: "Фиргавенгә бер пәйгамбәр күндергән кебек, сезгә дә нәкъ шулай, кыланмышларыгызга шаһитлек кылачак бер Пәйгамбәр

күндергән идек” [“Мүзәммил”: 15]; “Әмма Фиргавен ул пәйгамбәргә каршы чыкты. Без дә аны авыр, читен рәвештә җәзаладык” [“Мүзәммил”: 16].

“Коръән”нең иңдерелеше турында: “Әгәр илчебезгә *(Мөхәммәдкә)* иңдерелгән *(Коръән)*гә шикләнеп карасагыз, әгәр дә сез хаклы икән, Аллаһтан башка ярдәмчеләрегезне чакырып, шуңа охшаш, ичмасам, бер сүрә китереп күрсәтегез” [“Бәкара”: 23].

Кеше гомерен сүз йөртеп, байлык туплап кына уздырырга тиеш түгел: “Әче каһәр төшсен кеше артыннан сүз йөртүчеләргә, байлык туплап, кан калтырап торган сараннарга, байлыгым-малым мине мәңге яшәтер, дип уйлаганга”, – ди Аллаһ [“Һүмәзә”: 1-3]. Ләкин кеше нәфес корбаны. Ул вакыты җиткәч: “– Аһ, фани дөньяда игелекләр кылган булсам, Ахирәттә бәхеткә ирешәчәк идем бит, – дип уфтаначак” [“Бәләд”: 24]. Әйе, күп кеше чын байлыкның белем һәм гомумкешелек кыйммәтләре икәнен аңламыйча бакый дөньяга китеп бара. Халык белем турында болай ди:

“Бер байлык бар – янмый,
Карак та урлый алмый,
Төшеп тә калмый”.

Гомумән, Коръәннең бөтен аятьләрен камил аңлар өчен энциклопедик күләмле белемгә ия булырга кирәк [2, б. 5].

Мәкаләбез ахырында шуны әйтәсе килә: кешене ике канатлы кошка тиңләргә мөмкин. Бер канаты – дини (хак) гыйлем, икенчесе – дөньяви гыйлем. Мәгълүм булганча, кошка очу өчен ике канатлы булу кирәк, чөнки бер канат белән генә очып булмый. Димәк, Адәм баласыннан да яшәү-тормыш көтү өчен ике төр белемнәргә дә ия булу сорала.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Бала бишеге – гомер ишеге. Башлангыч сыйныф укытучылары, балалар бакчаларында, милли төркемнәрдә тәрбиячеләр, ата-аналар өчен халык авыз иҗаты әсәрләре җыентыгы. 3 нче басма. – Яр Чаллы: Идел йорт, 2002. – 144 б.
2. Букейль Б. Коръән һәм бүгенге фән. – Казан: Иман, 1993. – 17 б.
3. Гобәйдуллин Г.С. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәтләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 334 б.
4. Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары / Төрле галимнәрнең тәрҗемәләре һәм шәрехләреннән файдаланып матбугатка хәзерләүче – Р. Батулла. – Казан: ТГЖН типографиясе, 2000. – 600 б.
5. Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.
6. Татар халык табышмаклары / Мөхәррире – Г. Вәлиди. – Яр Чаллы: Идел-йорт, 2002. – 96 б.
7. Фәхреддинев Р.С. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 287 б.
8. Харт М.Х. 100 великих людей. – М.: Вече, 2000. – 544 с.

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ “САФ ҖИЛЛӘР” РОМАН-ДИЛОГИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ГАРӘП-ФАРСЫ АНТРОПОНИМНАРЫ

Хаматнурова Л.Р.

Муниципаль бюджет белем бирү йорты “7 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”, Яр Чаллы шәһәре, Россия

АНТРОПОНИМЫ АРАБО-ПЕРСИДСКОГО ПРОИСХОЖДЕНИЯ В РОМАНЕ-ДИЛОГИИ «СВЕЖИЕ ВЕТРА» МАХМУТА ХАСАНОВА

Хаматнурова Л.Р.

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа №7», г. Набережные Челны, Россия

Необходимость научного изучения поэтической ономастики отдельных произведений получила в настоящее время всеобщее признание. Цель статьи заключается в комплексном исследовании антропонимов арабо-персидского происхождения в романе-дилогии «Свежие ветра» М. Хасанова. Тем самым впервые в научный оборот вводится новый ономастический материал.

Ключевые слова: *антропонимы арабо-персидского происхождения, М. Хасанов, роман-дилогия «Свежие ветра».*

THE ANTHROPONYMS OF THE ARAB-PERSIAN ORIGIN IN THE NOVEL-NOVELS "FRESH WIND" OF MAHMUT KHASANOV

Khamatnurova L.R.

Municipal budget educational institution "Secondary school №7", Naberezhnye Chelny, Russia

The necessity of studying the poetic onomastics of the particular works has been generally recognized nowadays. The aim of the article is a complex research of the anthroponyms of the Arab- Persian origin in the novel-dilogy "Fresh wind" M. Khasanov. In that way, first lime a new onomastic material is putting into scientific use.

Keywords: *anthroponyms of the Arab-Persian origin, M. Khasanov, the novel-dilogy "Fresh wind".*

Ономастиканың *антропонимика* (гр. *антропос* – “кеше” + *онома* “исем”) бүлеге кеше исемнәрен, фамилияләрне, кушаматларны, псевдонимнарны һәм башка антропонимик категорияләрне өйрәнү белән шөгыльләнә.

Профессор Г.Ф. Саттаров фикеренчә, татарларда төрдәшләре белән 20 меңләп кеше исеме кулланыла [2, б. 4]. Без аларның кайберләрен Мәхмүт Хәсәновның “Саф җилләр” роман-дилогиясендә дә очратабыз.

Шунысы игътибарга лаек: әсәрдә бер генә очраклы исем дә кулланылмый. Автор исемнәрне уйлап, “исеме җисеменә туры килә торган”нарын гына сайлый.

Әлеге мәкаләдә безнең максат – “Саф җилләр” роман-дилогиясендә кулланылган исемнәрнең этнолингвистик катламнарын өйрәнү.

Гомумән алганда, әсәрдә кулланылган исемнәрнең түбәндәге төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин:

1) гарәп теленнән кергән исемнәр;

2) фарсы теленнән алынган исемнәр;

3) рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән үтеп кергән исемнәр;

4) катнаш (гибрид) ясалышлы исемнәр.

Әсәрдә күбрәк гарәп-фарсы һәм аларга мөнәсәбәтле катнаш (гибрид) чыгышлы исемнәр очрый. Без биредә шуларга тукталып үтәрбез.

1. Гарәп теленнән кергән исемнәр:

а) ир-ат исемнәре:

Әбрар – “изгеләрдән; тәкъва кеше” [2, б. 310]: *Билгеле, **Әбрар** Гайнетдинович район терлекчеләре алдында торган кыенлыкларны да яшермәде* [1, б. 344].

Әхмәди – “1. Мактаулы, данлы. 2. Бер аллага ышанучан, мөселман” [2, б. 318]: *Ахирәттә **Әхмәди**гә урын юк дигәндәй, ..., минем өчен хәсрәтләнә күрмә* [1, б. 134].

Әхмәт – “иң данлы, иң мактаулы” [2, б. 318]: *Әмма иң арттан килүче яшь тракторчы **Әхмәт**, иптәшләре каршына турыдан гына килү нияте белән, тракторын ерганакның шактый киң җиренә китереп кертте* [1, б. 145].

Баттал – “1. Батыр, каһарман; фидакарь сугышчы. 2. Буш, эшсез” [2, б. 58]: ***Баттал** абзый һичшиксез хаклы: мең төрле техника белән коралланган күпкырлы хуҗалык белән идарә итү ай-һай катлауланды* [1, б. 232].

Борһан – “дәлил; хакыйкать, дөреслек; исбатлаучы, факт” [2, б. 65]: *Чыннан да, әле генә алардан чыгып киткән **Борһан** элеккеге **Борһан** түгел иде инде. Кая ул! Басылган. Сүз-өннәренә кадәр икенче. Элегрәк сүз кушарга куркып тора идек бит, тиле. Дары кебек кабынып китеп, эт итеп сүгеп, кеше алдында мыскыл итә торган Борһан түгел инде ул* [1, б. 59].

Вазих ~ Вазыйх – “ачык, анык, билгеле; ачык итеп аңлатучы” [2, б. 72]: ***Вазих** үзе дә ифрат дәрәҗәдә тотанаклы, гаять тә сабыр, тыныч табигатьле кеше булып чыкты* [1, б. 242].

Вәли – “1. Ия, хуҗа, яклаучы. 2. Әүлия, изге. 3 Аллаһыга якын дус. 4. Хакимлек итүче һәм яхшы бәндәләрнең дусты” [2, б. 74]: ***Вәли** кызны тыкрыкка кадәр дә, өенә кадәр дә озатты”* [1, б. 217].

Габдулла – “Аллаһ колы, Аллаһ бәндәсе” [2, б. 80]: ***Габдулла** абзый сөт кабул итү белән беррәттән фуражчы да бит* [1, б. 71].

Гариф – “белүче, танучы, хәбәрдар; укымышлы; акыл иясе” [2, б. 87]: *Ә комсорг **Гариф**ны, Хәдичәнең колхозыбызга файдасы күп тиде, тиешенчә озату чарасын да күрергә кирәк, дип, яшьләр җибәргәннәр* [1, б. 359].

Гыйлаҗи – “дәвалану, дәва, дару; әмәл, чара; төзәтү” [2, б. 90]: ***Гыйлаҗи** картка кадәр төште, чалгы тапап тора* [1, б. 201].

Җәдит – “яңа, яңалык” [2, б. 330]: *Икенче көнне үк Хәдичәләргә район прокуратурасында тикшерүче булып эшләүче **Җәдит** исемле бер бәндә басып килеп керде* [1, б. 219].

Җәүдәт – “1. Өстенлек; һич кимчелексез булу. 2. Юмартлык, киң күңеллелек” [2, б. 331]: *“Авангард” колхозының атаклы механизаторы Җәүдәт Харисов “Мир” маркалы кул сәгате белән бүләкләнә* [1, б. 186].

Заһидулла – “Аллаһының изге, тәкъва кешесе” [2, б. 103]: *Нәкъ шул елларда **Заһидулла** абзый ялгыз калды* [1, б. 325].

Заһит – “изге, тәкъва; тыйнак; суфый, аскет” [2, б. 103]: *Берсе орынып торган күршебез, хәрендәш тиешле кешебез Мәфтуханың кече улы **Заһит*** [1, б. 359].

Зиннур – “нур иясе, нурлы; нур-бизәк” [2, б. 103]: ***Зиннур** минем белән килмәкче дә иде әле, сбор дип, иптәшләре мәктәпкә алып киттеләр үзен* [1, б. 235].

Кәримулла – “Аллаһының хөрмәтле, юмарт, кадерле кешесе” [2, б. 151]: *Көннәрнең берендә авылда бер диярлек таза тормышта яшәүче кибетче **Кәримулла** белән хатыны килеп керәләр* [1, б. 28].

Котбетдин – “диннең котыбы, үзәге (мәшһүр кешесе); ышаныч үзәге” [2, б. 142]: – *Сезнең урында башка берәү булса, бөтен районда бер дигән ирне сайлап, күзләп алыр иде дә: “Йә әле, кем, **Котбетдин**, бүгеннән син минем ирем буласың”, – дип команда гына бирер иде* [1, б. 196].

Мәҗит – “данлыклы, атаклы” [2, б. 180]: ***Мәҗит** тә онытылганда бер туган якларына, әнисе ягыннан кардәш тиешле җиңгәчәләренә кайтып, туган җирләрен, гүзәл Кенәле буйларын күреп киткәли* [1, б. 325].

Мисбах – “факел, яктырткыч, шәмдәл, лампа, фонарь” [2, б. 165]: *Хәзергә, **Мисбах** дус, минем ишекнең кай якка ачылганын онытып тор* [1, б. 13].

Мортаза – “сайланган, артык күрелгән; сайлап куелган; сөекле” [2, б. 172]: ***Мортаза** исә, бу бусаганы күптәннән бирле таптаган кеше сыман, кыю бәреп керде* [1, б. 63].

Нәҗип – “1. Затлы; асыл; акыл; сәләтле. 2. Затлы, асыл нәселдән” [2, б. 196]: *Менә шулай көтмәгәндә-уйламаганда, күп тармаклы гаять зур колхозның партком секретаре булып киткән кеше ул **Нәҗип*** [1, б. 328].

Нәфис – “1. Нәфис, күркәм, чибәр. 2. Кыйммәтле, бик бәһале” [2, б. 195]: *Бик озак, бик зәһәр ярыштылар ул көнне ике егет, һәм ахыр чиктә **Нәфис** җиңеп чыкты* [1, б. 16].

Нигъмәтулла – “Аллаһ мәрхәмәте, рәхим-шәфкате” [2, б. 190]: ***Нигъмәтулла** карт тирәсендәрәк утырганнар аны эткәли-төрткәли башладылар* [1, б. 169].

Ногман – “1. Лалә чәчәгенең бер төре. 2. Кызыл, кан төсендәге” [2, б. 191]: *Ә аның белән бергә килеп чыккан **Ногман** абзыйның үз тугызы тугыз иде* [1, б. 114].

Садри ~ Садрый – “1. Күкрәкнеке, йөрәкнеке, үзәкнеке. 2. Башлык, түрә, җитәкче” [2, б. 208]: *Җәйләүгә мастер-наладчик итеп инде ике-өч тапкыр шофёрлык правасын алдырган, соңгы авариясендә колхоз машинасын тәмам җимереп эштән чыгарган әлеге дә баягы исерек баш **Садрины** билгеләделәр* [1, б. 318].

Сафа – “1. Сафлык, пакълек. 2. Хозурлык, рәхәтлек, кайгысызлык, тынычлык” [2, б. 214]: *Мәдинә Ногман абзыйга **Сафа** картны күрергә кушты* [1, б. 127].

Солтан – “патша, хөкемдар, дәүләт хуҗасы, монарх, император” [2, б. 216]: ***Солтан** да, авызын ерып, теленә салынуын белде: ...* [1, б. 282].

Таһир – “саф, пакъ; гөнаһсыз” [2, б. 234]: *Бары тик бер **Таһир** гына әле таң алдыннан балалаган дуңгызы янында чуала иде* [1, б. 124].

Тәлгать – “1. Тышкы кыяфәт, йөз, чырай. 2. Матурлык, ямь, күркәмлек” [2, б. 246]: *Борһан улы **Тәлгать**нең ничегрәк һәлак булуын да сөйләде* [1, б. 177].

Фәсах – “ягымлы, сүзгә оста; матур сөйләүче, чәчән” [2, б. 261]: *Төнге сменада эшләгән **Фәсах** агай тегермәнчегә охшап калган, кием-салымнарына гына түгел, кашларына кадәр көрпә-он кунган аның* [1, б. 21].

Хәбибрахман – “Аллаһының дусты” [2, б. 271]: *Күрше **Хәбибрахман** карт олтан салып биргән иске чесанка да ярамады* [1, б. 83].

Хуҗи – “1. Хуҗа, башлык, әфәнде. 2. Укытучы, остаз” [2, б. 270]: *Шуны гына көтеп торган кебек, бөкре **Хуҗи** Шапырай картны җилтерәтеп элеп алды да эткәләп-төрткәләп чыгарып ук җибәрде* [1, б. 167].

ә) хатын-кыз исемнәре:

Васбикамал ~ Васфикамал – “төгәл, камил сыйфатлы” [2, б. 348]: *Хәдичәнең туган әнисен алыштырган кешесе **Васбикамал** түти, хәзер инде гүр иясе, авылның шундый да ярлы, тормышы коелып төшкән, гомере буена ятим-ятимә булып яшәгән кеше иде* [1, б. 216].

Вәлидә – “туучы; кыз бала” [2, б. 349]: *Башкара Хәдичә апаның кызы, безнең кадерле кунагыбыз **Вәлидә*** [1, б. 311].

Гайнисә – “хатын-кызларның иң яхшысы; иң асылы” [2, б. 351]: *Тормышның ачысын-төчесен күргән **Гайнисә** түти аларны үзенчә юатып, аналарча акыл бирде:*

– Балалар, ярлылык яр түгел дигәндәй, байлык та бал түгел. Ярлылыкта яр табылса, кузгалак та аш булыр; тигезсез байлыкка баллы мал да таш булыр, дигән борынгылар [1, б. 16].

Гайния – “тантана” [2, б. 351]: *Бөтен яшьлеген, гомерен фермага биргән **Гайния** апа мал-туар яныннан әллә кая китәргә теләмәде* [1, б. 207].

Галимә – “укымышлы, белемле, галимә” [2, б. 351]: – *Кечкенәбезнең исеме **Галимә** булыр...* [1, б. 235].

Галия – “бөек, олы, югары дәрәҗәле; кыйммәтле” [2, б. 351]: *Розалия белән **Галия** исемле ике кыз үстергәннәр* [1, б. 344].

Гөлсем – “тулы йөзле; ал яңаклы” [2, б. 358]: *Мәрхүмә **Гөлсем** яхшы тормыш иптәше булу белән бергә менә дигән ана да була белде* [1, б. 361].

Гыйльмениса – “хатыннарның гыйлемлесе, укымышлысы” [2, б. 354]: – ***Гыйльмениса,** күрше, узган елда сабан туе җыенында булган идеңме син? – дип сүз башлый берсе* [1, б. 259].

Җәмилә – "матур, чибәр, гүзәл" [2, б. 455]: *Ничек кенә булмасын, Борһан кадәр Борһанның килеп авылга чакыруы **Җәмилә** җиңгинең күңелен канатландырып җибәрде* [1, б. 59].

Зәйнәп – "1. Тулы гәүдәле; таза. 2. Кәккүк" [2, б. 369]: *Алма агачыннан ерак төшми дигәндәй, **Зәйнәп** тә иң алдынгы савымчылардан санала* [1, б. 207].

Зәйтүнә – "зәйтүн агачы; мәңге яшел агач" [2, б. 369]: ***Зәйтүнә** дә килеп җитте.*

– Нишләдең син, Хәдичә апа?! – дип өзгәләнеп күрсенде партгруппорг [1, б. 344].

Зөһрә – "1. Нур чәчеп, балкып торучы. 2. Гөл. 3. Зөһрә йолдызы, Венера" [2, б. 371]: *– Кара әле, **Зөһрә**, бозауларыма гына күз-колак булсаңчы. Ашарларына салган. Алларында җитәрлек. Суларын гына алыштырасы бар иде. Зинһар, шуны гына эшли күр инде...* [1, б. 182].

Камәр – "ай" [2, б. 376]: ***Камәр** аунап яткан капчыкларның берсе өстенә хәлдән таеп килеп утырды. Тик шул утыруыннан тора алмады* [1, б. 18].

Мәдинә – "Шәһәр. Согуд Гарәбстанындагы шәһәр. Мәдәният учагы" [2, б. 390]: *Соңгы вакытта инде ул **Мәдинәгә** бөтенләй башка күз белән карый башлаган иде. Эшнең әмәлен, җаен-рәтен белеп, җилдәй очып, уттай бөтерелеп, шуның өстенә әле тиенне тиенгә куша белә торган бу хатынга карап соклануын да яшерми башлады ул* [1, б. 50].

Мәйсәрә – "байлык, муллык, иминлек" [2, б. 390]: *Хәдичәнең күңелендә шик-шом кебек нәрсә дә кузгалып куйды. Ләкин дилбегәсен тотып торган **Мәйсәрә** елмая, йөзе дә тулган ай кебек балкый иде* [1, б. 291].

Мәфтуха – "ачык, ачык йөзле" [2, б. 392]: *Нәни кызы Вәлидәне караучы **Мәфтуха** түти аны эштән кайтуга: "Ирең машина белән килеп балаңны алып китте", – дип каршылады* [1, б. 221].

Мөнирә – "яктыртучы; нур өләшүче" [2, б. 395]: *Менә шундый иде ул **Мөнирә**. Олысы да, кечесе дә аны үз итә, якын күрә иде* [1, б. 35].

Нәсимә – "йомшак күңелле, мөлаем" [2, б. 402]: *Урта бер җирдә гармунын тотып Фирдәвес тора. Аның икенче ягында скрипка уйнавы белән тирә-юньдә дан казанган **Нәсимә*** [1, б. 313].

Рәмзия – "билге, тамга, символ" [2, б. 408]: *Алдан сөйләшеп куйгандай, барысы да көлешә башладылар. **Рәмзия** үзе дә түзмәде, нурланып, ачык итеп елмаеп куйды* [1, б. 283].

Сабира – "сабыр, түземле, чыдам" [2, б. 410]: *Кара, ничек җыйнак, ыспай итеп әтмәлләп куйды. **Сабира** апа улына сокланып туя алмады* [1, б. 83].

Сәкинә – "тыныч; сабыр, тыныч күңелле" [2, б. 414]:

*– Иптәшләр! Тиздән имтиханнар башланачак. Минем эшем болай да муеннан. Шуның өстенә читтән торып булса да укыйм, – дип, аяк терәп каршы торуына карамастан, партоешма секретаре итеп мәктәпнең завучы **Сәкинә** Харисовнаны сайлап куйдылар* [1, б. 344].

Салихә ~ Салиха – "1. Яхшылык, изгелек, игелек кылучы. 2. Саф күңелле" [2, б. 410]: *– Чыннан да, Ибрай, яшермичә дөресен әйт әле. Теге, **Салихә** карчыктан, райүзәккә утырып кайткан өчен икеләтә бәһа алуың хакмы?..* [1, б. 181].

Фагыйлә – "эшләүче, эшчән, эш сөюче" [2, б. 424]: *Суалчаннарын да төнлә белән, күрше **Фагыйлә** карчык мунчасының сайгагын куптарып кына җыеп ала* [1, б. 81].

Фәния – "белемле, гыйлемле" [2, б. 425]: *Савылган сыерларны стойкадан чыгарганчы, боҗыр кебек өлгер-җитез **Фәния** чиләк алып сыерларның каймак кебек куе җилен төбен кул белән савып ала торган булды* [1, б. 268].

Хәбирә – "хәбәрдар, белекле; хәбәрче" [2, б. 431]: *Шаккатырлык та шул! Чөнки **Хәбирә** унбиш баш сыеры белән Гайния апаның унике сыеры биргән сөтне дә савып ала алмаган* [1, б. 72].

Хәдичә – "җитлекмәгән; вакытыннан элек туган кыз. Мөхәммәт пәйгамбәр хатынының исеме" [2, б. 431]: *Бер килсә килә бит ул. **Хәдичә** дә шундый бәхетсезләрнең берсе* [1, б. 13].

Хөпбениса ~ Хөббелниса – “хатын-кызларның сөеклесе” [2, б. 433]: *Бу минутта аларга **Хөпбениса** түтиләреннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр кебек тоелды* [1, б. 27].

2. Фарсы теленнән алынган исемнәр:

а) хатын-кыз исемнәре:

Маһибану – “кызларның ай кебеге, ай кызы” [2, б. 384]: *Билгеле, карчыгы **Маһибану** түти белән икәүдән-икәү, карт белән карчык торганга гына түгел* [1, б. 190].

Сәрвәр – “башлык, җитәкче; дәрәҗәле кеше” [2, б. 415]: *– Таныш булыйк алайса. – Кунак, перчаткасын салып, кулын сузды. – Мин райком секретаре Рәхимова булам. Исемем – **Сәрвәр*** [1, б. 66].

3. Катнаш исемнәр дә очрый:

а) ир-ат исемнәре:

Миргасим ~ Миргасыйм (фарсы-гарәп теленнән) – “язык, яман эшләрдән саклаучы әмир” [2, б. 162]: *Баш зоотехник Гөлнур урынына калып торган ясалма орлыкландыру пункты технигы **Миргасим** кайсыдыр савымчыны эттән алып эткә салып сүгә* [1, б. 211].

Фирдәвес (фарсы-гарәп теленнән) – “җәннәт, оҗмах бакчасы” [2, б. 256]: ***Фирдәвес** сәхнәнең бер як кырыендарак торган трибуна артына килеп басты, куен кесәсеннән бер төргәк кәгазь чыгарып алдына куйды* [1, б. 309].

Хәсәнша (гарәп-фарсы теленнән) – “Хәсән + шаһ. Яхшы; чибәр, матур, күркәм” [2, б. 276]: ***Хәсәнша** атлы пәһлеван кадәр пәһлеваннар катнашкан бу кызыклы әкият ни белән беткән буласыдыр, анысын әйтүе кыен* [1, б. 28].

Сәеткол (гарәп-төрки-татар теленнән) – “Сәет + кол. Сәет – башлык, җитәкче, хөкемдар; хуҗа; әфәнде. Мөхәммәтнең кызы Фатыйма балаларыннан килгән аксөяк нәселгә бирелгән титул” [2, б. 221]: ***Сәеткол** карт, җилле-давыллы язгы кич булу сәбәпле, аның әнисен рәтләп күрә алмаган, бары тик ачыргаланып, ярдәм өмет итеп, җан ачысы белән кычкырганын гына ишеткән* [1, б. 272].

Хафиз (гарәп-татар теленнән) – “1. Саклаучы; күңелдән ятлаучы; Коръәнне яттан белүче. 2. Истәлек, хәтер” [2, б. 267]: *Юк, мыштым **Хафиз** түгел бу, ә чын хуҗа, колхоз дип янып-көеп яшәүче* [1, б. 262].

Ибрай ~ Ибраһим (яһүд-гарәп теленнән) – “1. Халыклар атасы. Гарәпләрнең һәм яһүдләрнең уртак бабалары Авраам (Абрахам) “Халыклар атасы” исеменнән. 2. Тәүраттагы Авраамның ассириялеләр теленнән туры тәрҗемәсе – “минем атакаем югары” [2, б. 108]: ***Ибрае** да аның таш астыннан чыккан. Сүз эзләп кесә капшап маташа торганнардан түгел* [1, б. 180].

ә) хатын-кыз исемнәре:

Гөлнур (фарсы-гарәп теленнән) – “гөл кебек нурлы” [2, б. 358]: *Ә инде сәхнәгә **Гөлнур** чыгып баскач, тамашачылар залы кинәт тынып калды. Бу минутта чыннан да сокланырлык иде ул* [1, б. 177].

Зәмзәмбикә (гарәп-төрки-татар теленнән) – “зәмзәм суы кебек мул бикә” [2, б. 369]: *Ә **Зәмзәмбикә** – теленә тилчә чыккыры – тыела алмыйча һаман чәпчи, теш агарта, нәрсәгәдер куангандай, башын артка ташлап, бөгелә-сыгыла көлүен белә* [1, б. 209].

“Саф җилләр” роман-дилогиясендә кулланылган исемнәр дөньясына күзәтү ясап чыкканнан соң, түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

№	“Саф җилләр” роман-дилогиясендә кулланылган исемнәрнең этнолингвистик төркемнәре	Саны	Процентларда
1	Гарәп теленнән кергән исемнәр	59	85,5 %
2	Фарсы теленнән алынган исемнәр	2	2,9 %
3	Катнаш (гибрид) ясалышлы исемнәр	8	11,6 %
	Барысы:	69	100 %

Югарыдан күренгәнчә, әсәрдә кулланылган исемнәрнең күбесен (59 – 85,5 %) гарәп теленнән кергән исемнәр тәшкил итә. Икенче урында – катнаш (гибрид) ясалышлы исемнәр (8 – 11,6 %). Фарсы теленнән алынган исемнәр чагыштырмача аз (2 – 2,9 %).

Бүгенге көндә аерым әсәрләрнең поэтик антропонимиясен өйрәнү гаять зур әһәмияткә ия. Тикшеренү барышында тупланган материалларны мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында татар теле һәм әдәбияты, татар ономастикасы кебек фәннәрне укытканда кулланырга мөмкин.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Чыганак

1. Хәсәнов М.М. Саф җилләр: роман-дилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 367 б.

2. Фәнни-теоретик әдәбият

2. Саттар-Мулилле Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: Раннур, 1998. – 488 б.

НАРОДНЫЕ ПРАЗДНИКИ КАК СРЕДСТВО ПРИОБЩЕНИЯ ДЕТЕЙ ДОШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА К НАЦИОНАЛЬНОЙ КУЛЬТУРЕ

Хафизова Ч.М., Габидуллина И.М.

Детский сад № 1 «Ласточка» Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан, Россия

Данная статья посвящена исследованию воспитательных возможностей использования национальной культуры в воспитании детей дошкольного возраста. Выявлено, что праздник является объединяющим средством всех видов искусств и приобщением детей к национальной культуре родного края. Определена воспитательная роль народных праздников.

***Ключевые слова**: народный праздник, дети дошкольного возраста, национальная культура, воспитательная роль.*

FOLK FESTIVALS AS A MEANS OF INTRODUCING PRESCHOOL CHILDREN TO NATIONAL CULTURE

Hafizova C.M., Gabidullina I.M.

Kindergarten № 1 "Sallow", Muslyumovsky district, Republic of Tatarstan, Russia

This article is devoted to the study of educational opportunities for the use of national culture in the education of children of preschool age. It is revealed that the feast is the unifying agent of all kinds of arts and introducing children to the national culture of their native land. Defined the educational role of the national holidays.

***Keywords:** folk festival, children of preschool age, national culture, educational role.*

Воспитание детей является непрерывным и сложным процессом, в котором действует множество факторов как стихийных, так и специально создаваемых, как природных, так и общественных. Оно тесно связано с конкретной исторической эпохой и социальном строем. Произошедшие в нашей стране политические и социально-экономические преобразования неизбежным образом вызывают глубокие изменения во всей системе общественного воспитания, в понимании его целей, направленности и нравственных идеалов.

Однако в современных дошкольных учреждениях нет достаточно разработанной научно-теоретической базы и методических разработок, необходимых для правильной организации национального воспитания детей в целом. Современное общество нуждается в разработке научно-методических основ формирования личности детей дошкольного возраста посредством национальных культур.

Многочисленные исследования К.Д. Ушинского, А.С. Макаренко, В.А. Сухомлинского, К. Насырова, Г. Ибрагимова, М.И. Богомоловой, Р.И. Жуковской, Э.К. Сусловой, С.А. Козловой, Н.Ф. Виноградовой, С.Н. Султановой и других доказывают важность и необходимость использования национальной культуры в развитии и воспитании детей дошкольного возраста.

Праздники и развлечения – яркие и радостные события в жизни детей дошкольного возраста. Сочетая различные виды искусства, они оказывают большое влияние на чувства и сознание детей.

Подготовка и проведение праздников и развлечений способствует нравственному воспитанию детей: они объединяются общими переживаниями, у них воспитываются основы коллективизма; произведение фольклора, песни и стихи о родине, о родной природе, труде формирует патриотические чувства. Разучивая песни, стихи, танцы, дети узнают много нового о своей стране, природе, о людях разных национальностей. Это расширяет их кругозор, развивает память, речь, воображение, способствует умственному развитию.

Праздничная атмосфера, красота оформления помещения, костюмов, хорошо подобранный репертуар, красочность выступлений детей – все это важные факторы эстетического воспитания.

Участие детей в пении, играх, хороводах, плясках укрепляет и развивает детский организм, улучшает координацию движения.

Таким образом, возникает проблема: каковы воспитательные возможности использования национальной культуры в воспитании детей дошкольного возраста?

Наше исследование состояло из нескольких этапов. На первом этапе изучалась и анализировалась психолого-педагогическая, этнографическая национальная литература; велись наблюдения за детьми, проводились беседы с родителями о методах и приемах семейного воспитания; анализировался опыт взаимодействия педагогов с родителями, изучались пособия и методические разработки педагогов по приобщению детей к национальной культуре. На этом этапе были определены цели исследования, объект, предмет, сформирована рабочая гипотеза. На втором этапе выявлялись условия положительного влияния традиций татарского народа на национальное воспитание; была организована опытно-экспериментальная работа, разработаны методические рекомендации для внедрения в практику национального воспитания. На третьем этапе по результатам проведенной опытно-экспериментальной работы осуществлялась их систематизация и обобщение, обработка полученных экспериментальных данных. Мы пришли к выводу, что основными факторами народной педагогики, соответственно и народного воспитания, являются природа, игра, слово, дело, общение, традиция, быт, искусство, религия, пример-идеал (идеи-символы, личности-символы, события-символы).

В процессе воспитания, в процессе ознакомления детей с необходимым материалом создаются благоприятные условия для их дальнейшего умственного развития. Детям предлагается анализировать, сравнивать, обобщать то, что они видят в окружающей жизни или то, о чем расскажет, или прочтет им воспитатель.

Впечатления раннего детства часто остаются в памяти на всю жизнь. Их яркость и богатство могут согреть и украсить душу человека на долгие годы. В общую цепь радостных настроений, незабываемых эмоций детства свои особые чувства и переживания вносят праздники.

Праздники – это радость общения, радость творчества и сотворчества, радость самовыражения, радость раскрепощения и взаимообогащения.

В народных праздниках присутствуют разнообразные виды искусства: литература,

музыка, живопись, театр, пантомима. Таким образом, праздник является объединяющим средством всех видов искусств и приобщающим детей к национальной культуре своего народа. А широкое использование этих средств в работе с детьми позволяет расширить кругозор, сформировать взгляды и нормы поведения ребенка, развить его творческие способности.

В разнообразных видах деятельности проявляются наклонности, формируются определенные умения и навыки. На празднике дети не только говорят, но танцуют, поют, рисуют. Дети учатся подчинять свои движения ритму музыки, различать музыкальные темпы, отражать их в движениях, играх, сопровождая речью. Праздник в детском саду – важная часть жизни ребенка. Это радостное событие, которое позволяет ребенку отдохнуть, развлечься и, вместе с тем, духовно обогащает и приобщает его к национальной культуре.

Проведенная работа показала, что праздники используются для подведения итогов обучения, являются удобной ситуацией для повторения пройденного за последнее время материала.

Полученные результаты позволили сделать следующие выводы:

1. Предварительная работа с детьми показала, что не все дети знакомы с татарской культурой, но вместе с тем большинство детей проявляет интерес к национальной культуре своего края и стремится знать родной язык.

2. Отобранные традиции, обычаи, праздники татарского народа эффективны при обучении и воспитании детей в детском саду.

3. Участие родителей и детей в общих мероприятиях (подготовка праздника, праздник “Науруз”), а также заучивание с детьми стихотворений, текстов татарских песен, консультации позволяет понять родителям значение приобщения детей к национальной культуре.

Праздник – одно из средств полноценного и всестороннего развития личности ребенка дошкольного возраста, который является объединяющим средством всех видов искусств и приобщением детей к национальной культуре родного края.

Список использованной литературы

1. Культура, искусство татарского народа. – Казань, 1993.

2. Рожнова П. Семья в народных традициях // Восп. Шк.. – 1998. – № 5. – 29 с.

3. Харисов Ф.Ф. Национальная культура в учебно-воспитательном процессе. – Казань, 1996.

4. Харисова Л.А. Педагогический потенциал национальной культуры. – Казань, 1996.

БӘЙРӘКӘ МӘДРӘСӘСЕ ТАРИХЫНА ЯҢА МАТЕРИАЛЛАР

Шәрипов А.М.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

НОВЫЕ МАТЕРИАЛЫ ПО ИСТОРИИ БАЙРЯКИНСКОГО МЕДРЕСЕ

Шарипов А.М.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Статья посвящена освещению истории Байрякинского медресе, одного из крупных учебных заведений Поволжья XVIII-XIX вв. В ней использованы новые печатные и рукописные источники в данной области, приведены новые факты и сведения.
***Ключевые слова**: медресе, мечеть, школа, село, история, учеба, наука, знание, личность.*

NEW MATERIALS ON THE HISTORY OF BAYRYAKINSK MADRASAH

Sharipov A.M.

Naberezhnye Chelny Institute of social-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

This article is devoted to describe the history of Bayryakinsk madrasah, one of the largest educational institutions in the Volga region in the XVIII – XIX centuries. New printed and handwritten publications in this area hove been used, new facts and data have been found.
***Keywords**: madrasah, mosque, school, village, history, studies, science, knowledge, personality.*

Октябрь инкыйлабына кадәр халкыбызның иң эре уку йортлары арасында хәзерге Ютазы районының Бәйрәкә авылындагы мәдрәсә дә булган. Әмма аның тарихы әле, безнеңчә, тулысынча өйрәнелеп бетмәгән. Әлбәттә, берәр оешма яки авыл тарихы турында мәгълүмат кирәк булса, без иң элек алты томлык русча "Татарская энциклопедия" хезмәтенә мөрәҗәгать итәбез. (Әле дә ярый безнең шундый бәяләп бетермәслек хәзинәбез бар! Аны язучыларга һәм гамәлгә куючыларга мең рәхмәт!). Менә шул капитал хезмәтнең 2 нче томында (Казан, 2005) Бәйрәкәдәге "Гобәйдия" мәдрәсәсе турында фәнни мәкалә бар (авторлары Р.Р. Салихов, Р.Р. Хәйретдинов. Бу мәкаләнең русчасы 2005 елда, татарчасы "Татар энциклопедиясе"нең 2 нче томында бары 2010 елда гына басылып чыкты). Бу хезмәттә Бәйрәкәдәге "Гобәйдия" мәдрәсәсенең тарихы китерелә. Әмма тормыш алга бара, бу мәкалә дөнья күргәннән соң да фәндә яңа мәгълүматлар пәйда булды. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхреддиннең 4 томлы "Асар" хезмәте басылып чыкты (Казан: Рухият, 2006-2010 еллар), Бәйрәкәдә яшәп вафат булган язучы һәм педагог Кәшиф Рәхимнең (1905-1989) "Бәйрәкә авылы" дигән кулъязма дәфтәре табылды. Шушы хезмәтләрдә "Татар энциклопедиясе"ндә искә алынмаган яңа мәгълүматлар килеп чыкты. Түбәндә шул яңа материалларның бер өлеше китерелә.

Бәйрәкәдә белем һәм мәгърифәт учагына кайчан нигез салынган? Р.Р. Салихов һәм Р.Р. Хәйретдиновлар, мәсәлән, болай яза: "Гобәйдия", Оренбург губ. Бөгелмә өязе (хәзер ТРның Ютазы р-ны) Бәйрәкә авылындагы өченче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсә. Идел буендагы иң зур мөселман уку йортларының берсе. 19 йөздән мәгълүм" [1, б. 131]. Ә Кәшиф Рәхимдә болай диелә: "1912 нче елда Бәйрәкәдәге "Гобәйдия" мәдрәсәсенең 100 еллыгы үткәрелде. Ул юбилейда катнашу өчен Самара большевикларыннан К.М. Төхфәтуллин килә. Ул юбилей турында Төхфәтуллин ага болай сөйләгәне бар: "Гобәйдия мәдрәсәсе төзелүгә 100 ел, гомумән Бәйрәкәдә мәдрәсә оешуга 200 ел" дип уздырылды" [2, б. 4]. Әгәр Кәшиф Рәхим китергән бу мәгълүматны дөрес дип алсак, Бәйрәкәдәге беренче мәдрәсәгә 1712 нче елларда нигез салынган булып чыга. Бәйрәкәдәге уку йортының башлангыч чоры хакында ул болай яза: "1785 нче елга кадәр Бәйрәкәдә законлы мәчет салырга рөхсәт ителми. Югары очтагы куе каен урманы эченә мәчетне кабыклардан оештыралар да, тикшерү килә башласа, сүтеп өя булганнар. Шуның өчен ул мәчет урнашкан мәхәлләне "Кабык мәчет мәхәлләсе" дип йөрткәннәр. 1785 нче елны "Әби патша" татар авылларында мәчет салырга рөхсәт биреп указ чыгаргач, кабык мәчет урынына агач мәчет салына һәм беренче мәхәллә дип атала. Патша хөкүмәте мәчет салырга рөхсәт итмәсә дә, мәдрәсәләр тотуга каршы килмәгән" [2, б. 4].

Шунысы куанычлы, Кәшиф Рәхим үзе белгән, үзе ишеткән хәлләрне түкми-чәчми кәгазьгә төшереп калдырган. Шуның өчен аңа зур рәхмәт! Үзенең әйтүе буенча, әлеге тарихны язган вакытта ул Бәйрәкә авылы турында үзенә кадәр язылган Шәриф Халиков, Фәхретдин Хадмиев һәм Әхмәдиша Әсәдуллиннарның тарихларын укып чыккан һәм үз хезмәтендә файдаланган. Аның бу кулъязма дәфтәрендә, әлбәттә, кайбер төгәлсезлекләр дә булырга мөмкин.

Бәйрәкә мәдрәсәсенең башлангыч чоры турында К. Рәхим: “1812 нче елга кадәр Бәйрәкә мәдрәсәсендә Мөхәммәт Шәриф ишан дигән суфи кеше җитәкчелек иткән”, – дип яза [2, б. 4]. “Татар энциклопедиясе”ндәге мәкаләдә бу шәхес хакында бер сүз дә юк. Ә Р. Фәхреддиннең “Асар” хезмәтендә 1812 елга кадәр үк Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыткан берничә имам-мәдәррис хакында языла. Мәсәлән, Мөхәммәдкол бине Табай дигән кеше хакында: “Ык елгасындагы Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып, 1786 елларда вафат булган. Гыйлем әһелләре арасында белемле вә камил дигән исеме таралган” дигән мәгълүмат бирелә [3, б. 48]. Бу, безнеңчә, XVIII гасырда ук Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыткан, исеме тарихта калган беренче имам һәм мөдәррис булса кирәк.

Бәйрәкә кешеләре миңа шундый бер вакыйга сөйләде: 1800-1810 еллар тирәсендә авылның хәлле кешесе Муса хәзрәт таштан ике катлы мәчет салдыра башлаган. Ә ул заманда мәчетләрне таштан салдыру өчен аерым рөхсәт кирәк икән. Муса хәзрәтнең андый рөхсәт кәгазе булмаган. Чәкән авылындагы чиркәү кешеләре, төзеләчәк мәчеттән көнләшеп, “Муса хәзрәт рөхсәтсез ике катлы таш мәчет салдыра”, – дип, Самара управлениесенә җиткергәннәр. Самарадан тикшерү килгән. Муса хәзрәт куркып калмаган, төзеләчәк бинаның сызымнарын күрсәтеп: “Мин мәчет түгел, чиркәү салдырам. Менә карагыз, гөмбәзе болай булачак”, – дип, түгәрәк гөмбәзне күрсәткән. Тикшерүчеләр каршы сүз әйтмәгәннәр, ышанып кайтып киткәннәр. Ә бина төзелеп беткәч, Муса хәзрәт гөмбәз өстенә тәре түгел, ә ай куйдырган. Шуңа күрә Бәйрәкә мәчете түгәрәк гөмбәзле булган икән.

“Асар”ның 1 нче томында Мөхәммәдкол бине Табайдан соң укыткан башка мөдәррисләр хакында да мәгълүматлар бар. Аларга таянсак, мәдрәсәгә “Гобәйдия” исеме бирелгәнче үк, Бәйрәкәдә өч мәчет булган (ә һәр мәчет каршында үзенең мәдрәсәсе дә булган); аларда Искәндәр бине Гали, Мостафа бине Әхмәр һәм Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим исемле имамнар укыткан. Искәндәр бине Гали хакында Р. Фәхреддин болай яза: “Искәндәр бине Гали бине Ает... Бәйрәкә авылында Мөхәммәдкол бине Табай вафат булгач имам вә мөдәррис булып, 1832 ел 17 июньдә 75 яшендә вафат булган (Димәк, аның яшәгән еллары 1757-1832 булып чыга – Ә.Ш.). Кабере Бәйрәкәдә. Бу зат беркадәр вакыт Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим белән бер мәчеттә имамлык итеп, аннан соң өченче мәчет төзелү илә Мөхәммәдшәриф анда күчә, вә бу зат үзе генә кала. Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим, Искәндәр бине Гали, Мостафа бине Әхмәр исемле өч затның мәдрәсәләре бер урында, фәкать үзләренең хөҗрә-бүлмәләре аерым-аерым биналарда булган, вә шул хәлдә шәкертләр укытканнар. Алар вафат булгач, бу мәдрәсәләрнең барчасы өченче мәчет имамы вә Мөхәммәдшәриф бине Ибраһимның улы булган Гобәйдулла бине Ибраһим тәрбиясенә калган. Ошбу мәдрәсәләр, шул көннән бу заманга кадәр гыйлем эстәүче шәкертләр өчен бер сыену урыны булып, бер-бер артлы алмашынып, олуг һәм файдалы мөдәррисләр укытканнар” [3, б. 132]. Ә Мостафа бине Әхмәр турында “Асар”да болай языла: “Мостафа бине Әхмәр бине Мансур. Бөгелмәдән төн тарафта Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып, 1836 ел, 14 мартта 60 яшендә вакытта вафат булган (Димәк, яшәгән еллары 1776-1836 булып чыга – Ә.Ш.). Кабере Бәйрәкәдә. Мансур исемле бабасы Казан артындагы Балыклы авылыннан Бәйрәкәгә күчеп килгән...

Мостафа бине Әхмәр, бу җирлектә булган остазлары хозурында гыйлем алгач, Бохарага барып, рәсми дәресләр белән мәшгуль булган вә, беркадәр еллар торгач, бу мәмләкәткә кайтып, Уфа илә Бөгелмә арасында зур почта юлы өстендә булган Япрук авылына имам булган. Ул авылда 9 ел торганнан соң, мәхәллә халкы илә дуслыгы киткәнгә, Бәйрәкә авылында булган баҗасы Фәйзулла бай бине Гали күрсәтүе һәм

тырышлыгы илә Бәйрәкәдә икенче мәчет хозурына күчкән һәм дәрес әйтү илә дә мәшгуль булган. Хатыны Маһруй исемле булган”, – диелә [3, б. 145].

Шулай итеп, нәтиҗә ясарга мөмкин: XIX гасыр башында Бәйрәкәдә өч мәчет булып, беренче мәхәлләдә Искәндәр бине Гали бине Ает, икенчесендә Мостафа бине Әхмәр бине Мансур һәм өченчесендә Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим имамлык вә мөдәррислек иткәннәр. Шулардан соңгысы, безнеңчә, аеруча зур һәм күренекле шәхес булган, ахрысы. “Асар”да аның тормышы шактый тулы тасвирланган. Шул мәкаләдән кайбер мөһим өлешләрен китереп узыйк.

Бу гыйлем иясенең тулы исемен Р. Фәхреддин “Мөхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви” дип атый һәм болай яза: “Үргәнеч мәмләкәтендә вә Яңа Үргәнеч шәһәренә 4 чакрымда булган Чекә атлы урында ишанлык итеп, 1841 елда вафат булган. Асылы типтәр таифәсеннән булып, ни вакыттадыр Бохарага сәфәр иткән. Хәлифә Ниязколый әт-Төрекмәни белән аралашкан (Әйтергә кирәк, күп кенә татар укымышлылары Ниязколый әт-Төрекмәнидән белем алганнар – Ә.Ш). Бу мәмләкәткә кайткач, Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында имам вә мөдәррис булып шәкертләр укыткан вә тәрбияләгән. Шул чорда Бәйрәкәнең мәшһүр байларыннан Исхак бине Гали бине Ает... исемле кешенең Шәмсекамәр исемле кызын никахлаган. Күпмедер вакыт торганнан соң, үз теләге беләнме, шәехе ишарәсенә күрәме, балаларын Бәйрәкәдә калдырып, 1815 елда Бохарага шәех Төрекмәни хозурына киткән вә аннан югарыда аталган Үргәнечтә, Чекәдә торган” [3, б. 178]. Шушы ук мәкаләдә Мәхәммәдшәрифнең монда калган балалары Әбүнәгыйм, Таҗенниса һәм Мәръям, аларның тормыш юллары хакында да шактый тулы язылa, балаларының хатлары да китерелә. Ул хатларның берсендә (Р. Фәхреддин: “Фикеребезчә, хат Мәхәммәдшәрифнең үз улы Мөхәммәдзакир әфәнде (Чекәдә өйләнгән икенче хатыныннан туган улы) тарафыннан язылгандыр”, – ди – Ә.Ш.) Мәхәммәдшәрифнең Бәйрәкәдән күчеп китүенең сәбәбе болай аңлатыла: “Мәгълүмдер ки, атабыз Бәйрәкә авылында Исхак бай дигән кешенең кызын алып, беркадәр вакыт әлеге бай мәдрәсәсендә мөдәррислек итеп йөргәндә, хатыны дөньядан киткән. Әлеге Исхак бай исә икенче кызын бирергә булгач, атабыз, кабул итмичә, һәммә китап, мал вә башка нәрсәләрен бер угыл вә кызына ташлап, үзе Бохараи шәрифкә килгән. Берничә еллар укыганнан соң, Харәзмгә килеп, Үргәнеч ягындагы бер мәсҗидкә имам булган вә шул мәхәлләдән өйләнгән. Биредә 30 елдан артык дин гыйлеме укытып, Аллаколый хан заманында вафат булган. Вафат вакытында өч угылы вә бер кызы, хатыны калган. Бу вакыт атабызга 56 яшь булган” [3, б. 179]. Димәк, Мөхәммәдшәриф 1785 тә туган һәм 1841 дә вафат булган икән.

Шушы ук мәкаләнең икенче бер җирендә: “Күчеп киткәннән соң, урынына үз тарафдарларыннан Гобәйдулла бине Ибраһим исемле зат калган”, – дип күрсәтелә [3, б. 179]. “Асар”ның 2 нче томында бу фикер тагын кабатлана; Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт турында язганда, Р. Фәхреддин әлеге Гобәйдулла хәзрәтнең улы Габделгалинең “Дамелла Мәхәммәдшәриф бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви күчеп киткәндә үз урынына имам булу һәм шәкертләр укыту өчен әтиебезне билгеләде” дигән сүзләрен китерә [4, б. 22]. “Татар энциклопедиясе” авторлары исә “Гобәйдия” мәдрәсәсенең тарихын бары Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәттән генә башлана дип күрсәтәләр; алар болай яза: “Гобәйдия”, Оренбург губ. Бөгелмә өязе (хәзер ТРның Ютазы р-ны) Бәйрәкә авылындагы өченче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсә. Идел буендагы иң зур мөселман уку йортларының берсе. 19 йөздән мәгълүм. Махсус төзелгән бинада урнаша (19 йөз ахырыннан). Мәдрәсәне нигезләүче һәм мөдәррисе авылның 3 нче мәхәллә имам-хатибы, дин белгече, шәригать белеме буенча аңлатмалар һәм хезмәтләр авторы Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт (1785-1845) була” [1, б. 131]. Биредә, безнеңчә, ике урынга төзәтмә кертергә кирәк. Беренче, “Асар”дан китерелгән өзекләрдән күренгәнчә, Бәйрәкәдәге мәдрәсәне нигезләүче Гобәйдулла бине Ибраһим бине Ишкуәт булмый; ул 1815 елда мәдрәсәдә имам булып эшли башлаганда (алда әйтелгәнчә, Мөхәммәтшәриф хәзрәт Бәйрәкәдән 1815 елда китә), мәдрәсәгә инде күптән нигез салынган була. Мәдрәсәнең “Гобәйдия” дип аталуы турында Кәшиф Рәхим болай ди: “Гобәйдулла ишан заманга карабрак эш иткән. Мәдрәсәне “Гобәйдия мәдрәсәсе” дип игълан иткән. Анда шәкертләр

кунып-ятып укыганнар, чөнки анда авыл кешеләренең балалары укытылмаган. Сирәк-мирәк кенә мулла һәм эре кулак балалары гына укыган" [2, б. 4]. Икенчедән, Гобәйдулла хәзрәтнең вафат булган елы, әгәр Р. Фәхреддингә таянсак, бик үк дөрес түгел. Р. Фәхреддин болай яза: "Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылында имам булып, 60 яшьләренә ирешеп, 1261 елның 1 мөхәррәмендә (1844 ел 29 декабрь) вафат булган" [4, б. 22]. Биредә Гобәйдулла хәзрәтнең үлгән көнен һиҗридән миладига күчергән вакытта, әлбәттә, бер-ике көнгә ялгышырга да мөмкин, Р. Фәхреддин "1844 елның 29 декабре" дисә, Р.Р. Салихов белән Р.Р. Хәйретдиновлар "1845 ел" диләр. Бу, безнеңчә, әлләни зур аерма түгел.

Сорау-җавапта 117 ир-ат һәм 132 хатын-кыз катнашты. Соралучыларның күпчелеге яшьләр һәм урта яшьтәгеләр булды. 25 яшькәчә категорияне ир-атлар 30%, хатын-кызлар 36% тәшкил итте. 26-35 яшьтәгеләрнең саны якынча тигез – 44-45%. 36-50 яшьлек ир-

атлар 23%, хатын-кызлар 15% булды. Әйтергә кирәк, өлкән буын кешеләренең өлеше бик аз: ир-атларда – 3%, хатын-кызларда – 5%.

Сорау-җавапта катнашкан ир-атларның 41% – өйләнмәгән, 46% – өйләнгән, 13% – аерылган, тол булганнары юк. Хатын-кызларның 27% – кияүдә түгел, 46 % – кияүдә, 25% – аерылган, 2% – тол булганнары.

“Сез үзегезне мөселман дип саныйсызмы?” – дигән сорауга ир-атларның һәммәсе дә уңай җавап бирде, хатын-кызлар арасында исә 132 кешедән берсе тискәре җавап бирде.

“Сез намаз укыйсызмы?” – дигән сорауга ир-атлардан 3% юк, 1% кайвакыт укыйм, 9% калдырмаска тырышам, 87% бервакытта да калдырмыйм, дип җавап бирделәр. Хатын-кызлардан шул ук сорауга 8% юк, 10% кайвакыт укыйм, 24% калдырмаска тырышам, 58% бервакытта да калдырмыйм, диделәр.

Булачак хатынның динлелегенә игътибар итү мөһимлеген ир-атларның 91% раслады. 6% бу аспектны файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, дип тапты. 3% мөһим түгел, диде. “Булачак ирнең динлелегенә игътибар итү мөһимме?” – дигән сорауга хатын-кызларның 94% әйе, бу мөһим, дип, 6% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, дип җавап бирделәр, әмма мөһим түгел диючеләр булмады.

Булачак хатынның дин тотуы (намаз укуы, ураза тотуы, яулык кию һ.б.) ир-атларның 83% өчен мәҗбүри булуы ачыкланды. 14% моны кирәкле, ләкин мәҗбүри түгел, дип саный. Бары 3% мөһим түгел, дип җавап бирделәр. Булачак ирнең дин тотуы (намаз укуы, ураза тотуы һ.б.) хатын-кызлар өчен дә бик әһәмиятле. Соралучыларның 84% моны мәҗбүри, диде, 12% кирәк, ләкин мәҗбүри түгел, дип тапты. 4% мөһим түгел, дип җавап бирделәр.

Шулай итеп, югарыда телгә алынган җаваплардан күренгәнчә, ир-атлар өчен дә, хатын-кызлар өчен дә булачак тормыш иптәшенең динле булуы бик әһәмиятле. Әйтергә кирәк, динлелек сүзен төрле кеше төрлечә күзалласа да, һәр ике як та тормыш иптәшен намазлы, уразалы итеп күрергә тели, ир-атлар хатынының яулык киюен тиешле дип саный һәм бу, әлбәттә, шәригать кануннарына туры килә.

Булачак хатынның ата-анасының динле булулары хакында карашлар ул кадәр катгый түгеллеге ачыкланды. Ир-атлардан 29% кына моны тиешле һәм бик мөһим, дип тапты. 58% исә кирәкле, ләкин мәҗбүри түгел, диде, ә 13% мөһим түгел, дип җавап бирделәр. Булачак ирнең ата-анасының динле булулары турында хатын-кызларның фикере ир-атларныкыннан әллә ни аерылмый. Аларның 31% бу аспектны тиешле һәм бик мөһим, дип исәпли, 55% кирәк, ләкин мәҗбүри түгел, ди, ә 14% мөһим түгел, дип саный.

“Булачак хатынның милләтенә игътибар итү мөһимме?” – дигән сорауга ир-атларның 22% бик мөһим, дип, 32% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, дип җавап бирде. Ә соралган ир-атларның 46% өчен хатынының нинди милләттән булуы бөтенләй мөһим түгел. Хатын-кызлар өчен милли компонентның роле зуррак булуы ачыкланды. Аларның 36% бик мөһим, 36% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, 28% мөһим түгел, дип җавап бирделәр.

Бу ике сорауга бирелгән җавапларга карагач, Русия мөселманнарының яшь вәкилләре дини, милли мохиттә тәрбияләнмәгәнлекләре күренә. Шуның нәтиҗәсендә алар үзләре дә моңа зур әһәмият бирми.

“Булачак хатынның һөнәренә игътибар итү мөһимме?” – дигән сорауга ир-атлардан 29% тиешле һәм бик мөһим, дип, 42% кирәк, ләкин мәҗбүри түгел, дип, 29% мөһим түгел, дип җавап бирделәр. Булачак ирнең һөнәренә таләп зуррак. Хатын-кызлардан 45% аны тиешле һәм бик мөһим, дип тапты. Тагын 45% кирәкле, ләкин мәҗбүри түгел, диде. Бары 10% хатын-кызлар ирнең һөнәренә игътибар итү мөһим түгел, дип җавап бирделәр.

Булачак хатынның бай булуының әһәмияте ир-атлар өчен юк дәрәҗәсендә. 7% респондентлар өчен генә бу бик мөһим булып чыкты. 38% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, 56% мөһим түгел, дип җавап бирделәр.

“Булачак ирнең байлыгына игътибар итү мөһимме?” – дигән сорауга хатын-кызлардан 30% бик мөһим, диде, 55% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, дип саный, 15% мөһим түгел, дип җавап бирделәр.

Һөнәргә килгәндә, хатын-кызларның ир-атларга карата таләпләре зуррак икәнлеге ачыкланды. Булачак тормыш иптәшенең байлыгына соралучыларның яртысы игътибар белән караса да, ир-атларның нибары 7% аның мөһимлеген таныды. Ә хатын-кызларның өчтән бере булачак иренең бай булуын бик мөһим, дип күрә.

Булачак хатынның мәдрәсәне яки югары мөселман уку йортын бетергән булуы ир-атларның 5% өчен генә бик мөһим булып чыкты. 62% бу аспектны файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, дип, 33% исә мөһим түгел, дип уйлый. Бу сорауга хатын-кызларның карашлары да әллә ни аерылмый. Булачак ирнең мәдрәсәдә яки югары мөселман уку йортында белем алып чыгуын 14% хатын-кыз бик мөһим күрә. 54% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, ди. 32% мөһим түгел, дип саный.

Булачак хатынның дөньяви урта-һөнәри яки югары белемгә ия булуы да ир-атлар өчен әһәмиятле түгел. Бары 7% моны бик мөһим, диде. 49% файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, 44% мөһим түгел, дип җавап бирделәр. Хатын-кызларның бу мәсьәләгә таләбе зуррак икәне ачыкланды. Аларның 30% өчен булачак ирнең дөньяви урта-һөнәри яки югары белемгә ия булуы бик мөһим. 50% моны файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, дип саный, 20% мөһим түгел, дип әйттеләр.

Әйтергә кирәк, дини һәм дөньяви белемгә ия булуны хәзерге мөселманнар бик зарур, дип санамый. Дөнья һәм шәригать күзлегеннән караганда, бу тискәре күренеш булып тора. Ислам дине кешене, кирәк ир-ат, кирәк хатын-кыз булсын, дини һәм дөньяви белем алырга чакыра. Гыйлемсез кешенең балаларына яхшы тәрбия бирүе бик шөбһәле.

Яшь мәсьәләсенә килгәндә, булачак хатынның иреннән яшьрәк булуын ир-атларның 25% тиешле, дип күрә. 34% кирәкле, ләкин мәҗбүри түгел, ди. 41% исә мөһим түгел, дип җавап бирделәр. Булачак ирнең яшькә зуррак булуын хатын-кызларның 20% тиешле, дип тапты. 50% моны кирәк, ләкин мәҗбүри түгел, диде. 30% өчен бу мәсьәләнең мөһим түгеллеге ачыкланды.

Булачак хатынның чибәрлеге ир-атларның 56% өчен бик мөһим булып чыкты. 35% моны файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, диде, 9% исә әһәмиятсез, дип тапты. Булачак тормыш иптәшенең чибәрлеге хатын-кызлар өчен дә әһәмиятле икән. Аларның 46% бу мәсьәләгә бик мөһим, дип карый. 43% аны файдалы, ләкин мәҗбүри түгел, ди. 11% мөһим түгел, дип җавап бирделәр.

Гомуми нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: мөселманнар гаилә төзегәндә булачак ир һәм хатынның дин тотуына зур әһәмият бирә, һәм бу яхшы күренеш. Әмма гыйлемгә һәм ата-аналарның дини булуларына игътибарның азлыгы булачак буыннарны тәрбияләүдә тискәре чагылыш табарга мөмкин. Бүгенге яшьләргә, буыннан буынга күчеп килгән, 20 нче гасырда өзелгән дини тәрбия чылбырын ялгарга туры килә. Бу зур эштә гаиләне ныгыту һәм тотрыкландыру – иң зарури мәсьәләләрнең берсе. Шуның өчен яңа гаилә төзүчеләр өстендә дини гыйлемне үстерү, үзләрендә һәм балаларында күркәм әхлакны тәрбияләү бурыч булып тора.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Аз-Зухайли В. Мусульманская семья в современном мире / Пер. с ар. Е.М. Сорокоумовой. – М.: Аль-Китаб, 2009. – 504 с.

2. Аль-Бухари М. Сахих Аль-Бухари. В 4 т. – Каир: Ас-Саляфия, 1979.

3. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы: Татар гимназияләре һәм лицейлары 11 нче с-фы, педагогия колледжлары, училищелары өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2000. – 183 б.

4. Ибн Аль Хумам М. Фатх аль-Кадир. В 8 т. – Каир: Амирия, 1897.

5. Маргинани Б. Никах и талак (отрывки из книги «Хидоя») / Пер. с англ. под редакцией Н.И. Гродекова. – Казань: ОАО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идел-Пресс», 2010. – 423 с.

6. Шәймәрдәнов Р.Х. Татар милли педагогикасы: Югары һәм урта педагогика уку йортлары өчен уку ярдәмлеге / Р.Х. Шәймәрдәнов, Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

ГАИЛӘ ТРАДИЦИЯЛӘРЕНДӘ ҺӘМ ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТТӘ ДИНИ ТӘРБИЯ

Сафиуллина Н.З., Шәрипова Г.Ә.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Яр Чаллы шәһәре, Россия

РЕЛИГИОЗНОЕ ВОСПИТАНИЕ В ВЗАИМООТНОШЕНИЯХ И СЕМЕЙНЫХ ТРАДИЦИЯХ

Сафиуллина Н.З., Шарипова Г.А.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

В статье анализируется роль религиозного воспитания в взаимоотношениях и семейных традициях. На основе фактического материала выявляются некоторые проблемы в воспитании подрастающего поколения, указываются пути выхода из проблемных ситуаций.

***Ключевые слова**: Ислам, Аллах, Коран, Мухаммед, воспитание, семья, дети.*

RELIGIOUS EDUCATION IN RELATIONSHIPS AND FAMILY TRADITIONS

Safiullina N.Z., Sharipova G.A.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

The article analyzes the role of religious education in relationships and family traditions. On the basis of factual material are revealed some problems in the education of the younger generation, are suggested solutions to challenging situations.

***Keywords:** Islam, Allah, Koran, Muhammad, education, family, children.*

Тәрбия өлкәсендә ислам дине зур әһәмияткә ия. Ислам – яхшылыкка өндәүче тынычлык дине. Ул бөтен кешеләрне дә хөрмәт итәргә һәм хакларын үтәргә куша. Ислам дине кануннарының яшәешебезнең барлык якларына (әхлагыбызга, чисталыгыбызга, сәламәтлегебезгә һ.б.) уңай йогынты ясаганын белмәгән кеше сирәктер, мөгаен.

Ислам дине аша килеп кергән әдәп, чисталык, иманлылык, биргән вәгъдәңә тугры калу кебек матур сыйфатлар халкыбызның борынгыдан килгән традицияләре белән бик тыгыз бәйләнештә тора. Ислам дине тәрбиясе – иң гүзәл тәрбияләрнең берсе. Күренекле мәгърифәтчебез Р. Фәхреддин "яшь буынны тәрбияләү эше – ул бик мөһим мәсьәлә, һәм без бу өлкәдә ислам диненә таянабыз" дигән фикер уздыра [2, б. 27; 4, б. 35].

Р. Фәхреддиннең бала тәрбияләү, гаилә ныклыгына һәм бәхетенә ирешү, үзеңне җәмгыятьтә тоту кагыйдәләренең, нәсыйхәтләренең үтемле, тормышчан булуының төп сере, чыннан да, аларны дин белән бәйләп аңлатуындадыр. Ул, дин тарихын бөтен нечкәлекләре белән өйрәнгән галим буларак, аның кануннарына җаны-тәне белән үзе ышанган һәм меңәрләгән шәхесләрнең тормышына диннең бары уңай тәэсир ясаганлыгын өйрәнеп, шул бай тәҗрибәне милләтенә җиткерү максатын куйган. Чөнки, бала шәхес буларак тулысынча ачылсын өчен, аның янында аны аңлаган, ягымлы сүзләр белән җылыткан, кирәк чакта яклый белгән ата-анасы булырга тиеш. Гаилә – баланың иң

төп тәрбиячесе, тотрыклы гаилә традицияләре булмаган өйдә балага дөрес тәрбия бирү, аны әхлаклы итеп үстерү дә бик авыр була. Р. Фәхреддин ислам диненә галим буларак, фән күзлегеннән чыгып карый. Аның өчен ислам дине – Әдәп, Әхлак, Шәфкать, Изгелек, Итагатьлелек, Кешелеклелек, Намус, Сафлык, Пакьлек, Гаделлек, Яхшылык һәм башка күп күркәм төшенчәләрне эченә алган һәм бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләр генә эшләргә өндәгән кануннар тупланмасы һәм тәртип, тәрбия һәм әхлакның нигезе, гаиләдә тәртип сакчысы, тормышның төзек, гомерләрнең бәрәкәтле һәм файдалы узуы өчен кирәкле дин.

Ислам мәдәнияте Ислам әдәбенә нигезләнә. Әдәп – гарәп сүзе, гадәтне аңлата, моңа тәрбия, яхшы холык, үз-үзеңне тота белүчәнлек, кешеләр белән аралаша белү төшенчәләре керә. “Әдәп” сүзе этик һәм иҗтимагый әһәмияткә ия. Ислам мәдәнияте Исламның ике төп чыганагына нигезләнә, болар – Коръән һәм Сөннәт, Пәйгамбәребезнең эш-гамәлләре, сүзләре һәм турыдан-туры күрсәтмәләре. Коръән һәм Сөннәттә барча вакытларда кешелек җәмгыятендә килеп туа торган проблемаларны чишү өчен кирәкле киң принциплар бар. Алар тормышның төрле өлкәләренә – дини, иҗтимагый, икътисадый, сәяси өлкәләренә кагыла. Дини өлкәдә мөселман булган һәр кешегә биш вакыт намазын укырга, ислам таләп иткәнчә генә яшәргә кушыла. Сәяси өлкәдә – ислам динендә көчләүгә, экстремизмга, терроризмга, җәберләүгә урын юк. Динебез һәрбер кешегә, аның тәненең төсенә, диненә, милләтенә карамастан, хөрмәтлек, изгелек кылырга куша [6, б. 15-18]. Ислам – кешенең натурасын һәм аның ихтыяҗларын тулысынча аңлаучы система ул. Ислам тормыш чынбарлыкларын таный һәм һәм аларга практик якын килергә тырыша. Ислам гадәтләре тормышны катлауландыру өчен канунилаштырылган ритуаллар җыелмасы түгел, ә алар көндәлек тормышны оештыру, аңа ритм бирү, тотнаклылык һәм ачыклык кертү өчен хезмәт итәләр. Ислам әдәбенең иң төп нигезләренең берсе – әхлаклылык. Ул милләт көченең нигезе. Шулай ук әхлаксызлык – милләтнең таркалуының, түбән тәгәрәвенең төп нигезе. Әхлаклылык милләтнең сәламәтлеге өчен мөһим роль уйный. Яшь буынны иманлы, инсафлы итеп тәрбияләүдә ислам диненең иҗтимагый әһәмияте зур. Ислам – җан, тән пакьлеге. Ул – әхлаклылык, ярдәмчеллек үрнәге. Намуслы, юмарт, ярдәмчел булу, дөреслекне яклау, эчкерсезлек, кунакчыллык – кешене күркәм итүче сыйфатлар. Ата-анага игелек кылу, сабырлык кебек сыйфатларны да безгә ислам дине кануннары өйрәтә. Ислам әхлагын саклаган һәр кеше дә сау-сәламәт һәм рухи яктан көчле була [5, б. 55-60]. Үзенең рухи үсешендә югары әхлакый биеклеккә ирешкән кеше генә гомере буе шул югарылыкта калырга омтылып яши. Ялгышлыклар җибәрсә, вөҗдан газабы кичерә, хаталарын төзәтү юлларын эзли. Әхлаклылык кешенең гадәти сыйфатына әйләнсен өчен, моңа аны балачактан ук гадәтләндерергә кирәк.

Ислам диненең өйрәтүләре тормышның барлык өлкәләрендә дә чагылыш таба. Ислам әдәбенең иң төп максатларыннан берсе – кешеләрне бар нәрсәдә игелекле һәм йомшак булырга өйрәтү.

Моңа мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә була:

- Очрашканда елмаерга тәкъдим ителә.
- Кычкырмыйча, шул ук вакытта әңгәмәдәшең ишетерлек итеп сөйләшергә кирәк.
- Бәхәсләшкән вакытта да сөйкемле булып калырга кирәк.

Чираттагы максат – башкаларны хөрмәт итү. Моңа беренче чиратта түбәндәгеләр керә:

- Башка халыкларның динен мыскыл итү яки көлү тыела.
- Кем дә булса берәүгә карата әдәпсез сүзләр белән шаярту.

Ислам әдәбе медицина һәм гигиена буенча да кешеләргә тәрбия бирә. Ислам кешеләрне һәрвакыт чиста булырга өйрәтә. Исламда алкоголь куллану тыела, чөнки алкогольнең тормышның бөтен өлкәләренә дә зыян китергәнен беләбез.

Ислам әдәбе милли икътисадка булыша: әрәм-шәрәм итү тыела, саклык хуплана, хәтта таләп ителә [3, б. 135-147].

Ислам әдәбе өйләнү, гаиләгә дә бик катгый таләпләр куя. Ләкин ислам әдәбе туйның өйләнешүчеләргә авыр йөк булуына каршы.

Ислам әхлагында ата-аналар белән балалар арасында мөнәсәбәтләр мөһим урын алып тора. Мөхәммәт пәйгамбәр: "Җәннәт аналарның аяк астында", – дип әйткән. Башка кешеләргә карата яхшы мөгамәләдә булу әдәплелек саналса, ата-аналарга карата бу инде дини бурычлар булып торалар.

Ислам гадәтләре кешене үз-үзен тотышын контрольдә тотарга һәм акыл тавышына колак салырга өйрәтә. Түземлелек, ачуыңны баса белү (билгеле, башкаларга зыян салмыйча), төгәллек, үз-үзеңне тәртипле тоту бик мөһим.

Тәртиплелеккә түбәндәгеләр кирә:

- чаманы белү;
- вакытны дөрес файдалану.

Вакыт кешенең Аллаһы биргән тормыш кыйммәтләрен үлчәү берәмлеге булып тора, кеше һәр минутның файдалы үтүе өчен җаваплы [1, б. 134-138].

Безнең уйлавыбызча, нәтиҗә ясап әйткәндә, Ислам дине – гадел, чиста, кешелекле диннәрнең берсе. Тәрбия өлкәсендә дә диннең әһәмияте әйтеп бетергесез дәрәҗәдә югары. Дин тыелган замана безнең җәмгыятебезгә төзәтеп булмаслык тәрбиясезлекне бирде инде. Хәзер дин күтәрелеш юлында. Соңгы елларда Татарстан Республикасында яшүсмерләрне Исламга тарту, мәхәлләләргә профессиональ кадрлар, мөселман уку йортларына имам-хатыйб һәм мөгаллимнәр әзерләү максатыннан, профессиональ мөселман уку йортлары системасы булдырылды. "Милли тормыш һәм дин" дигән I Бөтенроссия татар дин әһелләре форумнары оештырыла. Саф татар телендә "ТНВ - Татарстан", "ТНВ - Планета", "Башкортстан" телеканаллары программалары, "Дин вә мәгыйшәт" газетасы да безгә бик файдалы. Татар телендә эшләүчеләр дини сәхифәләр, интернет челтәрендә Татарстан һәм Бөтенрәсәй мөселманнарының мәгълүмат агентлыгы булдырып, кешеләргә ислам дине турында көннән-көн күбрәк мәгълүмат бирәләр. Дини сәхифәләр өлкәннәр өчен генә түгел, яшьләр өчен дә файдалы. Мәсәлән, "Татар радиосы"нда көн саен "Иман нуры" сәхифәсендә ислам динендә кеше нинди булырга тиешлеге турында 2 минутлык вәгазь укыйлар. Ул бүгенге көндә ата-баба йоласын, гореф-гадәтләребезне, динебезне, телебезне саклап тора.

Шуңа күрә, тормышыбыз матурланыр, бозыклыклар, наркомания кебек начар чирләр үсеш алмас дип ышанасы килә.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Ибраһимов Н., Бикчәнтәев К., Мадияров Ә., Низамиев А. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: "ДОМ ПЕЧАТИ", 2001. – 134-138 б.
2. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Р. Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. III кисәк. – Казан, 2007.
3. Студеникин М.Т. Дөньяви этика нигезләре. – Мәскәү: "Русское слово", 2012. – 135-147 б.
4. Фәхреддин Р. Нәсыйхәт. Әхлак гыйлеменнән. – Казан: "Мәгариф", 2005.
5. Харисова Л.А. Иминлек һәм игелек дине. – Казан: "Мәгариф", 2001. – 5-9 б.
6. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә. – Казан: "Мәгариф", 2001.

РӘШИТ БӘШӘР ШИГЫРЬЛӘРЕ АША МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРГА ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ БИРҮ

Смирнова А.Ф.

4 нче санлы "Шаянкай" балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәре, Россия

ЭКОЛОГИЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ ДЕТЕЙ ДОШКОЛЬНОГО ВОЗРАСТА НА ПРИМЕРЕ СТИХОТВОРЕНИЙ РАШИТА БАШАРА

Смирнова А.Ф.

Детский сад № 4 «Веселинка» г. Набережные Челны, Россия

Данная статья посвящена исследованию языка и стиля стихотворений известного детского поэта Рашита Башара, т.е. определению роли изобразительных средств при описании природы. Широко использованные в произведениях выразительные средства представляют собой важный способ достижения художественности, изобразительности и точности речи. Все это подтверждается богатым фактическим материалом. Определена их идейно-эстетическая роль в экологическом воспитании детей дошкольного возраста.

***Ключевые слова**: язык и стиль стихотворений, выразительные средства, экологическое воспитание.*

ENVIRONMENTAL EDUCATION OF CHILDREN OF PRESCHOOL AGE CHILDREN THROUGH POEMS RASHIT BASHAR

Smirnova A.F.

Kindergarten № 4 “Veselinka”, Naberezhnye Chelny, Russia

This article is devoted to the study of language and style of poems known children's poet Rashit Bashar. Widely used in the works means of expression are an important way to achieve the artistic, visual and speech accuracy. All this is confirmed by a wealth of factual material. Determine their ideological and aesthetic role in ecological education of preschool children.

***Keywords:** the language and style of the poems, expressive means, environmental education.*

Шигърият, шигъри сүз – илаhи төшенчә. Шуңа күрәдер шигърияттәге образ, фикерләүләр табигать дөньясы аша, сихри күренешләр аша күзаллана. “Поэзия – тирә-як дөньяны шагыйрьнең үзенчә кабул итүенең дә, әдәби телне һәм гомум халык телен кулланунның да үзенчә бер төре” [4, б. 21], – дип билгели галим Х. Курбатов.

Кеше борынгы заманнардан ук баласын ана теленә өйрәткән, тел хәзинәсенең матурлыгын аның күңеленә сеңдерергә тырышкан. Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә дә иң мөhим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Ә бу максатларны тормышка ашыруда нәфис сүз, әдәби әсәрләрнең әhәмияте гаять зур. Әдәби әсәр балаларның логик фикер йөртүен үстерә, дөньяны танып-белергә өйрәтә. Алай гына да түгел, матур әдәбият әсәрләре балаларны әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияләүгә булышлык итә.

Балачак бит ул – гаҗәеп киң төшенчә, ә балалар әдәбияты – балачакның көзгесе. Ул көзгегә карасаң, анда балалар дөньясы, малайларыбызның, кызларыбызның самими һәм ихлас тормышы, балачакның якты да, татлы да, шул ук вакытта тылсымлы да сәхифәләре дә ап-ачык булып күренеп тора. Балачак ул – чыннан да, үзе бер кабатланмас олы дөнья.

Ә менә балалар өчен язучы әдипләр сабыйлар күңеленә ачкыч таба беләләр. Шул алтын ачкыч белән балалар дөньясының капкасын ачып керәләр, укучыларны шул кызыклы дөнья белән таныштыралар. Балаларның күңел дөньясын тоеп, аңлый белүче әдипләребезнең берсе – Рәшит Бәшәр. Аның шигърияте тулысынча сурәтлелеккә нигезләнгән. Нәниләр өчен язган шигырьләрендә ул заманча тормыш күренешләрен, вакыйгаларны балалар күңеленә, аңына җиңел барып җитәрлек, аларда хыялый кызыксыну

уятырлык шигъри образлар, мажаралы детальләр аша бирергә омтыла, шул рәвешчә, турыдан-туры үгет-нәсыйхәтсез генә, баланың аң-белем, әхлакый тәрбиясенә педагогларча уңай йогынты ясый. Кечкенә генә шигырьдә дә хәрәкәт, вакыйгалар агышы өстенлек итә, бу исә укучыны фикер йөртергә, уйланырга этәрә. Бу яктан караганда темабыз актуаль булып тора. Барлык шагыйрьләр дә иҗат процесында төрле поэтик алымнар кулланалар. Поэтик әсәр нигезендә образлылык ята. Хезмәтебездә әнә шул образлылык тудыруда Рәшит Бәшәрнең табигать дөньясына – үсемлекләргә, кош-кортларга, җәнлекләргә, бөҗәкләргә, күк җисемнәренә мөрәҗәгать итүе үзәккә куеп тикшерелә, алар аша табигатькә мәхәббәт тәрбияләү, экологик проблемаларны чишү алымнары өйрәнелә.

Рәшит Бәшәров табигать хозурлыгында кешенең зурлыгын күрә, балаларга аңлаешлы итеп, шигъри бизәкләр белән моны тасвирлап бирә. Менә әти кеше кибән сала, апа кеше кибән очлый.

Ә мин аларга карап
Буш арбада утырам.
Әти бөтен болынны
Күтәрә дип торам.
Өелә кибән, өелә...
Кибән очы кояшка
Тиде дә инде, әнә! [5, б. 196-197].

Рәшит Бәшәровның көчле ягы – әйләнә-тирәне рәссамча күрә, табигатькә җан өрә белүендә, һәм, бигрәк тә, балалар күңелен аңлый, дөньяга алар күзе белән карый алуында. Шуңа да ул – балалар тәрбиячесе.

Әдипнең әсәрләрен укыганда кеше белән табигатьнең берлеген тоясың. Бигрәк тә сабый баланы табигатьтән аерып күз алдына китерүе кыен.

Рәшит Бәшәрнең әсәрләрендәге табигать күренешләрен берничә төркемгә бүлеп карарга була. Беренчедән, аның әсәрләрендә күп урын җәнлекләрне, кошларны һәм бөҗәкләрне тасвирлауга бирелә.

Шигырьләрдә иң беренче күзгә ташланган һәм күңелгә үтеп кергән образ – ак ат (колын) образы. Р. Бәшәр иҗатында иң камил һәм тирән мәгънәдә эшләнгән образ. Аны хәтта балачакның төп символы буларак та карарга мөмкиндер:

Ап-ак атка атланып,
Әй килә бер юртасы!..
Иң матур чагы җәйнең,
Авылда җәй уртасы. “Җәй уртасы” [2, б. 11].

“Болын” шигырендә бу символ тагын да ныграк ачыла. Монда балачакның бөтен төсе, авазы, көе-моңы, ымы-хәрәкәте дә бар: уйнак ак ат, җәй, кибән, кояш. Рәшит Бәшәр иҗатындагы гомумиләштерелгән балачак образы шундый: ихлас, самими, яп-якты, кояшлы, уйнак һәм хыялый. Дөрес, вакыты-вакыты белән төсләр үзгәрә, караңгыланып китә, авазларга шом керә, вакыйгалар кискенләшә, хисләр авырая; укучы тоя: яшәеш, тереклек дөньясы камил түгел шул.

Сабый җанлы шагыйрь үзенең шигырьләрендә дә бала булып кала, балаларча яза. Ул ихлас сөйли, әйткән сүзе ышандыра. Аю баласы черкиләр белән уйнап йөри, җиләк өзә, чигүле сөлгесенә битен сөртә, әнисенә чәй кайната. Кыскасы, кайсы шигырьдә нинди генә вакыйгалар турында сөйләнмәсен, алар бар да балалар психологиясенә, аларның фикер сөрешенә, кылган гамәлләренә тәңгәл килеп тора. Бу инде әдәби осталык, авторның яшь укучылар белән уртак тел таба белүе дигән сүз. Автор шулай эшләргә кирәк, болай эшләргә ярамый дип әйтми, ә балаларга үз-үзләрен ничек тотарга кирәклекне уйлап бетерергә җирлек калдыра.

Яшел күлдә бакалар
Борчылып сөйләшәләр,
Нәрсәдер киңәшәләр...
Аңладым ич, аңладым:
Бит юарга сабыннары

Юк икән бит аларның. “Иртән”.

Автор баларга тәрбия дәресе бирә, гап-гади көндәлек эшне алар гына түгел, хәтта су буендагы яшел бакалар да башкара дип әйтәсе килә. Әйтик, менә челләдә тирләгән талларга бит сөртергә кулъяулык бирмәкче икән, – авторның мондый шигъри табышларын хупларга гына кала. Яисә герой болытлы тауларны йөк төягән өркәчле дөягә охшата. Хыялның иге-чиге юк бит аның. Балаларның уйлау сәләтен, хыял тирәнлеген нәкъ менә шундыйрак әсәрләр үстерә дә инде.

Шагыйрь талантының көче дә шундадьр инде, бала шигърият арбасына утырып, шигырь дөньясына кереп киткәнен сизми дә кала. Шул кыска ара (бер шигырь арасы) үткәнче, шагыйрь сабыйның күңеленә кешелек тудырган күркәм сыйфатлар орлыгын салырга өлгерә. Сабый күңеле иң бәрәкәтле туфрак, аңа нинди орлык салына, шул тамыр җибәрә, гөрләп үсә башлый. Яхшысы да, начары да.

Чәчәккә үрелүгә,
Сизде бугай уемны:
– Өз-з-з-змә – диеп, бал корты
Чагып алды кулымны.

Артык бер сүз, вәгазь укып азаплану юк. Дидактизмнан кача алу – һәр шагыйрьнең зур хыялы. “Ни эшләп бетәрләр инде”, “Бал суыртучы аю”, “Бүрәнә һәм Бүдәнә” шигырьләрендә дә балаларга уйланырга да, нәтиҗә ясарга да урын калган.

“Авылга кайту” шигырендә шул ук бал кортының малайга уңай мөнәсәбәте тасвирлана. “Җәй уртасы” шигырендә малайның табигатьне яратуы, аңа соклануы ачык күренә:

Болыннар – яшел келәм,
Келәмнән атлап киләм.
Бал тулыдыр йортлары,
Безелди бал кортлары. “Җәй уртасы” [2, б. 13].

Бу балачак җаендә башка бик күп образлар, символлар бар әле. Аларның һәрберсе балачак сурәтенә бер штрих, төс өсти.

Шагыйрь еш кына, балаларга үтә дә таныш берәр күренешне яисә образны кулланып, мөһим һәм кискен проблема да күтәрә. “Танышу” шигырендә нәкъ шундый очрак – автор монда уйнап-шаярып кына тел дәресе биреп куя:

Күрсәтим дигән идем
Русча белгәнемне,
Әтәч тә аңламады:
– Привет, – дигәнемне...
Акбай әйтә:
– Татарча
Исәнләш, ди, – иртәгә! “Танышу”.

Алда әйткәнебезчә, Р. Бәшәр шигърияте тулысынча сурәтлелеккә нигезләнгән. Җете, якты, хыялый төсләрдә сурәтләнгән табигать, авыл, балачак күренешләрендә, әлбәттә, нәни героебызның якыннарына, дус- ишләренә, кыскасы, авыл кешеләренә дә урын җитәрлек.

Шунысын билгеләп үтү мөһим, һәр шигырендә автор дөньяны балаларча матур, әкият шикелле кызык, мавыктыргыч итеп күрергә омтылган. Аларда балаларча беркатлылык та, шул ук вакытта дөньяны үзенчә күрсәтүче форма төрлелеге дә бар.

Авыл җае. Искиткеч матур дөнья. Хыял иле. Бала күңелен җәлеп итәрлек бөтен нәрсә дә бар анда. Бөтен сурәт, төс, аваз бар. Әйе, әйе, искиткеч матур һәм серле авазлар бар. Һәр аваз-яңгырашка тирән мәгънә, хәтта сагаю хисе салынган:

Кычкыра үрдәк:
– Бак, бак!
Шартлады мылтык:
– Бах, бах!
Ыңгырашты күл:

А-ах! А-ах!

Сызланды малай:

И-и-их! “Авазлар” [1, б. 16].

Гүзәллекнең югалуына, гармониялелекнең җимерелүенә никадәр сызлану һәм борчылу. Болай итеп бары тик үзен җир улы, табигать баласы итеп санаган һәм аның бер кисәге итеп тойган кеше генә гүзәллек югалуга шулай борчыла һәм сызлана, шул усаллыкка нәфрәтләнә ала. Юкса, бер караганда бу юлларда сүз авазлар турында гына бара шикелле, чынлыкта исә шул авазларның нигезендә никадәр тирән мәгънә, никадәр олы фикер ята.

Рәшит Бәшәрнең “Сандугачлы ак инеш” шигырендә мондый юллар бар:

Казларың бөтенләйгә

Очып китсә нишләрсең?

Балыкларың диңгезгә

Качып китсә нишләрсең?

Сандугачлар кунарга

Яшел талың калмаса...

Син дә кибеп бетәрсең.

Кешегә үпкәләрсең… “Сандугачлы ак инеш” [3, б. 17].

Ул бу әсәрендә дә экологик проблемаларны күтәрә. “Без сиңа утыртырга куаклар алып килдек”, – ди. Сулыкларның кибүе, агачларның кимүе сурәтләнә. Безгә тырышып, бергәләшеп табигатьне саклап калырга кирәк дигән фикер үткәрелә. “Син, инеш, агарга тиеш”, – ди шагыйрь.

Шулай итеп, шагыйрь, төрле сүз-сурәт алымнары кулланып, шаян сүз уйнату һәм башка поэтик чаралар аша балаларны табигатьнең матурлыгына сокланырга өйрәтә.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Рәшит Бәшәр шигырьләрендә балаларга хас сафлык, самимилек, дөньяга гаҗәпләнеп һәм яратып карау хисләре өстенлек итә. Ул үзенең шигъри әсәрләрендә күбрәк җәнлек, кош-корт кебек образларга мөрәҗәгать итә. Алар балачак темасын ачу символлары булып торалар. Шагыйрь иҗатында кош-корт, хайван, бөҗәк, үсемлек, агач, күк җисемнәре атамаларының күпләп очравын, беренчедән, әдипнең үзе туып-үскән туган як табигатенең киң басулары, иркен тугайлары, нигъмәт-сыйга, кош-кортка бай урманнары белән аңлатырга мөмкин. Икенчедән, барлык шагыйрьләр кебек, ул да табигатькә гашыйк, шунлыктан шигырьләрендә һәр әдип иҗатына хас булган кыр чәчәкләредәй гади, саф рух чагыла.

Ассызыклап әйтергә мөмкин: автор дөньяны балалар күзе белән күреп, аны балаларга аңлаешлы җанлы образлар аша сурәтләүгә ирешкән. Иҗатында гәүдәләндерелгән геройлар табигатькә гашыйк сәяхәтчеләр генә түгел, ә шул сокландыргыч дәрьяга хуҗаларча караучылар, табигать яраларын үз яралары итеп кабул итүчеләр буларак күз алдына килә.

Гомумән, шагыйрь балаларда табигатькә карата мәхәббәт тәрбияләүгә, экологик проблемаларны хәл итүгә үгет-нәсихәт аша түгел, геройның үз уйланулары һәм аның яшеллек дөньясына үз мөнәсәбәте аша якын килергә омтыла.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Бәшәр Р. Ак әкият: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 32 б.
2. Бәшәр Р. Сандугачлы бишек: Шигырьләр, кыйссалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 176 б.
3. Бәшәр Р. Җиләк малай: шигырьләр. – Чаллы: Газета-журнал нәшр., 2002. – 80 б.
4. Курбатов Х. Сүз сәнгате: татар теленең лингвистик стилисикасы һәм поэтикасы.. – Казан: Мәгариф., 2002, 199 б.
5. Сөләйманова С. Табигать кочагында // Мәйдан. – 2002. – № 4. – Б. 196-197.

СТУДЕНТЛАРГА ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ БИРҮ (ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВНЫҢ “КИТЕК АЙ” ӘСӘРЕ МИСАЛЫНДА)

Фәсхетдинова Р.З.*, *Динмухамедова Р.К.

Кама дәүләт автомеханика техникумы, Яр Чаллы шәһәре, Россия

НРАВСТВЕННОЕ ВОСПИТАНИЕ СТУДЕНТОВ (НА ПРИМЕРЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ Г.Х. ГИЛЬМАНОВА “РАСКОЛОТАЯ ЛУНА”)

Фасхутдинова Р.З., Динмухамедова Р.К.

Камский государственный автомеханический техникум, г. Набережные Челны, Россия

Выявлены некоторые художественно-изобразительные средства, использованные в художественном мире татарского прозаика Г.Х. Гильманова. Освещены особенности функционирования этих средств как идиостилевых черт автора. Исследованы основные герои, изображенные в произведении «Расколотая луна». Все это подтверждается текстовым материалом. Определена их идейно-эстетическая роль в нравственном воспитании студентов.

Ключевые слова: *художественно-изобразительные средства, художественный герой, нравственное воспитание.*

MORAL EDUCATION OF STUDENTS (FOR EXAMPLE, WORKS G.H. GILMANOVA «SPLIT THE MOON»)

Fashutdinova R.Z., Dinmuhamedova R.K.

Kamsky State automechanical College, Naberezhnye Chelny, Russia

Identified some artistic and visual tools used in the art world of the Tatar writer G.H. Gilmanov. Highlights the peculiarities of these funds as hell idiostilevyh author. The basic characters shown in the product "Broken Moon". All this is confirmed by text material. Determine their ideological and aesthetic role in the moral education of students.

Keywords: *art-graphic arts, artistic character, moral education.*

Матур әдәбият ул – тормыш көзгесе һәм аның төп сурәтләү предметы – кеше. Шуңа күрә һәр әдип, ул кайчан гына яшәп, нинди генә әсәр иҗат итсә дә, үз алдына төп максат итеп кеше проблемасын яктыртуны куя: аның эш-гамәлен, эчке дөньясын, кешеләр белән мөнәсәбәтен һәм, ниһаять, аның бәхетен сурәтли.

Гомумтөрки әдәбият вәкиле булган И. Баласагунлыдан башлап бүгенге көн язучы-әдипләренә кадәр кеше бәхете мәсьәләсен күтәрәләр, әхлаклы, кешелекле мөнәсәбәтләр генә бәхетле тормышка нигез салалар дигән фикергә киләләр.

Билгеле булганча әхлак – кешенең шәхес буларак ачылуына китергән аралашуның төп факторы. Техниумда студентларга әхлак тәрбиясе бирү хәзерге чорда әхлак идеялы, кызыксынуы яшәешенең максатына туры килгән студентларның үз-үзләрен тотышын формалаштыруга юнәлдерелгән. Ул һәр шәхеснең үз-үзен тотышын җәмгыять мәнфәгатьләре белән килештерүне, җәмгыятьнең әхлаклы идеал принциплары, таләпләре белән таныштыруны; әхлакый белемнәрнең инануларга әверелүен; тотрыклы уңай сыйфатлар, хисләр формалаштыруны күздә тота.

Гәрчә әхлакый кыйммәтләр вакытлар үтү белән үзгәрә барса да, әдәбият үзенең төп вазифасын – халыкларны тәрбияләүне үти тора. Моңа дәлил булып гасырның 80 нче

елларында әдәбият хәрәкәтенә кергән Галимҗан Гыйльманов әсәрләрен атарга кирәк. Г.Х. Гыйльманов – әдәбиятта үзен танытып өлгергән өлкән язучы. 1972 нче елларда матбугатта күренә башлап, ике дистә елдан артык вакыт татар әдәбиятын үзенең әсәрләре белән тулыландырып бара. Язучы повесть-хикәяләрендә әледән-әле әхлак кануннары турында фикерләре белән уртаклаша килә. Гаилә кору, мәхәббәт, кешелеклелек, кеше бәхете проблемаларын күтәрә килә.

Кеше өчен иң затлы, бөек хис-яратуның серен әле тулысынча аңлата алучы булганы юк. Без "мәхәббәтнең кешене кеше иткән нәрсә" булуына, аннан башка чын мәгънәсендә кешелеклелек, игелеклелек, күңел нечкәлекләренә ия, башкаларны хөрмәт итүче, назлы шәхес була алмый икәненә әдәби әсәрләр укып, үз тәҗрибәбездән чыгып та әледән-әле ышанабыз. Ә менә Г.Х. Гыйльмановның "Китек ай" әсәренең төп герое Гөлнарага килгән мәхәббәт чын мәхәббәт була аламы? Күз карасы кебек карап үстергән әти-әнисен рәнҗетүе, мәхәббәт җимеше булган баланы ташлап китүенә алда әйтеп үтелгән олы хис сәбәп буламы? Әсәрне укыганнан соң менә шушындый сораулар туа.

Сөясе, сөеләсе килү – гадәти хәл. Ләкин элек-электән килгән әхлак нормаларын саклаган хәлдә дә яратып була бит. Дөрес, заманалар үзгәрү, төрле халыклар белән аралашу әхлак критерийларына сизелерлек тәэсир итте. 70-80 нче еллар вәкиле буларак автор үз геройлары авызыннан түбәндәге сүзләрне әйтә: "Әмирҗан да, Фәйрүзә дә сөю-мәхәббәткә каршы түгел анысы. Сөйсен, бәхетле булсын. Тик... Болай түгел бит инде. Кайдадыр төн кунып, шәраб чөмереп йөреп, мәхәббәтнең сафлыгына, игелегенә ирешеп булмыйдыр ул" [2, б. 216]. Мәхәббәт төшенчәсенә дә яңа сыйфатлар өстәлә тора. 70-80 нче еллардагы "саф мәхәббәт" башкачарак төсмерләр ала. Чыннан да шул "адашкан мәхәббәте" аркасында Гөлнара әниләрен рәнҗетә. Ул аларны ташлап китә, борчу-кайгы алып килә – елга якын үзенең исәнлеге турында хәбәр дә бирми. Шуның өстенә карынындагы баласын төшереп, ташлап китә. Дөрес, ул моны эшләргә мәҗбүр була. "Гомерен бирерлек дәрәҗәдә" җаны-тәне белән ярата, авырга уза. Бала буласын белгән егете якын килмәс була. "Баланңы ташласаң, кабат кайтам, дигәч, сабыен төшереп, читкә чыгып китә..." Ә яратам дип йөргән егете барыбер ташлап китә. Менә шул чагында гына, миңа калса, Гөлнара үзен сукырайткан, исерткән мәхәббәттән айнып, зур гөнаһлар кылганын аңлый башлый. Аның мондый юлга басуында кем гаепле соң? Әти-әнисеме, Гөлнарада саф хис уята алган яшь кешеме, әллә үземе?

Әти-әнисенә килгәндә, алар бердәнбер газиз кызларын – йөрәк парәләрен – бик нык иркәләп, кирәгеннән артык назлап үстерәләр. Кыз бернинди мохтаҗлык күрмичә үсә. Әмма әти-әнинең сукыр мәхәббәте нәтиҗәсендә һәрнәрсә ул дигәнчә булганга күнеккән Гөлнара ахыр чиктә ялгыш юлга баса. Егетне үз янында тоту өчен, баласын ташлап калдыра. Артык иркә булып үскән кешеләр өчен эгоистлык хас булучан. Менә шушы хакыйкатьне, безнең фикеребезчә, Гөлнараның әти-әнисе бала тәрбияләгәндә искә алмыйлар.

Ә бит югыйсә Әмирҗан белән Фәйрүзәнең теләкләре изге була: алар балага бары бәхет теләп кенә шулай эшлиләр.

Бу бәхетсезлектә автор егетне генә гаепләргә теләми, чөнки ул аның исемен дә атамый. Ләкин бу образ аркылы автор хәзерге вакытта гаилә корып, бала үстерү кебек җаваплылыкны үз өсләренә алырга теләмәүче, типик "ирекле мәхәббәт" вәкилен сурәтли. Ә мәхәббәт алдауны, хыянәтне кабул итә алмый. Аның юлдашы – сафлык, тугрылык, намуслык. "Ирекле мәхәббәт" – кешенең татлы кичерешләреннән, аның мөкатдәс омтылышларыннан көлү ул. Егетнең исеме булмау гомеренең күпчелек вакытын кәеф-сафа корып, җаваплылыктан качып йөрүче затларның күбәеп китүен күрсәтә. Әйе, егет тискәре сыйфатларга ия кеше буларак сурәтләнә. Ләкин Гөлнараның "кыйбласы ялгышуында" үзенең дә гаебе бар. Халкыбызга хас булган изге гореф-гадәтләренең билгеле бер чикләрен атлап чыгу, ахырын уйламыйча эш кылу егет белән кызны уңайсыз хәлгә куя, кызның гөнаһ юлына басуына китерә. Гадәттә җиңел холыклы кызларга егетләр дә җиңел карый торган була: мондый юлга тиз төшкән кызга карата күпмедер вакыттан соң гайрәтләре дә чигә. Егет соң булса да кызның җитди икәнен күргән, чынлап яратуын

аңлаган. Аңа карата күңелендә ярату хисе дә булган дип уйларга кирәк, шул сәбәпле ул Гөлнарага ир, балага ата булырга ниятләгән. Моннан безнең киләчәгебез гел үк өметсез түгел дигән нәтиҗәгә киләбез. Игелек, мәрхәмәт, мәхәббәт кебек изге хисләрнең әле яшьләр күңелендә сүнеп бетмәгән икәненә төшенәбез. Бу хисләрнең яшьләр күңел түреннән ургып чыгуы өчен шартлар тудыру – өлкәннәрнең, якыннарының бурычы. Шул чагында гына халкыбызның бәхетле киләчәге өметле.

Гөлнара образын ачуда автор китек ай символын куллана. “Китек ай – китек иман дигән сүз. Китек күңел, китек язмыш дисәң дә ярый” [2, б. 218]. Чыннан да, әсәрдә сурәтләнгән хәл Гөлнара күңеленнән гомере буе китмәс, күңелсез уйларга китерер. Әледән-әле тыңгысызлап торыр, гәрчә вакытлар үтү белән бу яра төзәлә барса да. Әсәрдә бирелгән бу символик образга тагын бер мәгънә салынган, безнеңчә. Бердәнбер балаларына тәрбия бирүдә Әмирҗан белән Фәйрүзә китеклек калдырганнар. Тормышны аңлау, ир-егетләр белән үз-үзеңне тоту, алар белән якын мөнәсәбәтләр нәрсәгә китерүе турында җитди сөйләшү булмаган, олы юлга басканда, киңәшче була алмаганнар, күрәсең. “Көне-төне заводта булдылар, икешәр смена эшләп, кооперативка акча җыйдылар, шуңа күрә дә вакытлары аз булды” [2, б. 227].

Китек ай образы повестьның башыннан ахырына кадәр вакыйгалар барышында искә алынып, әсәргә ниндидер серлелек, шомлылык өсти. Әсәр укуны мавыктыргыч итә. Ул әсәргә табылдык бала белән килеп керә. Бала тапкан Әмирҗан белән Фәйрүзәне шомга сала ул. Үзе “Көмеш ай!.. Мөселман ае...”. Көмеш булуы ниндидер кыйммәтле, кадерле нәрсә белән бәйле икәнен күрсәтеп торса, мөселман ае булуы татар халкының элек-электән сайлап алган, саклаган һәм югары күтәреп мактаган намуслылык, сафлык, гаделлек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар, матур гореф-гадәтләр билгесе булып тора. Милләтебез нинди генә сынаулар үтсә дә, аларны саклап кала алган. Фәйрүзә, Әмирҗан, Гөлнара бу асыл сыйфатларны саклый алганмы соң?

Бер генә әни булган кеше дә баласына начарлык, авырлык теләми. Һәр ана баласы турында бары тик яхшы сүзләр ишетергә тели, начар юлга басар дип һич башына китерми. Гөлнараның әти-әнисе дә шулай бала ташлаучы хатын аларның кызы дип уйлап та карамыйлар. “Кем үстерде икән ул хатынны? Кем бишектә бакты микән? Шул ата-ананың да күзләренә карар идем. Йөзләренә төкерер идем…” [2, б. 227], – дип әйтә Фәйрүзә шушындый кешелексезлек кылган бәндә турында. Ә күңеле нәрсәдер сизә, шуңа ул китек айны сандыкка салып яшереп куя.

Күңеленә тынычлык бирми бу ай Фәйрүзәнең, ул алда ире белән балаларын күңелсез хәл көтүен сизә.

Фәйрүзә дә, Әмирҗан да повестьта миһербанлы, шәфкатьле кеше итеп сурәтләнәләр. Яфрак өеме астыннан тапкан баланы өйләренә алып кайтып тәрбиялиләр. “Үлеп баручы бәгырь кисәген бу якты дөнья өчен ничек тә саклап калырга тырышалар” [2, б. 219]. Балалар йортына урнаштыргач та, көн саен аның янына баралар. Бу бала аларда “якты, матур, хәтта игелекле, изге хис” тудыра. Алар балада ниндидер нур, ниндидер өмет күрәләр. Баланы балалар йортына алып киткәч, Фәйрүзә: “...үз балабызны алып чыгып киткән кебек булды… Нидер бар бу балада… Бездән нидер бар… Безнең бала кебек ул, безнең онык кебек” [2, б. 225], – ди. Монда Г. Гыйльмановның кешенең кичерешләрен оста итеп сурәтләве – психологик портрет остасы булуы күренә. Ана күңеленең сизгерлеге, сафлыгы баласына булган мәхәббәт хисләре бар нечкәлеге белән күңелләрне тетрәндерерлек итеп бирелгән.

Бала табу күренешенә кире кайтсак, автор дини-мифологик ышануларга барып тоташа торган “җан” образын сурәтли. “Мә-ә-ә…” дигән тавышны ишеткәч, Фәйрүзә: “әллә… шул тавыш үзе җанмы? Берәрсенең ятим, үксез җанымы? Кайчакларда кара кайгыга очраган, ачы рәнҗешкә тап булган җан шулай чыгып китүчән була икән, дөнья бетереп, үзенә тынычлык, иминлек эзләп йөри, имеш…” [2, б. 218], дип уйлый. Фәйрүзә шушы бала елавында кызы Гөлнараның “җан тавышын” ишетә кебек. Шул рәвешле, язучы әни белән бала арасында була торган бәйләнешнең никадәр ныклы булуын вакыйгалар барышында кат-кат күрсәтә килә.

Хатын-кыз буларак хисләргә бирелүчән Фәйрүзә бала ташлап китүчене гаепләү ягында булса, ә аек акыл йөртүче Әмирҗан мондый юлга басуның сәбәбе булырга мөмкинлекне истә тотып болай ди: “Кызмале, карчык… Алай ук чәнчемә! Кем белән нәрсә булмасын? Әллә дөнья китереп кыскандыр ул ана затын? Бәлки, юлын, кыйбласын ялгышкандыр? Алдашкандыр?.. Миһербанлы, игелекле булыйк. Баласын ташлаган анага хәзер бик кирәктер ул игелек, шәфкать дигәннәре…” [2, б. 218].

Әйе, шәфкать барчабызга да кирәк. Беркем дә үз аеның китек булуын теләми. Гөлнарага килсәк, анда татар хатын-кызына хас balaҗанлылык, җаваплылык, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар бөтенләй үк әле бетмәгән. Соң булса да ялгышлык эшләгәнен аңлый. Әти-әнисенә язган хатында болай ди: “Мин сезнең каршыгызда нык гаепле. Мин Ходай Тәгалә каршында да зур гөнаһлы. Ул гөнаһны гомерем буе юып бетерә алмасымны да беләм. Әмма сезнең мәрхәмәтегез, мәхәббәтегез аны бераз җиңеләйтер кебек” [2, б. 219]. Әниләре янына кайткач, кайгы-хәсрәтләр алып килгән өчен гафу үтенә, ә балага кайгыртучан, назлы әнигә әверелә.

Әмирҗан белән Фәйрүзәнең эчке дөньясын, кичерешләрен тулырак, тирәнрәк җиткерү өчен Г.Х. Гыйльманов табигать кичерешләрен сурәтли. “Күктәге айның китек очы һаман ачылмады. Киресенчә, төн караңгылыгы аның имгәнгән очын тагын да ныграк кимерә башлады. Ямьсез уйлар, әнә шул караңгы төн кебек, Әмирҗан белән Фәйрүзәнең күңелен дә усалланып, үҗәтләнеп кимерергә керештеләр” [2, б. 218]. Бу юллар кызларының ташлап чыгып китүе, аларны үзенең бәхетен таба алмавында гаепләве нәтиҗәсендә ата-ана күңелендә туган борчу-сагыш, үкенеч хисләренең тирәнлеген күрсәтәләр. Бала хәсрәте ата белән ана өчен зур кайгы булуы, алар өчен бөтен дөнья хәсрәттә булып тоелуын табигать күренешендәге үзгәрешләр аша язучы оста итеп бирә.

Шулай итеп, Г.Х. Гыйльмановның “Китек ай” әсәрендә кулланылган төрле сурәтләү чараларын өйрәнеп, андагы үзенчәлекле образларны анализлау аша балаларда шәфкатьлелек, җаваплылык, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар тәрбияләү аларның әхлакый белемнәрен инануларга әвереддерер; тотрыклы уңай сыйфатлар, хисләр формалаштырыр дип уйлыйбыз. Авторның киләчәктә җәмгыятьнең чистаруына, кешелекнең яхшы якка үзгәрүенә юнәлдерелгән өмете чынга ашар дигән теләктә калабыз.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Заһидуллина Д. Яңа дулкында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 141 б.

2. Гыйльманов Г.Х. Китек ай: Повестьлар, хикәяләр, парчалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 384 б.

3. Шәсмутова Г. Галимҗан Гыйльман иҗаты // Мәйдан, 2007. – № 4. – Б. 140-143.

4. Фәхретдинов Р.Р. Нәсыйхәт. Әхлак гыйлеменнән. – Казан: Мәгариф, 2005. – 184 б.

РОЛЬ УЧИТЕЛЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ В ВОСПИТАНИИ ШКОЛЬНИКОВ

Хуснуллина А.М.

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Средняя общеобразовательная школа №45», г. Набережные Челны, Россия

В данной статье исследована проблема формирования воспитательной деятельности учителя татарского языка и литературы. Освещены основные функции воспитательной деятельности учителя татарского языка и литературы. Выявлены основные критерии эффективности воспитательной деятельности.

Ключевые слова: *учитель татарского языка и литературы, воспитательная деятельность.*

THE ROLE OF THE TEACHER OF THE TATAR LANGUAGE AND LITERATURE IN THE EDUCATION OF PUPILS

Khusnullina A.M.

Municipal budget educational institution "Secondary school №45", Naberezhnye Chelny, Russia

This article studies the problem of formation of educational activity of the teacher of the Tatar language and literature. The main features of educational activity of the teacher of the Tatar language and literature. Identified the main criteria of the effectiveness of educational activities.

Keywords: *the teacher of the Tatar language and literature, educational activities.*

В настоящее время в Республике Татарстан идет новый этап развития и совершенствования национального образования. Он потребовал современного теоретического осмысления и целостного подхода, т.к. эти процессы протекают в условиях перехода от концепции единой унитарной школы к формированию системы национального образования. Наша новая школа – это школа, обеспечивающая право обучения и воспитания детей на родном языке, передачу молодому поколению многовекового опыта народа, его нравственных устоев, трансляцию национальной культуры, формирование национального самосознания.

В условиях новой школы возникла настоятельная необходимость пересмотра воспитательной деятельности и задач учителей татарского языка и литературы. Поэтому в новых учебных планах национальных школ родной язык и литература обрели достойное место, достаточное для более содержательного и полноценного изучения.

Татарская литература – хранительница национального генофонда, традиций, обычаев, нравов народа. Исходя из этого, в программах и учебниках по татарской литературе нашли должное отражение те произведения, в которых ярко освещаются важнейшие проблемы, связанные с историей развития общества, человечества и т.д. В учебниках по татарской литературе, составленных для различных типов учебных заведений, с учетом возрастных особенностей и образовательного уровня учащихся, включены самые лучшие художественные произведения древнетатарской, классической, современной литературы, в которых широко отражается национальный дух, прогрессивные национальные традиции, нравы и обычаи, эстетические воззрения татарского народа и братских народов Поволжско-Приуральского и других регионов. У нашей национальной школы есть очень заинтересованные друзья – учителя родного языка и литературы. Все эти годы они настойчиво совершенствовали содержание и структуру уроков татарского языка и литературы, активно искали и ищут новые приемы, методы, обеспечивающие не только прочное усвоение знаний, но и духовное и культурное обогащение учащихся. Творчески работающие учителя умело используют художественные произведения, фольклор, народное искусство для воспитания у детей чувств подлинной любви к своей земле и своему народу.

Процесс обновления содержания национального образования повлек за собой не только коренное изменение учебных планов, методов и технологий обучения, но потребовал создания школ нового типа, новых учебных программ, учебников, методических пособий, в первую очередь, по предметам, составляющим национально-региональный компонент образования.

В ходе выполнения Закона о языках Республики Татарстан и Государственной программы развития национального образования осуществлено создание оригинальных учебников по татарскому языку и литературе. Уже с 1992 года начали разрабатываться и издаваться три комплекта новых программ и учебников: для татарских школ, для учащихся-татар в школе с русским языком обучения, для русскоязычных учащихся.

Воспитательная деятельность учителя татарской литературы осуществляется не только через совместные мероприятия, общие дела, а в первую очередь через рефлексивную деятельность детей, через размышления и обсуждение с другими и т. д. Вся система занятия, их содержание, методы проведения направлены на развитие самосознания учащихся. Именно эта направленность определяет атмосферу, стиль и тон жизни классного коллектива не только во время уроках, но и вне их: на уроках, переменах, внеурочных встречах детей. Таким образом, происходит не только личностное развитие каждого, но и сплочение и совершенствование класса как значимой социально-психологической группы.

Важно, чтобы именно в школьном возрасте произошло глубокое, окрашенное чувством усвоение понятий, которые лягут в основу представлений ребенка о сущности людей, об ответственности каждого перед самим собой и окружающими. Тогда можно надеяться, что в более старшем возрасте дети смогут отстоять и утвердить эти ценности в своей деятельности.

Организация воспитания учителем татарского языка и литературы являются реальным воплощением следующих смыслообразующих идей:

– наиболее продуктивные и достойные человека способы взаимодействия людей друг с другом – сотрудничество, компромисс, взаимные уступки, что невозможно без умения общаться, договариваться, преодолевать себя;

– дружным класс может стать, если дети заняты общей, увлекательной для них деятельностью, если в классе доброжелательная атмосфера, если каждый стремится понять себя и другого и в то же время умеет принимать достойное индивидуальное решение и следовать ему;

– достойное решение – это самостоятельный ответственный выбор, осуществляемый конкретной личностью, исходя из ее индивидуальных интересов и возможностей и из интересов и возможностей окружающих;

– осуществление самостоятельного выбора требует от человека определенной личностной зрелости. Оно невозможно без осмысленной инициативы и определенной компетентности;

– умение быть самостоятельным – это целостное проявление человека. В нем проявляется индивидуальность, отражается прошлое, проецируется будущее школьника.

Принятие этой идеологии и признание этих идей определяют содержание, логику всей работы учителя татарского языка и литературы, структуру каждого занятия, предпочтительные формы и методы их проведения – реализуют антропологический подход к воспитанию школьников.

Миргалимова З.Ф.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты,
Яр Чаллы шәһәре, Россия

АРАБСКАЯ КАЛЛИГРАФИЯ И ИСКУССТВО ШАМАИЛЯ У ТАТАР

Миргалимова З.Ф.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Данная статья посвящена изучению арабской каллиграфии и искусства шамаиля у татар.

***Ключевые слова**: арабская каллиграфия, искусство шамаиля, мастера шамаиля.*

ARABIC CALLIGRAPHY AND ART SHAMAIL TATARS

Mirgalimova Z.F.

Naberezhnochelninsky Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

This article is devoted to the study of Arabic calligraphy and art shamail Tatars.
***Keywords**: Arabic calligraphy, art shamail, master shamail.*


Татар халкы тарихын гарәп язуыннан башка күз алдына китереп булмый. Мең елдан артык гамәлдә булган гарәп язуы нигезендә бик күп әдәби, фәнни һәм сәнгать әсәрләре иҗат ителгән. Шулар арасында каллиграфия җәүһәрләре аерым бер урын биләп тора.

Каллиграфия (грек. kalligrapha – красивый почерк) – искусство чистописания [4, б. 213]. Каллиграфия – матур язу сәнгате, сынлы сәнгатьнең бер төре. Бу эш белән шөгыльләнүче *каллиграф* яки *хаттат* дип атала.

Каллиграфия – ул, беренче чиратта, китап. Элекке заманда кульязма китаплар гамәлдә булган. Каллиграф-хаттатлар аларны күчереп тараткан. Мөселман сынлы сәнгатен өйрәнүче А.Х. Шәйхлисламов фикеренчә, китапның каллиграфик кульязмасы барлыкка килүе, аның иллюминациясе казан татарлары өчен аллегорик мәгънәгә, бай символикага ия булган. Казан татарларында китап материаль байлык булып саналган. Урта гасыр җитәкчеләре, кыйммәтле кульязмалар булдыру өчен, махсус остаханәләр тотканнар. Китапны тудыру процессында төп рольне каллиграф башкарган. Каллиграф булу өчен, оста булу гына җитмәгән, ә белемле һәм әхлакый сыйфатларга ия булу да таләп ителгән. Каллиграфтан соң китапны миниатюрист һәм орнаменталист бизәгән. Китапның соңгы битендә хаттатның исеме, кульязманың язылу урыны һәм вакыты күрсәтелгән [5, б. 17].

Сәнгатьле бизәү элементы буларак каллиграфик язу мөселман сәнгатенең мөһим бер билгесе булып тора. Шәмаилләр, каллиграфик почерк белән эшкәртелгән елъязмалар, патша указлары, миниатюралар – милли язу хәзинәсенең бер өлеше генә. Гарәп язуы үзеннән-үзе орнаменталь, хәрефләрне төрле вариацияләрдә язу мөмкинлеге чиксез, шуңа күрә сәнгать осталары һәрвакыт яңа, оригиналь чишелеш эзләгән. Ә бу үз чиратында язу стильләренең күбәюенә китергән. Хәзерге көндә гарәп язуының 36 каллиграф язу стиле бар дип санала [5, б. 15]. Мәсәлән, 10-13 гасырларда гарәп хаттатлары түбәндәге классик язу төрләрен уйлап тапкан: нәсх, сөлс, мөхаккак, рәйхани, тәукигъ, рикагъ.

Гарәп каллиграфиясе үрнәкләре: куфи, нәсх, рикагъ, нәстәгъликъ, сөлс, дивани:



Гарәп каллиграфия сәнгатенең алга таба үсеше Казанда милли типографияләр барлыкка килү белән бәйле. Беренче типография Казанда 1880 нче елда барлыкка килә. Беренче милли типографияләр ачылгач, татар китапларын бастыру киң колач ала. Татар

китапларын бастыру белән беррәттән шәмаилләр бастыру да үсеш ала, чөнки бу чорда Урта Идел һәм Урал буенда яшәүче татарлар арасында шәмаилләр бик популяр була.

Шәмаил гарәп теленнән кергән сүз. Сүзлектә ике мәгънәсе китерелгән: 1. Тумыштан килгән сыйфат, холык, яхшы холык. 2. Рам эченә куелган дини эчтәлекле текст яисә изге урыннарның рәсеме [1, б. 134]. Шәмаил – безнең дини культурабыз белән бәйләнгән сынлы сәнгать әсәре.

Шәмаил сәнгатен тирәнтен өйрәнгән Рөстәм Шәмсутов: "Шамаиль в культуре татар-суннитов Среднего Поволжья и Приуралья религиозный знак, основанный на искусстве арабской каллиграфии, оформленный в виде станковой картины. Арабографический текст, в основном религиозного содержания или изображения культовых сооружений, представленные в шамаилях, могут быть выполнены различными материалами – тушью или печатным способом на бумаге, в виде вышивки на ткани, масляными красками на стекле или холсте" – дип яза [6, б. 9].

Гадәттә шәмаилләр Коръән сүрәләреннән алынган өзекләрдән, Мөхәммәт пәйгамбәребезнең хәдисләреннән, урта гасыр шагыйрьләренең хикмәтле сүзләреннән һ.б. тора. Аларның эчтәлегендә үз-үзеңне яхшы тоту, әдәп-әхлак кагыйдәләре урын алган. Шәмаил – Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен җиткерү ысулы. Аны юкка гына түр башына элмәгәннәр.

Матур язу осталары – хаттатлар – XIX гасыр ахырына кадәр кульязма формасында, XIX-XX гасыр чикләрендә басма формада татар рәсем сәнгатендә кабатланмас шәмаил үрнәкләре тудырганнар. XIX-XX гасыр чикләрендә Госман Сәлиев, Мотаһир Яхъя, Мораддым ибн Ибраһим, Мөхәммәдҗан Хәлил улы Хуҗасаитов, бертуган Әхмәтовлар кебек танылган каллиграфлар плеядасы барлыкка килә. Әмма совет чорында, гарәп имлясыннан баш тарткач һәм динне тыюлар башлангач, шәмаил сәнгате дә сүрелә.

Совет чорында шәмаилләр иҗат итү белән Бакый Урманче шөгыльләнә. Рәссам шәмаил стилендә тугыз әсәр иҗат итә. Ш. Монасыйпов фикеренчә, тик аларның бары өчесен генә чын шәмаил дип санап була, чөнки алар гына Коръән Кәрим вә хәдисләрнең изге текстларына багышланган. Калган әсәрләрендә изге теләкләр түгел, ә рәссамның яраткан шагыйрьләре Тукай, Кол Гали һ.б. әсәрләреннән алынган канатлы сүзләр, шулай ук Шәрыкнең хикмәтле гыйбарәләреннән үрнәкләр гади каллиграфия ысулында эшләнгәннәр [3, б. 38-39].

Куанычка, гасырлар буена җыелып, буыннан-буынга тапшырылып килгән рухи-мәдәни традицияләребез XX гасыр азагында халкыбызга әйләнеп кайта. Бакый Урманче борынгы осталардан өзмичә алып килгән бу эстафетаны Рамил Насыйбуллов, Рәиф Мәрдәнов, Нәҗип Нәккаш, Владимир Попов, Фирдәвес Гыйрфанов, Ришат Сәлахетдинов, Салават Гыйләҗетдинов кебек сәнгать осталары дәвам итә. "Шунысы игътибарга лаек, бу изге эшкә соңгы елларда Әлфия Хәлиуллина, Гөлгенә Вәлиуллиналар да килеп кушылдылар", – дип яза Н. Нәккаш [2, б. 40]. Алга таба шулар арасыннан берничә кылкаләм остасының иҗатына тукталып үтәбез.

Каллиграфия өлкәсендәге хезмәтләре белән танылган мастерларның берсе – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында гыйльми хезмәткәр вазыйфасын башкаручы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Нәҗип Фәйзрахман улы Исмәгыйлев (Нәккаш). Ул иҗат иткән шәмаилләр, тугралар, гарәп графикасы нигезендә Мөхәммәд пәйгамбәребезнең хәдисләре, урта гасыр шагыйрьләренең хикмәтле сүзләре язылган Коръән аятьләре мәчетләрдә генә түгел, дөньяның байтак музейларында да куелган. Үзенең иҗаты турында Нәҗип Нәккаш түбәндәге фикерләрне әйтә: "Мин 400дән артык шәмаил эшләдем. Әйтик, иң яраткан шәмаилемдә Коръәннән 3 нче аять, Җиңү сүрәсе язылган: "Без Аллаһ сиңа ап-ачык җиңү бүләк иттек". Мин гарәпнең "Мән җәддә-вәҗәдә" әйтемен дә бик яратам. Ул, безнеңчәгә тәрҗемә итсәң "Кем тырыша – шул тормышка ашыра" дигән сүз. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның да байтак юлларын шәмаилгә күчереп эшләдем. Соңгы елларда халкыбыз тормышындагы олы даталар, әһәмиятле вакыйгалар да шәмаилгә күчте. "Сөембикә манарасына ай кую", "Хәтер көне",

“Болгарстанның Ислам динен кабул итүе”, “Белем бәйрәме”, “Колшәриф мәчетен торгызу” әнә шундыйлардан”.

Владимир Попов – дөньякүләм күренекле каллиграф, бик тә үзенчәлекле, оригиналь шәмаил һәм тугралар авторы, ислам сәнгатендә иҗат итүче Татарстанда беренче һәм бердәнбер рус рәссамы. Аның хезмәтләре Татарстан музейлары фондларын гына түгел, ә дөньяның башка ил коллекционерлар тупланмаларын бизәп тора. Ислам тематикасына ул олыгаеп килә һәм аз гына вакыт эчендә бу өлкәдә үзен профессиональ буларак таныта. Каллиграфияле композиция шәкелләре өчен 2014 елда Владимир Поповка Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. “Заманча ислам рәсем сәнгате гореф-гадәтләрендә, жанрында һәм ислам каллиграфия эстетикасында иҗат итүче Татарстанда беренче һәм бердәнбер рәссам. Ул иҗат иткән образлар ачык һәм шундук җәлеп итүчән, эпик формасы ягыннан мәһабәт, соклангыч, хиссилек ягыннан тирән, алар үткән һәм бүгенге мәдәниятне бик табигый төстә берләштерәләр”, – ди аның иҗаты турында сәнгать белгече Розалина Шаһиева.

Каллиграфия остасы Рамил Насыйбуллов – Татарстанның хәзерге заман каллиграфлары арасында диплом-иҗаза алган – хаттатлык осталыгына ия булуның рәсми дәлилләмәсенә һәм шушы сәнгатькә башкаларны өйрәтү хокукына ия булган бердәнбер иҗатчы. Истанбулда укыган вакытында ул 14 төрле язу ысулын һәм шәркый китап бизәү алымын үзләштерә, мисалга, тәзхиб (алтынлау) сәнгатен, эбру (кәгазьне “мәрмәрләндерү”) һ.б. Ул Казанда яшәп иҗат итә. Хаттат иҗади хезмәтен укыту белән бергә уңышлы гына алып бара: Россия Ислам университетында аның җитәкчелегендә республикада бердәнбер булган Гарәп каллиграфиясе үзәге эшләп килә.

Рамил Насыйбуллов иҗаты классик каллиграфиядән гыйбарәт: каләменең һәрбер хәрәкәте төгәл математик исәпләүләр аша тикшерелгән, бу исә рәссамның һөнәри әзерлеген раслаучы мөһим күрсәткеч булып тора. Аның бөтен әсәрләре, гарәп каллиграфиясе сәнгате классик кануннарына туры китереп, форма төгәллеге һәм шрифт матурлыгы, тәэсирлеге белән аерыла. Шул рәвешле, Рамил Равил улы Насыйбуллов иҗаты хәзерге заман татар каллиграфиясен яңа, һөнәри югарылыкка чыгара.

Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче Фирдәвес Гыйрфанов – татар шәмаилләрен пыялага ясау сәнгате традицияләрен дәвам итүче һәм үстерүче һәм бу өлкәдә әйдәп баручы мастерларның берсе. Рәссам пыялага ясау техникасын шактый баета. Аның әсәрләре турында Р. Шамсутовның фикерләре: “Работы Ф. Гирфанова ... отличаются обилием деталей, гармонирующих с информативной насыщенностью, ярким световым решением. Основополагающим элементом в картинах остается текст религиозного содержания, грамотное исполнение которого в сочетании с символикой образного языка демонстрирует высокие профессиональные знания художника. Ф. Гирфанов является одним из немногих художников, активно передающих свой опыт и знания подрастающему поколению” [6, б. 182].

Шулай итеп, кешеләрнең язуда иҗади үзенчәлекләрен чагылдыруга омтылышы гаҗәеп бизәкләр рәвешенә кертеп язылган гарәп графикасы үрнәкләрен барлыкка китергән. Мөселман татарларында саклау вазифасын башкаручы хәзерге заман шәмаилләрнең текстлары эчтәлекләренең күпкырлылыгы белән аерылып тора. Дини эчтәлекле булмаган гарәп графикасындагы текстлар киң таралыш ала. Гарәп графикасы һәм кириллица янәшә кулланылган шәмаилләрне дә очратырга мөмкин. Шуның белән бергә шәмаил терминының эчтәлеге дә үзгәрә.

Ни генә булса да, халык сәнгате үрнәкләренең эстетик кыйммәте, кадере еллар үткән саен ныграк арта гына бара. Алар бүген дә күпчелек татар гаиләләренең өйләрен бизәп тора.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Зәйнуллин Ж.Г. Шәрык алынмалары сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 1994. – 143 б.

2. Нәккаш Н. Хаттат кызлар // Идел. – 1990. – №7. – С.40.

3. Монасыйпов Ш. Бакый Урманче шәмаилләре // Духовный мир Баки Урманче. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – С.34-58.

4. Универсальный словарь иностранных слов русского языка. – М.: Вече, 2001. – 688 с.
5. Шайхлисламов А.Х. Роль мусульманского и декоративно-прикладного искусства в становлении и развтитии художественного образования татарского народа в Казанском крае (VIII-XV вв.) // Казанский педагогический журнал. – 2008. – №12. – С.113-119.
6. Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле от прошлого и до настоящего. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. – 199 с.

БӘЕТЛӘРДӘ ШӘХЕС ЯЗМЫШЫ

Нигъмәтҗанова Д.Х.

Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты,
Яр Чаллы шәһәре, Россия

КОНЦЕПЦИЯ ЛИЧНОСТИ В БАИТАХ

Нигметзянова Д.Х.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Баиты как один из жанров татарского устного народного творчества стали создаваться в очень далёкие времена. Они бережно хранятся в исторической памяти нашего народа как национальные достояние.

Татарские баиты, как правило, отражали или важные исторические события в жизни народа (войны, крестьянские восстания), или чрезвычайные события, случавшиеся в жизни отдельного человека. Выделяются, в частности, баиты, посвященные сложным, тяжелым судьбам жертв культа личности. В них находят отражение глубокие философские размышления о судьбе человека, о смысле жизни.

***Ключевые слова**: баит, судьба народа, историческая память.*

THE CONCEPT OF PERSONALITY IN BAIT

Nigmetzyanova D.Kh.

Naberezhnochelninsky Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

The baits as one of genre of tatar oral arts has been created in very far times. They are carefully kept in the historical memory of our nation as national heritage.

The tatar baits usually reflected or the important historical events in nation's life (wars, peasant uprising), or emergency events, that happened in the life of the individual person. The baits dedicated to difficult fate of victims of the cult of personality is especially stood out. The deep philosophical reflections about fate of person, meaning of life are reflected in them.

***Keywords:** the baits, the fate of the nations, the historical memory.*

Бәетләр бик борынгы дәвердән үк иҗат ителеп килеп, татар халкының милли мирасы булып торалар.

Халык нинди генә шартларда яшәмәсен, нинди генә тарихи вакыйгалар аша үтмәсен, авырлыкларга игътибар итмичә җыр-моңга тартылган. Гаиләдә яисә дәүләттә

кайгылы яки шатлыклы вакыйга булса, озакламый әлеге вакыйгага багышланган җыр, мөнәҗәт яисә бәет иҗат ителгән. Еш кына әлеге әсәрләрне укып, тыңлап бөтен бер дәүләт тарихын күз алдына китерергә мөмкин.

Нәкъ менә татар халык иҗатының бер төре буларак бәетләр бик борынгы заманнарда иҗат ителү сәбәпле, милләтебезнең асыл затлары, халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас хатирә булып яши. Кадерле ул-кызларының исемнәре бәет булып татар халкы күңелендә саклана. Халкыбызның хәтерле, нечкә күңелле, сизгер булуына ишарәләп, Г. Тукай да: "Иске, күчмә заманнардан калган гадәте, нидәндер, безнең халык – шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык", – дип язган [7, б. 175].

Бәетләр халык тарафыннан иҗат ителәләр. Ләкин аларны туплап, бастырып чыгару, тарату эше белән шөгыльләнүчеләр булмаса, бәлки әлеге рухи мирасыбызның күбесе югалып, юкка чыккан булыр иде. Бәетләр турында иң беренче фикерләр Ш. Мәрҗанинең "Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" ("Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр") [3, б. 58] хезмәтендә очрый.

Аларны туплауны беренчеләрдән булып XIX йөз уртасында К. Насыйри башлап җибәрә. Аның эшен Х. Бәдыгый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Толымбай, Х. Ярми, И. Надиров кебек күренекле шәхесләр дәвам итәләр. Бүгенге көннәрдә бәетләрне өйрәнүчеләр булып Ф. Урманчеев, М. Бакиров, Ф. Әхмәтова кебек галимнәр тора.

Бәет сүзе гарәп теленнән алынган. Ул ике юллы тезмә әсәр дигән мәгънәгә ия. Заманалар узгач, бу сүз тезмә әсәрнең һәр ике юллыгын гына билгеләүдән туктый һәм тора-бара тулы бер шигъри әсәр, хәтта татар халык иҗатының аерым бер жанры бәет дип атала башлый [5, б. 5].

М. Бакировның бәет сүзен борынгы тарихи телләр яки аларның диалектларында сакланган бай (җыр, хикәят) һәм - ет, - эт (әйтү, көйләү) мәгънәләренә таянып, бойет - бәет (җырлана, сөйләнә торган хикәят) дип аңлатырга омтылуы игътибарга лаек [1, б. 262].

Бу жанр әсәрләре халык телендә бәет дип кенә түгел, мөнәҗәт дип тә, әрбагый дип тә йөртелә.

Бәет – татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Аның нигезендә кайгылы яисә көлкеле вакыйга ята. Әсәр шул вакыйга нәтиҗәсендә кеше күңелендә туган хис-кичерешләрне бәян итә [6, б. 5].

Бәетләрдә гәүдәләнгән образларның күбесе чынбарлыкта булган тарихи шәхесләргә – прототипларга нигезләнәләр. Еш кына бәетләрдә фаҗигале вакыйгалар үзәккә алына. Тарихта үз урынын алган тарихи шәхес, хатын-кызларның михнәтле язмышы, шәхси фаҗигаләргә, нахакка гаепләнгән кеше язмышлары бәетләрнең нигезен тәшкил итә.

Кайбер тарихи дәвернең үзенә генә хас күренешләре, вакыйгалары булу белән бергә, бәетләрдә дә теге яки бу иҗтимагый чорга бәйле рәвештә кеше язмышы чагылыш таба. Моның шулай икәнлеген Казан ханлыгы, шул чорда булган тарихи вакыйгалар һәм Казанның соңгы ханбикәсе Сөембикәгә багышланган бәетләр мисалында күзәтеп була. Шундыйлардан "яулап алынган хатын"ның фаҗигале язмышын гәүдәләндергән "Ханәкә-Солтан" бәете, "Казан тарихы" һәм "Сөембикә бәете" кебек бәетләрне атап үтәргә мөмкин. Бу бәетләр ил, татар халкы тарихындагы мөһим вакыйгалар турында гына сөйләп калмыйча, аерым тарихи шәхесләрнең дә трагик язмышларын сурәтлиләр (Туктамыш хан кызы Ханәкә-Солтан, Сөембикә һ.б.).

Алар – үзләренең илләреннән аерылырга һәм башка җирдә торткын, әсирлеккә мәҗбүр ителгән, коллыкка дучар булган тарихи шәхесләр.

Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, Ханәкә Туктамыш ханның кызы булырга тиеш. Академик В. Жирмунскийның түбәндәге фикерләре дә шуны раслый: "Фарсы тарихи чыганаклары раславынча, Идегәй Туктамыш ханның бер кызын торткынлыкка ала... Рәшедэддиннең "Монголлар тарихы"ның казакъ-татар теленә тәрҗемәсендә Туктамыш хан кызының исеме дә күрсәтелә: профессор И. Березин басмаларында Җаныкәй (күрәсең, Ханыкәй исеме ялгыш укылган). Димәк, бу исем чыннан да тарихи димәсәк тә, XVI йөздәге тарихи вакыйгаларга якын. Димәк, традициядә телгә алынуын истә тотарга тиеш булабыз [8, б. 17].

“Казан бәете” (“Казан тарихы”) әсәре Болгарны яулап алу һәм җимерү турында сөйләп башлана. Бәетнең тарихи нигезләре турында сүз алып барганда Болгар шәһәрен Аксак Тимер “Абдулла ханның кулыннан... алдыра” [5, б. 5] дигән сүзләргә игътибар итәргә мөмкин. Төрле тарихи язмаларда урын алган күп санлы легенда һәм риваятьләрдә, әлеге бәеттә кебек үк Аксак Тимер Болгар шәһәрен Абдулла ханның кулыннан ала, соңгысының Алимбәк һәм Алтынбәк исемле ике улы кала, диелә. Алар Болгардан төньяккарак качып китәргә һәм яңа кала төзәргә мәҗбүр булалар. Аны, шәһәр янынннан агып ятучы елга исеменнән чыгып, Казан дип атап йөртә башлыйлар. Яңа төзелгән ханлыкның тәхетенә яше буенча өлкәнрәк Алимбәкне утырталар.

Алга таба бәеттә Казанның Ядкәр хан идарә иткәндә, урыслар тарафыннан яулап алынуы турында сөйләнә. Чыннан да, 1552 нче елның 2 нче октябреннән Казан шәһәре урыслар тарафыннан тар-мар ителгәнче тәхеттә Әстерхан патшасының улы Ядкәр хан була. Бу бәеттә аның Казан алынганда хан тәхетендә утыруы һәм Иван IV кулына әсирлеккә төшүе белән бәйләнгән. Ядкәр Иван IV кә әсирлеккә төшә, аны Мәскәүгә алып китеп чукындыргач, Симеон дип исем кушыла һәм ул шунда 1565 нче елда үлә. Бәеттә сурәтләнгән вакыйгалар арасында легенда характерындагылары да бар. Имеш, Ядкәр үлгәннән соң аның ир туганнары ягыннан варислар калмый. Аптырагач, Ядкәрнең 9 яшьлек кызына хан булырга тәкъдим ясыйлар. Ләкин ул: “Шул хәтле ирләр булганда, мин нигә хан булыйм?” – дип, баш тарта һәм үз-үзен үтерә. Хан нәселеннән бердән-бер урысларга әсир төшкән Шаһгали генә кала. Бик күп акча бәрабәренә аны, әсирлектән коткарып, тәхеткә утырталар.

Билгеле булганча, Шаһгали – Казан тәхетенә берничә мәртәбә утырган кеше. Ләкин Казанның бәйсезлеген саклап калу өчен ул бернәрсә дә эшләми.

Нәселендә бер ир бар ирде, исеме аның Шигали,
Шифаларга яр ирде, тоткын булмыш ир дия [2, б. 26].

Бәет юлларыннан күренгәнчә, Касыйм хан улы Шаһгали (1506-1567) Казан тәхетенә өч мәртәбә хан итеп куелса да, рус патшалары кулындагы кеше генә булып кала.

Шул рәвешчә, “Казан бәете” Болгар дәүләтенең җимерелүеннән башлап Казанның һәм ханлыкның урыслар тарафыннан яулап алынуына һәм тәмам юкка чыгарылуына кадәр дәвам иткән тарихи вакыйгаларны үз эченә ала.

“Сөембикә” бәете Казанның соңгы ханбикәсенең шәхси язмышын гына сурәтли кебек. Әмма “Сөембикә” бәетендә Казан ханлыгының соңгы язмышы да тулысынча яктыртыла һәм дөньяга килүеннән башланып, ханбикәнең бәхетсез бер җан булып бик иртә вафат булуын хәбәр итү белән тәмамлана. Эчтәлектән күренгәнчә, ханбикә – Сөембикәнең язмышы, рус һәм татар дәүләте арасындагы дәүләти-сәяси мөнәсәбәтләр яссылыгында аңлатыла.

Ханбикә үзенең язмышына туры килгән газапларын, романтик шигърияттәгечә тәкъдир кушуы буенча эшләнә дип кабул итә. Алга таба бәеттә Сөембикәнең коллыктагы кичерешләрен, күңел дөньясын ачуга зур урын бирелә. Ханбикәгә багышланган тарихи җырлардагыча, әсирлеккә китү мәҗбүриятенә юлыккан “Сөембикә өч көн буена канлы күз яшьләре коя, күзләренең нуры бетә, Сафагәрәй кабере янында такмаклап елау-сыктаудан телләре әйләнмәс хәлгә килә, хәлсезләнеп, тере үлеккә әйләнә”. Хан сараендагы оркестрның йөрәк өзгеч җылау көйләрен уйнап озатуы Сөембикәнең хәсрәтен тагын да тирәнәйтә. Шәһәрдәге җылау-сыктау тавышлары кыямәт кубуын хәтерләтә башлый. Ханбикәне көймәгә утыртып алып китү, Казаннан мәңгелеккә аеру мотивы бәеттә аеруча тәэсирле бирелгән. Бәет тукымасына музыка культы кертеп җибәрелүе, җылау-сыктауларны “кыямәт кубу” белән чагыштыру, “мәңгелеккә аерылу” мотивын сурәтләү әсәрнең романтик яңгырашын бик тә көчәйтә.

Казаннан килеп төшкәч тә, Сөембикә зинданга – Мәскәүнең кызлар мәйданындагы ун сакчы саклый торган бер йортка ябыла:

Күп заманнар баргачтын, Мәскәүгә барып җиттем,
Бу бәхетсез башларга ни була? – дип без көттек.
Кызлар мәйданы дигән бер урынга илттеләр,

Бераз карап торгачтын, безне йортка керттеләр,

Кергән йортка каравыл куйдылар бер ун кеше,

Чыгармыйлар, йөртмиләр һәм кертмиләр бер кеше [4, б. 33].

Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән хан сараена китерелә һәм явыз Иванның рәхимсез һәм катгый карарын ишетә:

Падишах та шунда үзе, миңа әйтә бер сүзне.

“Балаң монда асралыр, иргә бирәм мин сезне”.

Диеп шунда баламны кулымнан да алдылар,

Әсирлектә янган идем, тагын утка салдылар.

Ишеттем мин, баламны коллар алганнар диеп,

Гакылы да юк сабыйны диннән чыгаралар дип [4, б. 33].

Бәеттә ханбикәнең дәүләтеннән, иленнән, җиреннән, газиз баласыннан аерылуы, бигрәк тә аны чукындыру кебек мотивлар куертылып, тирән психологизм һәм фаҗигалелек белән сугарылып, гиперболалар ярдәмендә көчәйтелеп сурәтләнгән.

Кайбер галимнәрнең фикеренчә, ханбикә бик яшьли, 1557 нче елда, 37 яшендә үлә.

Югарыда без, тарихта булып узган вакыйгаларга мөнәсәбәтле рәвештә чыгарылган бәетләрне карап үттек.

Татар халкының хатын-кызларның язмышына багышланган бәетләре дә байтак. Октябрь революциясенә кадәр татар хатын-кызларының иҗтимагый яктан хокуксызлыгы, асраулыкка бирелгән кызлар (“Асрау кыз”); үзе яратмаган кешегә кияүгә бирү, яки аның товар кебек сатылуы (“Зөлхәбирә”, “Кыз сату бәете”), язмышларына ризасызлык белдергән (“Җиде кыз бәете”), бәлагә юлыгу турында (“Су баткан Гайшә бәете”), нахакка рәнҗетелүче (“Сәхибә матур”) хатын-кызлар турындагы бәетләр тууга этәргеч була. Күпчелек очракта хатын-кызның язмышы фаҗига белән тәгәлләнә.

Татар халкының бертөркем бәетләре зур тарихи вакыйгалар (сугыш, крестьяннар күтәрелеше) яки кеше тормышындагы гадәттән тыш хәлләр уңае белән иҗат ителгәннәр. Шундыйлардан баш күтәрүчеләр (“Урта Тигәнәле”, “Чынлы”, “Ышна”, “Перепись”, “Мирсәй бәете”, “Комсомолец Рәхи бәете”), шәхес культы корбаннары язмышлары (“Сөрген бәете”) турындагы бәетләр үзенчәлекле төс ала. Мондый бәетләрдә кеше хокукларының җиргә салып тапталуы, кыйналу, ачлы-туклы яшәү, якыннарны сагыну хис-кичерешләре шәхес язмышының никадәр катлаулы һәм четерекле булуы турында сөйли.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк: шәхес язмышы турындагы бәетләрдә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе иң югары ноктасына җиткерелеп аңлатыла. Бу читен хәлләр күпчелек очракта Алладан, Тәкъдирдә язылганнан килә дигән фикерләр дә яши.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек / М.Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.262.

2. Казан бәете // Татар халык иҗаты. Бәетләр / Төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б.26.

3. Мәрҗани Ш.Б. Мостәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар / Төзүче Ә.Н. Хәйруллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б.58.

4. Сөембикә бәете // Татар халык иҗаты. Бәетләр / Төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б.33.

5. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр / Төзүче Ф.И. Урманчеев. – Казан, 2000. – Б.5.

6. Татар халык иҗаты. Бәетләр / Төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б.5.

7. Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда / Габдулла Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 4 Т. – Б.175.

8. Ханәкә-Солтан бәете // Татар халык иҗаты. Бәетләр / Төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б.17.

ДУХОВНО-НРАВСТВЕННЫЕ ЦЕННОСТИ ИСЛАМСКОЙ КУЛЬТУРЫ НАРОДОВ ТАТАРСТАНА

Сафиуллина Н.З., Исхакова Н.Р.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Исследование направлено на формирование толерантности во взаимоотношениях молодежи - последователей разных культур и религий. Общекультурные, духовно-нравственные и исторические традиции способны создать в обществе самое драгоценное – уважение культуры друг друга. Взаимодействие и мирное сотрудничество различных народов, позитивное развитие межнациональных, межконфессиональных отношений являются важным фактором в социально-политической стабильности любого государства.

Ключевые слова: *материальная культура, архитектура, ислам, традиции, молодежь.*

SPIRITUAL AND MORAL VALUES OF THE ISLAMIC CULTURE OF THE PEOPLES OF TATARSTAN

Safiullina N.Z., Iskhakova N.R.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

The study aims at the formation of tolerance in relations between young people - followers of different cultures and religions. Common cultural, spiritual, moral and historical traditions are able to create in society the most precious thing - respect each other's culture. Cooperation and peaceful co-operation of different nations, the positive development of inter-ethnic, inter-religious relations are an important factor in the socio-political stability of any country.

Keywords: *material culture, architecture, Islam, tradition, youth.*

Современная политическая карта мира сформировалась в результате сложных геополитических процессов, в том числе двух мировых войн, и много несправедливых явлений сохраняется и в современном политическом устройстве. Однако трудно себе представить судьбу нашей планеты, если актуализируются все эти конфликты, которые сейчас находятся в латентном состоянии. Самое главное, нет ни какой гарантии, что в результате «справедливых» разрешений все конфликтные ситуации будут устранены: ведь у каждой из конфликтующих сторон свое представление о справедливости.

Урегулирование и прекращение межэтнических этносоциальных конфликтов является жизненно важной необходимостью существования полиэтнического сообщества, где на протяжении веков сосуществуют представители различных религиозных конфессий. Примером этого может служить многонациональная республика Татарстан. На территории республики проживают представители таких конфессий, как ислам, христианство, иудаизм и др. Такое конфессиональное разнообразие и мирное сосуществование религий во многом уникальны. И их изучение, сохранение являются важной государственной задачей народа [2, с. 348]. Религиозная нетерпимость и безтактность часто являются существенными факторами обострения межрегиональных противоречий и причины центробежных тенденций.

Конфликтные межэтнические, межконфессиональные и межнациональные отношения, характер и тенденции их развития всегда негативно влияют на основные вопросы социально-экономического, культурного, духовного и политического развития любого многонационального государства. Они не просто задерживают и нарушают ход общественного развития, но и способны изменить всю его ориентацию, породить новые негативные тенденции, заложить фундамент для будущих конфликтов других поколений. Государству для стабильного развития необходима новая – социологическая концептуальная основа, которая будет основана на программе социально-экономического развития любого общества, куда входят духовно-нравственные ценности, культура и традиции многонационального и многоконфессионального государства. Духовно-нравственные ценности, культура и традиции занимают лидирующую роль в регулировании острых проблем этносоциальных процессов [3, с. 108].

Возрождение и всестороннее развитие системы ценностей, духовно-нравственных основ общества, содействуют взаимному обогащению культур и выработке у молодежи уважительного отношения к духовным ценностям народов. Духовная культура общества вырастает на фундаменте его общей культуры. Социально-политическое развитие современного общества связано с самоопределением молодежи, суверенностью государства, развитием национальных языков и культур. Мировая культура развивается как единая многонациональная культура полиэтнических сообществ. Данная работа представляет собой исследование проблем влияния элементов исламской культуры на формирование самосознания молодежи. Культурные традиции ислама, которые влияют на межконфессиональные процессы, а также на развитие духовно-нравственных ценностей, многонациональной республики, могут стать хорошей основой для брендирования и презентации Татарстана на федеральном и международном уровне.

Религиозный плюрализм сегодня является краеугольным камнем демократии и в российских условиях он в какой то степени отражается в Законе «О свободе совести и религиозных объединениях», в принятых Российской Федерацией международных обязательствах («Всеобщая декларация прав и свобод человека, конвенции Совета Европы» и другие акты).

На современном этапе ислам для татарского народа является не только выражением религиозных канонов, это по существу и история, и часть культуры, и образ жизни. В последние годы общественно-политиическая жизнь многонациональных республик стала намного разнообразнее и богаче. Религия сейчас является немаловажным фактором определяющей духовную жизнь народов. Сегодняшняя обстановка в многонациональной и многоконфессиональной республике Татарстан отражает последствия тех коренных изменений в государственном и политическом строе, которые произошли за последние десятилетия и существенно затронули сферу духовных отношений общества. Эти отношения в республике строятся в строгом соответствии с принципом свободы совести, включающем в себя такие понятия, как равенство всех религий перед законом, светский характер государства, воспитание молодежи в духе веротерпимости [1, с. 49].

Духовные факторы ислама, складывающиеся на основе нравственных ценностей общества являются определяющими, формируя социокультурное видение феномена мусульманской религии. Культура ислама, формируя особую сферу сакрального мира, способствует самобытному развитию этносов и их культур. Они оказывают существенное влияние на общественно-политическую жизнь республики и на духовную сферу общества. Сегодня ислам в татарском обществе обеспечивает определенную стабильность. Он способствует регенирации общества, сохранению в нем элементов культурной традиции народов.

Список использованной литературы

1. Батыршина А.Р., Гильманов М.М. К вопросу о взаимовлиянии исламской религии и народной педагогике. Преемственность народных традиций. – Материалы пятой международной научно-практической конференции. – Ч. 1. – Казань, Набережные Челны, 1998. – С. 49-50.

2. Исхакова Н.Р., Сафиуллина Н.З. Проблемы экстремизма в молодежной среде (социологический анализ на материалах исследований школ г. Набережные Челны). Конфликтология 21 века. Пути средства укрепления мира; материалы Второго Санкт-Петербургского международного конгресса конфликтологов, Санкт-Петербург, 3-4 октября 2014 г. – СПб., 2014. – С. 348-351.

3. Сафиуллина Н.З., Исхакова Н.Р. Духовная культура как нравственный ориентир в воспитании современной молодежи. Адлеровские социологические чтения. – 2012. – Т. 1. – № 1. – С. 108-112.

РОЛЬ ИСТОРИКО-КУЛЬТУРНЫХ ЦЕННОСТЕЙ ИСЛАМА В СОВРЕМЕННОМ ПОЛИЭТНИЧЕСКОМ ОБЩЕСТВЕ

Сафиуллина Н.З., Мансурова М.Ф.

Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов, г. Набережные Челны, Россия

Более тысячи лет мусульмане проживают в России вместе с представителями различных конфессий. В связи с этим большое значение имеет обращение к историко-культурному наследию мусульман, в частности проживавших на землях бывшей Волжской Булгарии. Исламизация булгарского общества шла по восходящей линии, проникая во все области жизни государства. Ислам дал огромный толчок для развития просвещения и научных знаний. Обращение к культурному наследию мусульманского мира имеет в современных условиях большое историческое значение, т.к. возрождение культурного наследия народов может стать важным фактором выхода страны из духовно-нравственного кризиса.

Ключевые слова: *конфессии, исторические наследия, мусульманская культура, духовная жизнь, исламизация, историко-культурные ценности, межэтническая гармония, многонациональная Россия.*

THE ROLE OF HISTORICAL AND CULTURAL VALUES OF ISLAM IN A MODERN MULTI-ETHNIC SOCIETY

Safiullina N.Z., Mansurova M.F.

Naberezhnye Chelny Institute of socio-pedagogical technologies and resources, Naberezhnye Chelny, Russia

More than a thousand years Muslims live in Russia, together with representatives of various faiths. Therefore, a great importance to the historical and cultural heritage of Muslims in particular who lived on the lands of the former Volga Bulgaria. Islamization of Bulgarian society was on an upward trend, permeating all areas of life in the state. Islam has given a huge impetus to the development of education and scientific knowledge. The reference to the cultural heritage of the Muslim world has in modern conditions of great historical importance, since the revival of the cultural heritage of the peoples may become an important factor of the country's withdrawal from spiritual and moral crisis.

Keywords: *confessions, historical heritage, Muslim culture, spiritual life, Islamization, historical and cultural values, inter-ethnic harmony, multinational Russia.*

Более тысячи лет мусульмане проживают в России вместе с представителями различных конфессий. За прошедшие века ислам и мусульмане внесли большой вклад в

формирование государственности, дали стране и миру видных политиков, деятелей науки и культуры, таких как М.Ш. Шаймиев, Х. Туфан, И. Шакиров, З. Туешева, С. Губайдуллина и другие. Длительное совместное проживание на одной территории привело к взаимному обогащению культур и традиций народов, исповедующих различные религии, выработало уважительное отношение друг к другу. В этих условиях немаловажное значение имеет обращение к историческому наследию на землях бывшей Волжской Булгарии.

Распространение ислама в Поволжье среди предков татарского народа тесно связано с историей Булгарского государства. В конце IX – начале X в. в процессе оформления раннефеодальной государственности у булгар наблюдается коренной перелом во всех сферах экономической, общественно-политической и культурной жизни. Завершается переход населения к оседлости, появляются новые села, идет интенсивное развитие пашенного земледелия и различных ремесел, расширяются и торговые контакты со странами Востока и Запада. Формирующееся молодое Булгарское государство нуждалось в идеологии, которая отвечала бы интересам общества. Такой идеологией стал ислам, пришедший на смену тенгрианству. Исламизация булгарского общества шла относительно быстро по восходящей линии. Кроме того ислам, как монотеистическая религия, способствовал объединению булгарских племен и ускорил процесс образования и укрепления государственности. Процессы образования и укрепления Булгарского государства, развитие ислама были тесно взаимосвязаны. В X веке ислам активно распространяется по всей территории страны, проникает во все области жизни, во все слои общества. Волжская Булгария становится мусульманским государством: распространяется мусульманская культура – материальная и духовная. Прогрессивную роль принятия ислама Волжской Булгарией отметил в свое время известный историк А.П. Смирнов. Он писал: «Принятие ислама булгарами имело для их государства большое значение, т.к. приобщило значительный круг населения к мусульманской культуре, являющейся в то время передовой культурой Востока и сыграла прогрессивную роль в тех условиях» [4, с. 68-69].

С развитием Булгарского государства усиливается потребность общества в единой письменности. Без единой письменности не мог складываться и развиваться общебулгарский язык. Таким образом, единая письменность подготовила основы для развития общебулгарского языка, вследствие которого в дальнейшем были созданы такие памятники литературы, как поэма Кул Гали «Кысса-и Йусуф», получила научные трактаты и т.д. [2, с. 59-60]. Кул Гали по праву считается основоположником булгаро-татарской письменной литературы. В своем творчестве он опирался на произведения восточных поэтов той поры, как, например, Фирдоуси. Основу булгарской письменности составила арабская графика. На ней делали надписи на многочисленных памятниках, ювелирных изделиях, бытовых вещах. Образцы этих надписей являются настоящими произведениями каллиграфии. Булгары чаще всего писали на бересте, на досках, покрытых слоем воска. С принятием ислама широкое распространение у булгар получила бумага. Ее привозили из Самарканда. Писали на ней чернилами и перьями.

Распространение письменности шло параллельно с развитием просвещения среди широких слоев населения. В X веке в Булгарском государстве были начальные школы, где учили читать и писать. Дети читали хадисы, заслушивали отдельные аяты – небольшие отрывки из Корана. После учащиеся могли продолжать свое образование в медресе. (Это средние и высшие учебные заведения). Учащиеся медресе (шакирды) изучали богословие, получали знания по математике, географии, истории, астрономии, медицине. Большое внимание уделялось изучению арабского и персидского языков. Наиболее способные шакирды могли продолжить свою учебу в культурных центрах Востока: в Самарканде, Бухаре, Багдаде. Ислам не препятствовал, а, наоборот, способствовал получению знаний. Так, например, даже в хадисах сказано: «Час затраченный на приобретение знаний, Аллаху угодней, чем целая ночь, проведенная в молитве». История булгар знает целую плеяду ученых булгарского происхождения: Эш-шейх Ходжа Ахмед Булгари – ученый, лекарь,

богослов; Абдулл-Аля Хамид Ибн Идрис ал-Булгари – философ и богослов; Сулейман Ибн Йусуф ал-Булгари – ученый, медик, богослов и другие [3, с. 65-66].

Ислам не только укрепил государственность Волжской Булгарии, но и дал огромный толчок для развития просвещения и науки. Широкое развитие получили научные знания по химии, медицине, математике и др. Знания по химии были необходимы булгарам в различных видах производства и в фармакологии. Уже на рубежах X-XI веков булгары научились производить сталь высокого качества, изготавливали бумагу, стекло и различные красители. Ремесленные мастерские находились в городе Биляре и в других городах.

В государстве распространялись и медицинские знания, которые основывались на прогрессивных традициях народной медицины. Особым уважением пользовались в обществе лекари-травники. Они раскрывали секреты целебных свойств меда, березового веника и различных трав. Лекари-табибы умели изготавливать ценное лекарство из бобровой струи, использовали при лечении болезней белемниты – вымершие окаменевшие беспозвоночные моллюски; изготовляли чудо-мазь под названием «чарме-и булгхар» («булгарская кожа»). С булгарских времен дошли до нас труды Ибн Сины – знаменитого средневекового табиба-врача.

У булгар развивалась и математика, в частности, вычислительная, необходимая в торговле, строительстве, ремесленном производстве и канцелярском деле. Развивается архитектурная математика, основанная на различных измерениях и геометрических формах. Булгары также использовали в строительстве принцип «вавилона». На развалинах булгарских городищ были найдены игральные фишки, фигуры шахмат, шашек. Использовали математическое мышление в различных играх, магии. Проникновение его в духовную жизнь населения говорит о широком распространении математических знаний в булгарском обществе.

Тесно была связана с исламом, его обрядами и требованиями в Булгарском государстве очень популярная в мусульманском мире, наука астрономия. Булгарские астрономы наблюдали за движением солнца, луны, звезд и многочисленных других планет. Эти наблюдения привели к образованию таких понятий, как год, месяц, день и ночь, час, весна, лето, осень, зима. Были созданы календари: солнечный, лунный, лунно-солнечный. Булгары, в основном, пользовались лунно-солнечным календарем. Он был удобен тем, что учитывал смену фаз Луны и годичное движение Солнца, что облегчало труд булгар-земледельцев.

Широкое развитие получила градостроительная культура. Города стали приобретать мусульманский облик. Повсюду строились мечети. В Булгаре и Суваре были построены соборные мечети внушительных размеров. На многочисленных болгарских городищах – остатках городов, феодальных замков, военных крепостей, археологами были обнаружены развалины различных монументальных, т.е. крупно-масштабных, кирпично-каменных сооружений. Огромные 2-3-х этажные дворцы правителей, великолепные культовые (мечети, минареты) и общественные сооружения (бани) имеют сложную архитектурную планировку, в основе которой лежит прямоугольник близкий к квадрату [1, с. 35-37; с. 90-92].

В то время для соседних народов и для самого булгарского общества город Булгар стал центром, из которой исходило сильное культурное влияние.

Исламизация булгарского общества укрепило связи Волжской Булгарии с внешним миром: с мусульманским Востоком, с развитыми азиатскими странами. Тесные культурные связи способствовали укреплению государственности у Булгар. Уже с тех ранних времен ислам Булгарского государства превращается в неотъемлемую составную часть общемирового исторического, духовного и культурного наследия. Мусульмане всегда вносили и вносят свой вклад в дело процветания своего государства. Сегодня мусульмане России всемерно содействуют поступательному развитию российского общества, достижению мира, дружбы, межэтнической гармонии, согласия и сотрудничества между всеми народами и конфессиями. В течение тысячелетий в

многонациональной России уживались последователи разных религий – христианства, ислама, иудаизма, буддизма.

Обращение к культурному наследию мусульманского мира, возрождение духовной и материальной культуры прошлого имеет в современных условиях большое историческое значение, так как оно обусловлено потребностями сегодняшнего дня. Возрождение культурного наследия народов может стать важным фактором выхода страны из духовно-нравственного кризиса. Сегодня духовность изучается представителями различных отраслей гуманитарных дисциплин, это философы, историки, социологи, психологи, педагоги. Духовность – это сложная система элементов, состоящая из совокупности культурного наследия общества и играет большую роль в формировании личности. Такой подход к пониманию духовности позволяет нам говорить о нравственной культуре, о культуре образования, об освоении национальных культурных ценностей и традиций общества, а также о приобщении к культурному достоянию всего исторического наследия накопленного народами веками [3, с. 76-77].

Список использованной литературы

1. Ахметов Г.Н. Избранные труды. – Казань: Таткнигоиздат, 1998. – 238 с.

2. Давлетшин Г.М. Ислам и мусульманская культура в истории татарского народа. – Казань: Казанский университет, 2013. – 180 с.

3. Мухаметшин А.Г., Сафиуллина Н.З., Исхакова Н.Р. Из истории развития педагогической мысли, духовно-этнических традиций татарского народа (на материалах РТ). – Набережные Челны, 2012. – 84 с.

4. Тагиров Р.И. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. – Казань: Казанский университет, 2013. – 180 с.

5. Халиков А.Х. Происхождение татар Поволжья и Приуралья. – Казань: Таткнигоиздат, 1978. – 160 с.

6. Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. – Казань: Таткнигоиздат, 1989. – 222 с.

ГАРМУН ОБРАЗЫНЫҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ (ЧАЛЛЫ ТӨБӘГЕ ӘДИПЛӘРЕ ИҖАТЫ МИСАЛЫНДА)

Хәмидуллина Р.Г.

МБУ “Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы”, Яр Чаллы шәһәре, Россия

ВОСПИТАТЕЛЬНАЯ РОЛЬ ОБРАЗА ГАРМОНИ (НА ПРИМЕРЕ ТВОРЧЕСТВА ЧЕЛНИНСКИХ ПИСАТЕЛЕЙ)

Хамидуллина Р.Г.

МБУ “Централизованная библиотечная система”, г. Набережные Челны, Россия

В статье на примере творчества Челнинских писателей рассматривается воспитательно-нравственное значение образа гармони.

Ключевые слова: *Набережные Челны, татарская литература, образы, гармонь.*

EDUCATIONAL ROLE OF THE HARMONIC’S IMAGE (ON THE EXAMPLE OF WRITERS FROM CHELNY)

Khamidullina R.G.

MBA “The centralized library system”, Naberezhnye Chelny, Russia

In the article educational and moral significance of harmonic’s image is considered on the example of writers from Chelny.

***Keywords**: Naberezhnye Chelny, Tatar literature, images, harmonic.*

Әдәбият, гасырлар дәвамында тупланып килгән язма мирас буларак, сәнгатьнең башка төрләреннән үзенең байлыгы, күптөрлелеге, кеше шәхесен формалаштырудагы әһәмияте белән аерылып тора.

Әдәбият әсәрләре дөньяны танып-белү, кешеләргә тормышны аңлатып бирү, идея-рухи яктан тәрбияләү максатына хезмәт итә. Матур әдәбият әсәрләре образларга бик бай. “Романтиклар иҗатында образлылык бигрәк тә калку чагыла”[1]. Образлар ярдәмендә әдипләр күп вакытта фәлсәфи кичерешләрен белдерәләр. Мәсәлән: чәчәк – матурлык, мәхәббәт билгесе булса, чишмә – тормыш, яшәеш башлангычы билгесе булып тора.

Татар әдәбиятында гармун образы да бик еш очрый. Гади генә булып тоелган бу уен коралын нинди генә мәгънә төсмерләренә төреп бирмиләр?!

Бу мәкаләмдә Чаллы әдипләре иҗатына тукталасым килә. Чаллы әдипләренең поэзия (К. Сибгатуллин, Г. Шаһи, Н. Галимов, Ә. Ситдыйкова, Н. Гафиятов, Р. Гыймадиев), проза (Э. Касыймов, А. Хәлим, Я. Шәфыйков, Ф. Сафин) әсәрләрен күздән кичерербез.

Төбәгебез язучылары гармун образы аша гармун уйнаучының кайгы, зар-моңнарын укучыга җиткерә, сагышын тарата, күңелен юата. Алай гына да түгел, тыңлаучы да шундый ук хисләр кичерә. Яхшы ният белән кулга алынган гармун үз алдына куелган вазыйфаны җиренә җиткереп башкара. Әдәби әсәрләрдә мондый үрнәкләрне бик күпләп табарга мөмкин.

Халкымның уен коралы гармуннан агылган моң төшенчәсен бер сүз белән генә аңлату мөмкин дә түгел. Моң – ачы да була ала икән. Язучы Эдуард Касыймов “Кояш көн дә чыга” повестенда яңгыраган көйне “ачы моң” итеп күрсәтә: “Авылның югары очында кайсыдыр, йөрәк моңнарын кушып тальянкасын тарта. Тукта, бу бит таныш, бик таныш көй! Абдулланың кәефе шәп бүген. Маңгай тире агызып эшләгән халыкның күңелен күтәрәсе, “алтын кулларының” дәртен, куәтен арттырасы бар аның, шуңа ашыга ул, шуңа ерактан ук баянын сузып җибәргән, тамагына көй салган. Тез өстендә озак тибрәнде баян. Әмма үзәк өздергеч ямансу, моңсу көйләрдән башкасы күңелгә килмәде, бармаклар, сихерләнгән кебек, һаман да хәсрәтле төймәләргә бастылар, иреннәрдән һаман да, сөрем шикелле, ачы моң агылды”[2].

Ә язучы Ягъсуф Шәфыйков “Зәңгәр таудан яулык болгармын” хикәясендә, төрмәгә бер гөнаһсызга этисен алып киткәндә озата баручы ун яшьлек егетнең гармунда моңлы итеп уйнавын тасвирлый: “Аның моңы, күңел кылларын тибрәндереп, игеннәре җыелган басуларга, урман полосаларындагы алтын яфраклар белән бизәлгән нәфис каеннар арасына таралды”. Язучы укучыга хикәя ярдәме белән, татарның киләчәген, алай гына да түгел, күңелендә гармунга карата мәхәббәт йөрткән кешенең бервакытта да бәхетсез булмавы турында да искәртеп үтә. Шуларга өстәп әсәр герое авызыннан автор түбәндәге сүзләрне ишеттерә: “Тормышта беркайчан да боекма. Ә тальянкаңа килсәк, ул сине һәрвакыт коткарыр. Сакла син аны. Ә хәзер саубуллашу хакына уйна әле тагын “Сарман”ны, – диде”[3]. Тормышта ачысын-төчесен дә күргән кеше сүзләре бу. Ул аны, тулы мәгънәсенә төшенеп, татар гармуны өчен горурлык кичереп, баланың күңелендә гармунга карата мәхәббәт җепсезләре уятып, бөтен күңеленнән, бөтен барлыгы белән җиткерә.

[1] Әдәбият белеме сүзлеге / төз. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 125.
[2] Касыймов, Э. Повестьлар / Э. Касыймов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 4.
[3] Шәфыйков, Я. Хуш, Агыйдел!: повестьлар, хикәяләр, фельетоннар / Я. Шафыйков. – Казан: “Идел-Пресс”, 2002. – Б. 88-95.

Шагыйрьләребез күпчелек очракларда мәхәббәт хисләрен тальян гармун образы ярдәмендә аңлаталар. Мәхәббәт хисләре белән сугарылган шигъри тәлгәшләр тудыралар. Моның бер дәлиле итеп түбәндәге шигырь юлларына тукталыйк.

Яз уянмый кояш елмаймаса,
Җир яшәрми җылы яңгырсыз...
Мәхәббәтең тулып ташыганда,
Яшәү кыен тальян гармунсыз.
(Р. Гәрәй “Тальян гармун”[1])

